РОССИЯ ФЕДЕРАЦИЯСЕНЕҢ
МӘГАРИФ ҺӘМ ФӘН МИНИСТРЛЫГЫ
КАЗАН (ИДЕЛ БУЕ) ФЕДЕРАЛЬ УНИВЕРСИТЕТЫНЫҢ
АЛАБУГА ИНСТИТУТЫ

ТАТАР ФИЛОЛОГИЯСЕ КАФЕДРАСЫ



# ТАТАР ТЕЛЕ ҺӘМ ӘДӘБИЯТЫ, ТАРИХ: ҮТКӘНЕ, БҮГЕНГЕСЕ, КИЛӘЧӘГЕ

УКУЧЫЛАРНЫҢ ҺӘМ СТУДЕНТЛАРНЫҢ
XV БӨТЕНРӘСӘЙ ФӘННИ-ГАМӘЛИ КОНФЕРЕНЦИЯСЕ
МАТЕРИАЛЛАРЫ
(Татар драматургиясе классигы Галиәсгар Камалның
145 еллыгына багышлана)

АЛАБУГА – 2024

ББК 81.632.3
УДК 811.512. 145.
Т 23

Казан (Идел буе) федераль университеты Алабуга институтының Гыйльми советы карары белән басыла (берткетмә № 3, 28 март 2024 ел)

**Бәяләүчеләр**:

**Галиуллин Р.Р.** – филология фәннәре кандидаты, Яр Чаллы дәүләт педагогия университеты доценты.

**Шаймарданова М.Р.** – филология фәннәре кандидаты, Казан (Идел буе) федераль университетының Алабуга институты доценты.

**Редколлегия:**

**Камаева Р.Б.** – филология фәннәре докторы, Казан (Идел буе) федераль университеты Алабуга институтының татар филологиясе кафедрасы профессоры.

**Габидуллина Ф.И**. – филология фәннәре кандидаты, Казан (Идел буе) федераль университеты Алабуга институтының татар филологиясе кафедрасы доценты.

**Даутов Г.Ф.** – филология фәннәре кандидаты, Казан (Идел буе) федераль университеты Алабуга институтының татар филологиясе кафедрасы доценты.

**Хәйруллина Ә.С.** – филология фәннәре кандидаты, Казан (Идел буе) федераль университеты Алабуга институтының татар филологиясе кафедрасы доценты.

**Т23 Татар теле һәм әдәбияты, тарих: үткәне, бүгенгесе, киләчәге:** укучыларның һәм студентларның XV Бөтенрәсәй фәнни–гамәли конференция материаллары (Татар драматургиясе классигы Галиәсгар Камалның 145 еллыгына багышлана (Алабуга, 20 февраль, 2024 ел). – Алабуга, 2024. – 166 б.

*«Татар теле һәм әдәбияты, тарих: үткәне, бүгенгесе, киләчәге» фәнни-гамәли конференциясенең материаллары тупланган җыентыкка укучыларның, студентларның, магистрантларның фәнни тикшеренү эшләре кертелде.*

*Россия Федерациясенең Татарстан, Чувашстан, Башкортостан республикаларында яшәгән укучыларыбызның фәнни мәкаләләрендә татар теле һәм әдәбиятының актуаль проблемалары, тарихның күпләрне борчыган һәм дулкынландырган мәсьәләләре, татар әдипләре иҗатында милли яшәешнең яктыртылуы турындагы тикшеренү нәтиҗәләре урын алган.*

©Авторлар коллективы, 2024
© КФУның Алабуга институты, 2024

# ТАТАР ӘДӘБИЯТЫНЫҢ АКТУАЛЬ МӘСЬӘЛӘЛӘРЕ

Абакаева А.В.,
Алабуга шәһәренең 8 нче урта мәктәбе укучысы.
Фәнни җитәкче: Гайсина Г.Г.

Татар әдәбиятын күренекле каләм ияләреннән башка күз алдына да китереп булмый. Ничәмә буын аларның әсәрләрен укып, шул әсәрләрдәге геройларга охшарга тырышып үсте. Ул әсәрләр сугыш кырында дошманны җиңәргә, тормышыбызда әхлак бозмыйча, намус кушканча яшәргә өйрәтте. Кулга кесә телефоннары, өйләребезгә интернет дигән техник чаралар килеп керү белән Китап уку онытыла башлады. Бүгенге буын мәктәп балалары аны кирәксенми дә. Халыкның әхлагы шуңа түбәнәйде, шуның белән бәйле рәвештә тормышыбыз үзгәреш кичерә башлады. Китап дигән изге нәрсәбез киштәләрдә тузан җыярга калды. Гомер буе адәмне кеше итеп яшәткән китапка көн бетте.

Китап укуны мин татар әдәбиятының иң беренче актуаль мәсьәләсе дип атар идем. Изге китаыбыз “Коръән”дә дә укыганны язу белән ныгытып куярга дигән сүзләр бар ич. Бүгенге буын укыганны язып куярга да иренә.” Интернет бар ич – ачасың да карыйсың”,– дип фикер йөртә хәзерге мәктәп баласы. Әле “Безнең гәҗит”нең 42 нче санында “Күренекле галимнең гыйбрәтле китабы” баш астында Рүзәл Юсупов турында мәкалә чыкты.Аннан мисал итеп уку турында өзек китерәсем килә. “Тормыш авыр,мәктәпкә, дәрескә вакыт та калмый .Әмма Рүзәлгә кечкенәдән китап җене кагылган була. Укырга ярата һәм бу сыйфат аны күренекле галим дәрәҗәсенә күтәрә дә...”Димәк, галимнәр дәрәҗәсенә үстерү өчен дә китап уку олы этәргеч бирә.

“Акчарлак” гәҗитенең 42 нче санында Зөлфәт Зиннуров олы кызы Зәлиянең”Маша һәм аю”мультфильмын татарча тавышландырган мизгелләрен интертентка куя. Бер ханым: ”Нигә радиода утыручыларның балалары? Нигә гади кешенеке түгел? Ужас! Артыннан эткәч әйбәт инде,”– дип кайтаваз яза.

Зөлфәт Зиннуров аңа болай дип җавап бирә:” Чынлап та ни өчен?.. Бәлки тууга ук саф, әдәби телдә сөйләшергә өйрәткәнгәдер? Һәм әле өйдә татарча гына сөйләшеп, татарча китаплар укырга мәҗбүр иткәнгәдер? Бәлки туган авылыбызда мәктәп була торып, татарча укысын дип, 20 чакрым ераклыкта урнашкан гимназиягә йөрткәнгәдер? Бәлки ял көннәрендә, иренмичә, балалар белән шөгыльләнгәнгәдер? Ә сезнең балаларыгыз, оныкларыгыз татарча сөйләшә беләме?

Дөрес фикер, балалар белән өстәмә үзебез шөгыльләнмәгәч, башкаларга ничек үпкәләргә кирәк? Баланы тәрбияләү– һәркемнең изге бурычы.

Өлкән буын вәкилләре китапны бүген дә кадерләп саклый. Укый. Якыннары белән фикер алыша. Ләкин бу тәҗрибәсен балаларына сеңдереп кала алмаган.Сәбәпләрен үзебез дә яхшы аңлыйбыз.Баланы артык кызганырга өйрәнеп барабыз түгелме? Ул баланың кем булып үсүе генә уйландырмый, ахрысы.

1970–1980 нче елларда Алабуга педагогия институтында укыган студентлар хәзер дә аның мөгалимнәрен сагынып искә төшерә: Салихов Рим Гарипович, Сәлимов Хәлил Хәлимович, Шәрипов Әнвәр Мәгъданурович – татар әдәбиятының алыштыра алмаслык белгечләре иде. Кызыксындыра да, таләп итә дә белделәр. Димәк, алар үз фәннәрен яратып, башкаларга аңлата белгәннәр. Шуңа бүгенге көндә дә исебездән чыкмыйлар.

Әдәбиятны яратып аңлату– икенче актуаль мәсьәлә дип уйлыйм мин. Үз йөрәгең аша уздырганнар гына башкаларныкына барып җитә. Бүгенге мәктәптә укытучылар чын әдәбиятчылармы? Бала күңеленә ни сала алар. Бу турыда да уйларга вакыт җиткәндер. Югыйсә, балага әхлак кайдан иңсен!

Китапханәне  дә онытты бүгенге буын. Китап алып укырга куркалар. Укымагач, нинди күңел байлыгы булсын аларда, нинди хис чәчәк атсын. Уйланырлык нәрсәләр монда да җитәрлек.

Нинди генә китаплар юк китапханә киштәләрендә. Зәвык белән эшләнгән,ал да укы гына, ләкин монда йөрүчеләр дә бик аз, күбесенчә өлкән буын вәкилләре.Өченче актуаль мәсьәлә, минемчә, шул.

“Безнең гәжит”нең 43 нче санында Рәүф Хәсәновның” Милләтне кемнәр таныта?” исемле мәкаләне дә мисал итеп китерәсм килә.”Халкыбызның киләчәге барыбызны да борчыйдыр, – дип башлана ул.– Милләтне саклап калу юнәлешләрекүп, аларбарысы да бер максатка–телгә ихтыяҗны арттыруга хезмәт итәргә тиеш... Милләтебез сакланып калсын өчен , һичшиксез, безгә берничә бик мөһим сыйфатка ия булырга кирәк:

1) горурлык

2) җаваплылык

... Шунысын онытмыйк: татар телен белү төрки дөнья белән багланышлар өлкәсендәэшләү мөмкинлекләрен ача.Мөселман дөньясында дә, төрки дөньяда да татарлар гыйлемле халык буларак танылган.Безнең киләчәк буын татар егет–кызларыда шушы традицияне дәвам итәр, башка төбәкләрдә,чит илләрдә дә үз илен,үз республикасын,үз милләтен лаеклы күрсәтер дип өметләнәбез...” – дип әйтелә анда. Татар әдәбиятын яхшы белгән кеше – монда халкының мәдәниятен күрсәтүче дә. Безнең халык турында алардан күреп фикер йөртәләр. Бу халкыбызның мораль йөзе, үсеше , горурлыгы, яшәеше.

“Алабуга нурының” 79 нчы санында “артист тыныч кына яши алмый” исеме астында Резедә Сәләхова белән әңгәмә басылды. Анда аңа: “Милли мәдәниятка ничек тартылдыгыз?” дигән сорау белән мөрәҗәгать иткәннәр. Резедәнең җавабы шундый: ”Казанның дүртенче татар гимназиясендә укыдым. Вокаль ансамбльдә җырлый идем. Республика күләм бәйге һәм бәйрәмнәрдә чыгыш ясап үстек....”

Уйландыра торган җавап.Тормышыбызда телнең роле – безне кеше итеп таныта. Балачакта биргән юнәлеш онытылмый. Соңыннан һөнәр сайларга да , милләтеңә хезмәт итәргә дә этәргеч бирә икән.

Шушында ук  глобальләшү  заманында туган телне, милли рухны ничек сакларга дигән сора у да бирелгән.Р езедәнең җавабы мондый: “Күп әйбер

гаиләдән килә. Без дә улыбызның татарча сөйләшүен телибез, киләчәктә татар гимназиясендә укытырга ниятлибез.

Кайбер ата-аналар, хәтта минем танышларым да, мәктәптә БДИ тапшырасы була дип, баласын русча гына укыта. Имтиханнан куркып, туган теленнән ваз кичкән кешеләрне аңламыйм да, аңларга теләмим дә. Мәктәптә татарча укып, имтиханнарга русча әзерләнеп, аларны яхшы билгеләргә тапшырган һәм үз көче белән югары уку йортларына укырга кергән балалар күп бит. Шуларны үрнәк итеп күрсәтергә кирәк. “Туган тел кирәкми”дигән фикер башка да керергә тиеш түгел.

Татар әдәбиятының актуаль мәсьәләсе – бу телебезне белү.Үз телен яхшы белгән кеше генә кирәкле белгеч тә сәнгать кешесе дә,янында ныклы таяныч та була ала.Телнең үсеше әдәбият үсеше белән бәйләнгән.Телен камил белгән кеше генә яратып укырлык, геройлары укучы күңелендә сакланырлык әсәрләр иҗат итә ала.

**Әдәбият**

1.”Акчарлак” гәҗите, 42 нче сан, 28 нче октябрь, 2022.
2.”Безнең гәҗит”, 42 нче сан, 26 нчы октябрь, 2022.
3.”Безнең гәҗит”, 43 нче сан, 2 нче ноябрь, 2022.
4.”Алабуга нуры”,79 нчы сан, 28 нче октябрь, 2022.

## ГАЛИӘСГАР КАМАЛ – ТАТАР ТЕАТР СӘНГАТЕНӘ НИГЕЗ САЛУЧЫ

Айзатуллина Д.А.,
Әлмәт шәһәренең 17нче урта мәктәбе укучысы.
Фәнни җитәкче: Ибрагимова Г.А.

Галиәсгар Камал татар әдәбиятчысы, драматургия әсәрләре авторы, җәмәгать эшлеклесе һәм Татарстанда театр эшенә нигез салучы. Ул рус классикларының әсәрләрен тәрҗемә итә һәм аларны сәхнәдә куюга зур өлеш кертә. Камалның пьесалары Казан театрлары сәхнәләрендә бара һәм хәзер дә популяр. Без гаиләбез белән Казанга баргач, Галиәсгар Камал театрына бармыйча калмыйбыз. Аның театрларын бик яратып карыйбыз. Үзебезгә ниндидер зур көчләр туплап, дулкынланып кайтып китәбез. Һәм тизрәк тагын шул мизгелләр җиткәнен көтә башлыйбыз.

Безнең мәктәптә дә Галиәсгар Камалга багышланган төрле чаралар үткәрелә. Аның пьесаларын укучылар бик теләп башкаралар. Кичәләр бик нәтиҗәле үтә. Еш кына китапханәдә китап күргәзмәсе куела, китап укучылар белән язучының тормыш юлы һәм иҗаты турында фикер алышына, китаплары укырга тәкъдим ителә. Безнең мәктәптә туган тел дәресләрендә дә аның иҗатына зур урын бирелә. Укытучы апа аның хезмәтләреннән өзекләр күрсәтә. Без бик яратып карыйбыз һәм үзебезгә тормыш өчен кирәкле тәҗрибә алабыз.

Галиәсгар Камал 1900 нчы елда үзенең “Бәхетсез егет” дигән тәүге драмасын бастыра. 1906нчы елда ул тәрҗемә иткән “Кызганыч бала” пьесасы

буенча Казанда беренче мәртәбә ачык спектакль уйнала. Актер һәм драматург буларак ул “Сәйяр” труппасы эшчәнлегендә дә шактый катнаша. 1905нчы елгы беренче рус революиясе Галиәсгар Камалның мәдәният эшчәнлеге һәм әдәби иҗаты киңәюгә зур этәргеч була. Бу елларда ул үзенең иң көчле, сәнгатьчә иң камил булып саналган “Беренче театр”, “Банкрот” пьесаларын иҗат итә.

Галиәсгар Камал Гогольнең “Женитьба”, “Ревизор”, Островскийның “Гроза”, М.Горькийның “На дне” әсәрләрен бик уңышлы тәрҗемә иткән. Минемчә, Камал бик акыллы, уңган һәм яхшы кеше булган. Хәзерге көндә дә мондый талантлы кешеләр булса иде. Аның хезмәтләре бүгенге көндә дә үз урынын югалтмаган. Казандагы Галиәсгар Камал театры тамашачылардан өзелми. Анда һәрвакыт зал тулы була. Әгәр дә без яшьләр театрларга ешрак йөрсәк,татар халкының гореф–гадәтләрен, тормыш–көнкүрешләрен яхшырак белер идек. Бу безнең милләтебезгә карата булган мөнәсәбәтебезне дә, уңай якка үзгәртә һәм яшь буынга милли тәрбия бирә.

**Әдәбият**

1. Галиәсгар Камал: тәрҗемәи хәле, истәлекләр, әсәрләр, анализ үрнәкләре, дәрес эшкәртмәләре/ төз. Т.Р. Шакирова. – Казан: Татар. кит. нәшр.,2014.– 224б.

2. Галиәсгар Камал. Әсәрләр:3 томда. 1том. Пьесалар /Г.Камал; Б.Гыйззәт. Г. Камалның революциягә кадәргә иҗаты б.341–356.– Казан: Татар. кит .нәшр., 2010.– Б. 341-356.

## ЭКОЛОГИК ТӘРБИЯ БИРҮНЕҢ ПЕДАГОГИК НИГЕЗЛӘРЕ

Арсланова А.Ф.,
КФУның Алабуга институты студенты.
Фәнни җитәкче Камаева Р.Б.

Иҗтимагый аң формасы буларак экология фауна һәм флора эчкедә, аларның вәкилләренең үзара һәм әйләнә-тирә мохит белән үзараа бәйләнешләренең законлылыгын өйрәнүче биологик фәннең бер өлеше булып тора. Табигать – кешенең яшәү тирәлеге. Кеше табигатьтә бөтенлекне, чисталыкны, гармонияне саклау, биологик бәйләнешне бозуларны булдырмау белән кызыксына. Шуның белән бергә, үзенең актив үзгәртеп кору эшчәнлеге белән кеше табигый процессларга катнаша, аларны боза, табигать байлыкларын үз мәнфәгатьләрендә кулланаӘгәр бу эшчәнлек контрольсез, экологик законнарны һәм табигый ресурсларны яңартудан башка барса, табигатьтә кеше гомеренә куркыныч янаучы процесслар тудыра торган төзәтмәслек зыян китерелергә мөмкин. Гомумкешелек масштабтагы шулай ук региональ экологик проблемалар бар. Бары тик бөтен дөнья җәмәгатьчелеге тырышлыгы белән генә атмосфераның чисталыгын саклап калырга, Дөнья океанын пычратудан саклап калырга, җир асты байлыкларын куллануны акыл белән җайга салырга, аларның тулысынча бетүенә юл куймаска мөмкин. Шуның

белән бергә һәр аерым ил үз төбәгендә әйләнә-тирә мохитне саклау турында кайгырта ала һәм һаваның чисталыгын күзәтеп торырга, урманнарны, үсемлекләрне, хайваннарны юк итүгә каршы көрәшергә, елгаларны һәм сулыкларны пычратмаска, игенчелек культурасына һәм туфракны саклауга ярдәм итәргә тиеш.

Табигать кешеләр өчен белем һәм эстетик мөнәсәбәтләр объекты булып тора. Аның күренешләре эстетик яктан камил һәм эстетик яктан камил кешегә тирән рухи ләззәт бирә. Аның серләренә үтеп керү фәнни дөньяга караш формалаштыруга ярдәм итә. Моның белән кешенең экологик культурасына нигез салучы гомуми, мәҗбүри, башлангыч экологик тәрбия бирүне гамәлгә ашыру зарурлыгы аңлатыла.

“Экологик тәрбия – балаларга экологик белем һәм тәрбия бирүне үстерүгә юнәлтелгән максатчан системалы педагогик эшчәнлек. Экологик белемнәр туплау, табигатьтә эшчәнлек күнекмәләрен формалаштыру, югары әхлакый-эстетик хисләр уяту, табигать саклау эшен башкаруда югары әхлакый сыйфатлар һәм ныклы ихтыяр алудан гыйбарәт” [Лихачев 1998: 19-21].

Үзенең «Шәхес экологиясе» мәкаләсендә күренекле педагог Б.Т.Лихачев ул алга киткән аң, эмоциональ-психик халәтләрнең бердәмлеге каралырга мөмкин булган «җәмгыять шәхесе һәм мәдәнияте экологиясе» дигән төшенчәнең эчтәлеген ача. Кешенең табигатькә, җәмгыять тормышына фәнни нигезләнгән кертүне гарантияләүче анализ-синтез сәләтенә аеруча юнәлдерелгән мондый аңның үзәге булып аларның тигезлеген саклап калу күз алдында тора. Кешенең экологик культурасы тулаем шәхес һәм аның төрле яклары, сыйфатлары белән тыгыз бәйләнгән, ул яңа белем буларак барлыкка килә. Табигый фәнни белемлелек табигатьнең закончалыкларын, аның белән кеше арасындагы элемтәләрне белүне тәэмин итә. Фәлсәфи караш кешенең билгеләнешен аңларга мөмкинлек бирә. Сәяси-хуҗалык эшчәнлеге һәм табигый ресурслар арасында тиешле тигезлекне тәэмин итә. Әхлакый мөнәсәбәтләрне рухландыра. Хезмәт һәм хуҗалык эшчәнлеге кешенең тырышлыгын табигать саклау максатына юнәлтә.

XX гасыр ахыры чынбарлыкларында чагылыш тапкан шәхес культурасын мондый киң аңлау кайбер чиктәш фәнни юнәлешләрне үстерүне күздә тота. Алар арасында академик Б.Т. Лихачев экологик психология һәм педагогика, экологик психофизиогигиена кебекләрне аерып чыгара. Беренчесе табигатьнең бер өлеше булып үзен аңлый һәм хис итә, үзара файдалы, үзара сәламәтләндерә торган бәйләнешкә мотивация формалаштыру һәм урнаштыру формалаштыруны тәэмин итә торган психик халәтләрнең формалашуын һәм үсешен өйрәнүдә үзенчәлекле фән. Бәлки, ул махсус фәнни дисциплина буларак, экологик юнәлешле педагогика өчен, заманча яңгырашта табигать барлыкка китерү принцибына мөмкин кадәр җавап бирүче эзләү юнәлеше өчен нигез булыр. Алар базасында баланың яшәү рәвешен оештыру, экологик тигезлекне (үсештә тоткарлану, хайваннарга карата агрессивлык һәм рәхимсезлек һ.б.) бозуга бәйле кризис күренешләрен бетерү буенча тәкъдимнәр

эшләнергә мөмкин. Педагоглар экологик терапия һәм баланың биологик һәм психологик яктан уңайлы яшәү мохитенә әйләнеп кайту юлларын һәм чараларын эшләү кирәклеген сөйлиләр, психика һәм гомумән организмның нормаль эшләвен киеренкелек тудыра торган махсус уен, иҗади, эшлекле аралашу ситуацияләрен тәкъдим итәләр. Академик Б.Т. Лихачев билгеләп үткәнчә, экологик аң табигатькә, җәмгыятькә, кешеләргә эмоциональ бербөтен, тирән әхлакый караш белән ныгытуны таләп итә. Баланың барлык әхлакый юнәлеше мәхәббәт, вөҗдан дулкынлануы, табигать һәм кешеләр белән аралашу кебек хис-тойгыларны һәм халәтләрне үстерүгә юнәлдерелгән булырга тиеш. Табигать гадел, ул яхшылык һәм явызлык ягыннан аның бөеклеге һәм тынычлыгы анда үз урынын аңларга ярдәм итә. Гармония, соклану, соклану хисен үстерергә кирәк.

Педагоглар билгеләп үткәнчә, шәхеснең экологик культурасы аның чынбарлыкка практик мөнәсәбәтеннән тыш, ул укытучылар һәм укучыларның уртак тырышлыгы нигезендә формалаша. Сүз табигатькә, ноосферага, җәмгыять тормышына экологик нигезләнгән рәвештә кертүгә ышанычлы психологик җайланма булдыру турында бара. Бу баланың үз табигатен, аның сәләтен, физик һәм интеллектуаль көчен үстерү, хезмәт сөючәнлек, сакчыл мөнәсәбәт, булдыклылык һәм хуҗалык белән бәйле булырга тиеш.

Шулай итеп, хәзерге шартларда экологик культура шәхеснең алдынгы компонентларының берсе булып тора. Ул чын зыялылыкка һәм цивилизациягә ия булган төп система барлыкка китерүче фактор буларак карала ала.

**Әдәбият**

1.Заһидуллина Д.Ф. Урта мәктәптә татар әдәбиятын укыту методикасы. – Казан: Мәгариф, 2000. – 335 б.

2.Лихачев, Б.Т. Педагогика. Курс лекций. – М.: Прометей, Юрайт, 1998. – 464с.

3.Подласый И.П. Педагогика. Новый курс: учеб. для студентов вузов: в 2 кн. – М.: Гуманитар. изд. центр ВЛАДОС, 2006. – Кн. 2. Процесс воспитания. – 256 с.

4.Хуҗиәхмәтов Ә.Н. Гомуми педагогика: педагогик уку йортлары, коллиятләр, гимназияләр, лицейлар өчен уку әсбабы. – Казан: “Матбугат йорты” нәшрияты, 1999. – 504 б.

5.Экология. Википедия. – URL: https://ru.wikipedia.org/wiki/ Экология (мөрәҗәгать итү датасы: 16.10.2023).

# ПОЛИЛИНГВАЛЬ БЕЛЕМ БИРҮ ШАРТЛАРЫНДА ТАТАР ТЕЛЕ ҺӘМ ӘДӘБИЯТЫН УКЫТУ

Богаутдинова Д.А.,
"Г.Тукай исемендәге Арча педагогия көллияте" нең 411 төркем студенты.
Фәнни җитәкче: Гыйләҗева А.Ф.

Соңгы елларда Россиядә алып барылган мәгариф системасын модернизацияләү милли мәгарифнең гомумроссия бердәм мәгариф системасында тоткан урынын үзгәртте. Республикабызда милли мәгарифнең торышына, үсешенә, киләчәгенә бик зур игътибар бирелә, дәүләткүләм мөһим эшләр башкарыла. Милли мәгарифнең эчтәлеген яңарту, белем бирү методикасын һәм технологияләрен яңа таләпләр нигезендә камилләштерү, республикада милли мәгарифнең нәтиҗәле үсешен тәэмин итүче мониторинг механизмнарын, коралларын булдыру максатыннан, «2030 нчы елларга Татарстан Республикасында Милли мәгарифне үстерү Концепция»се кабул ителде.

Арча районының барлык мәктәпләрендә татар, рус телләре, дәүләт телләре буларак, Федераль дәүләт белем бирү стандартлары кысаларында өйрәнелә. Дәүләт телләреннән тыш, барлык уку оешмаларында чит телләр (инглиз, француз) укытыла. Әйтергә кирәк, районда (полилингваль) күптелле белем бирү системасы барлыкка килде. Заманча мәктәп төрле телләрне өйрәнүдә, шәхес тәрбияләүдә зур урын алып тора. Һәм шуны ассызыклап үтәргә кирәк: мәктәп–гимназияләрдә күп тел укыту туган телдә белем алуга һич комачауламый.

Татарстан Республикасында полилингваль мәктәпкәчә белем бирү концепциясе формалаша. Республикада заманча белем бирү комплексы моделе булдырылырга тиеш. Әлеге комплекста уку–укыту процессы кимендә өч телдә – татар, рус, инглиз телләрендә алып барылачак.

Полилингваль белем бирү шартларында татар теле һәм әдәбиятын укытуны нинди методик юллар, инновацион технологияләр белән камилләштереп була?

Безнеңчә, бары тик яхшы әзерлекле укытучы гына белем бирүне югары дәрәҗәдә алып барырга, укучыларда тыңлап аңлау, сөйләү, уку, язу өлкәсендә ныклы белем һәм күнекмәләр булдырырга сәләтле икәнлеген аңлыйбыз. Шулай итеп, инновацион технологиянең төп максаты – укучының белем алу эшчәнлеген активлаштыру. Элегрәк укытучы яңа теманы бик матур итеп сөйли, ә укучы бары гади үзләштерүче ролен үти иде. Бүген исә, укучы яңа теманы үзе эзләүче, тикшеренүче сыйфатында үзләштерергә тиеш дип карала. Укытучы бу очракта укучыларның актив фикерләү эшчәнлеген, акылын, зиһенен үстерү өчен юнәлеш бирүче, әйдәп баручы ролен үти. Хәзерге шартларда, мәгълүматның күләме тиз үскән вакытта, кирәген сайлап ала белергә, тәртипкә китерергә, бәләкәй генә ачыш ясап куана белергә өйрәтү, юл күрсәтү – уку-

укыту өчен авыр эш. Укучы теманы уйлап, фикерләп, эзләнеп аңлый икән, әлбәттә, аның белеме ныклырак, төплерәк була. Мәктәптәге традицион, бер төрле үткәрелгән дәресләр арасында, гадәти булмаган дәресләр үткәрү укучыларның хәтерендә ныграк кала. Ялыктыргыч эш төрләрен һәр дәрестә кат-кат башкаруга караганда, кызыклы ачышлар булганы укучының күңеленә тәэсир итә, аң–белемен киңәйтә, иҗади эзләнүгә теләк тудыра. Шуңа да соңгы вакытта укучының белем сыйфатын күтәрүдә, иҗади сәләтләрен үстерүдә яңа технологияләрне өйрәнү һәм дәрестә куллану турында күп сөйләнелә, языла. Хәзер укытучы алдында җаваплылык артты: мәктәптә укытылган дистәләгән фәннәр арасында балага татар телен абруйлы итеп өйрәтү, шушы фәнгә карата гомер буена җитәрлек горурлык хисе тәрбияләү, туган тел матурлыгын онытылмаслык итеп күңеленә сеңдерү. Дәрес шәхес күңелен кузгатырлык булырга тиеш. Заманча технологияләр белән эшләү укытучының үз эшенә иҗади якын килүен дә таләп итә. Мөгаллимнән үз шәхесенә тәнкыйть күзлегеннән карау, яңалыкка омтылу, заман сулышын тоеп эшләү сорала.

Бүгенге балалар мәгълүмати технологияләр белән бик иртә таныша. Хәзер балалар бакчасында ук заманча технологияләрне үзләштерү мөмкинлеге тудырылган. Әгәр дә элек мәктәп баласы өчен мәгълүмат чыганагы булып китап һәм мөгаллим торса, бүген ул барлык кызыксындырган сорауларга җавапны интернет челтәре аша да таба ала. Шуңа да хәзерге педагоглар үсмерләрне үз фәне белән кызыксындыру өчен, яңа технологияләрне кертеп җибәрү – бүген көн тәртибенә куелган мәсьәлә. Хәзерге көндә мәгълүмати белем чыганаклары уку–укыту системасында аерылгысыз бер тармак булып тора.

Шулай ук дәресләрдә Интернет ресурсларны куллану гаять зур мөмкинлекләр бирә. Интернет челтәре укучыга һәм укытучыга кирәкле мәгълүматны җир шарының төрле ноктасыннан эзләп табу шартларын тудыра. Татар теле дәресендә интернет ярдәмендә уку, язу күнекмәләрен булдыру һәм үстерү, кирәкле материал табу, укучыларның сүзлек запасын баету, татар телен өйрәнүгә мотив формалаштыру кебек дидактик бурычларны үтәргә мөмкин. Укучылар интернет челтәрендә үткәрелә торган тестларда, викториналарда, конкурсларда, олимпиадаларда катнаша, яшьтәшләре белән аралаша алалар. Педагогика фәнендә укыту–тәрбия процессы сыйфатын үстерергә булышлык итүче технологияләр бик күп. Укытуның һәр этабы өчен уку материалын аңлатуның иң уңышлы вариантын табу – укытучының бурычы.

**Әдәбият**

1. Харисов Ф.Ф. Татар теле буенча мөстәкыйль эш төрләре һәм күнегүләр.–Казан, 1994.

2. Портал для учителей http://www.teacher–rt.ru/index.php/biblioteka Дата обращения: 06.02.2024.

**ФОЛЬКЛОР ТЕКСТЛАРЫНДА КАБАТЛАУЛАР**

Борһанова Л.И.,
КФУның Алабуга институты студенты.
Фәнни җитәкче: Камаева Р.Б.

Халыкның телдән сөйләнә торган поэтик әсәрләре халык авыз иҗаты яки фольклор дп атала. Халык авыз иҗаты әсәрләренә җырлар, такмак-такмазалар, экиятләр, мәкальләр, әйтемнәр, табышмаклар, мәзәкләр һ.б. керә [Хәсәнова 2014: 12].

Фольклор текстларында сәнгатьле сурәтләү алымы буларак кабатлаулар еш очрый.

*Гади кабатлау* – бер үк сүзне яки фразаны бер үк җөмләдә яисә берничә җөмләдә бер-бер артлы яки төрле-төрле урында берничә тапкыр куллану [Курбатов 2002: 147].

Текстларда кулланылган гади кабатлауның берничә төрен аерып күрсәтергә мөмкин.

1.*Бер юлда сүзләрнең кабатлануы:*

*Дусның дуслыгы өч* көннән түгел, *өч* елдан соң беленер.

*Тимерне тимер* көрәп чыгара.

*Такта* чиләкне *такта* капкач белән каплыйлар.

*Кеше кешегә* бик кирәк.

*Берәү* белмәгәнне *берәү* белер.

*Үз* эшеңә *үзең* җавап бир.(Мәкальләр)

2. *Сүзләрнең берничә җөмләдә бер-бер артлы кулланылуы.*

Борын-борын заманда *булган, ди*, бер урта хәлле крестьян. *Булган, ди,* моның өч улы. Шуларның кечесе Тиле *булган, ди.* (“Ак байтал”экияте)

2.*Сүзләрне һәм җөмләләрне кире кабатлау:*

*Заман сиңа* иярмәсә,

*Син заманга* ияр.

*Заман сиңа* буен куймас,

*Син заманга* буең куй.

*Чүлмәк ташка бәрелсә дә, таш чүлмәккә бәрелсә* дә, вай чүлмәккә.

*Эшлә дигәндә эшләмәсәң,*

*Эшләмә дигәндә эшләрсең.*

*Табак килсә, сабак куй,*

*Сабак килсә, табак куй.* (Мәкальләр)

*Анафора* дип шигырь юлы яки җөмлә башында кабатлана баручы сүзләрне, тезмәләрне атыйлар [Хатипов 2000: 132]. Мәкальләрдә анафора күренешенең төрле формасы күзәтелә.

1.*Бер үк сүзләрнең юл башында кабатлануы:*

*Ир* бакканны ил баккан,

*Ир* какканны ил каккан.

*Илдә* булса – үлмәссең,

*Илсез* көн күрмәссең.
*Каләм* өйрән, *каләм* изгегә тартыр,
*Каләм* тоткан кешенең зиһене артыр.
*Акылың* булса, *акылга* ияр,
*Акылың* җитмәсә, мәкальгә ияр. (Мәкальләр)
2. *Бер үк тезмәләрнең кабатлануы:*
*Дусы күп кеше* дала кебек киң,
*Дусы юк кеше* уч төбе кебек
*Кеше булыр* баланың
*Кеше белән* эше бар,
*Кеше булмас* баланың
*Кеше белән* ни эше бар?
*Бу бик яхшы укучы,*
*Бу бик яхшы укучы,*
Аның укуы яхшы
Аннан үрнәк алыгыз. (Җыр)
3. *Тамырдаш сүзләрнең, сүз формаларының кабатлануы:*
*Сер* дусы күп булыр,
*Серне* тоткан бер булыр.
*Көчсез* калып изелгәнче,
*Көчәнеп* из дошманны.
*Илдә* булса – үлмәссең,
*Илсез* көн күрмәссең.
*Тилене генә* тыңлый. *Тилегә генә* буйсына (Әкият)

*Эпифора* – анафораның нәкъ киресе. Эпифора сүзләрнең, тезмәләрнең җөмлә яки тезмә ахырында кабатлануын аңлата (грекча epi + phoros "ахырдан килүче" дигәнгә туры килә) [Хатипов 2000:134].

Илдә илле *дустың булсын,*
Кырда кырык *дустың булсын.*
Сер дусы күп *булыр,*
Серне тоткан бер *булыр.*
Җәйнең күрке яр *булыр,*
Ярның күрке тал *булыр.*
Тау бүресез *булмас,*
Ил угрысыз *булмас.*
Яз яме чәчкә *белән,*
Көз яме көлтә *белән.*
Күз өчен яз *яхшы,*
Авыз өчен көз *яхшы.*
Аяклыга юл *бирмәс,*
Авызлыга сүз *бирмәс.*
Тешләшкән атның артыннан *үт,*
Тибешкән атның алдыннан *үт.* (Мәкальләр)

*Ялгау.* Синтаксик фигура, анафора белән эпифора арасындарак тора; ягъни бер җөмләнең тезмәнең ахырында һәм икенчесенең башында кабатланып килүче сүзләрне *ялгау* дип атыйлар, чөнки алар, беренчесенең ахырында икенчесенең башында килеп, ике җөмләне ялгап куялар [Хатипов 2000: 135].

Шушы ук синтаксик күренешне Х.Курбатов *акромонограмма,* ягъни *эпанафора* дип атый.

*Акромонограмма.* Яңа шигырь юлын аңа кадәрге шигырь юлының азагы белән башлап китү *акромонограмма* (грекча akros кырый, югары, бер үк, язу) яки *эпанафора* (азактагыны башта кабатлау) дип атала [Курбатов 2002:149].

Иле юкның *икмәге юк,*
*икмәге юкның* түшәге юк.
Улың белән *җорланма,*
*Җорлансаң* улың сине елатыр.
Эшне *башлама,*
*Башласаң,* ташлама.
Чүп җыйсаң – *чүмәлә,*
*Чүмәлә* җыйсаң – богыл.
Ерактыр да – *якындыр***,**
*Якындыр да* – ялкындыр.
Байның алты йорты *бар***,**
*Бар* булса да өе тар.
Кунак килсә *ит пешә,*
*Ит пешмәсә* бит пешә. (Мәкальләр)
Бирәү *бар* –
*Бар* икәне дә билгесез.(Әйтем)
*Ул дәрья да бу дәрья,*
*Ул дәрьядан Сыр-Дәрья,*
*Сыр-дәрьядан – Сәмәрканд,*
*Сәмәркандка* утырган
Әмир Бырлас Шаһ Тимер.(Дастан)

*Эпистрофа.* Строфаның бер үк сүз яки сүз тезмәсе белән башлануы һәм бетүе *эпистрофа* (кире борылу, әйләнү) яки *анэпифора* (баштагыны азакта кабатлау) дип атала [Курбатов 2002:148].

*Аз* ашның хәсрәте дә *аз.*

**Әдәбият**

1. Курбатов, Х.Р. Сүз сәнгате: Татар теленең лингвистик стилистикасы һәм поэтикасы. – Казан: Мәгариф, 2002. – 199 б.
2. Татар әдәбияты: рус телендә төп гомуми белем бирү оешмалары өчен д-лек (татар телден туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен) 5нче с-ыф. Ике кисәктә: 1 нче кисәк / Ф.Ф.Хәсәнова, Г.М. Сафиуллина, М.Я.Гарифуллина. – Казан: “Мәгариф-Вакыт” нәшр., 2014. – 143 б.
3. Татар халык авыз иҗаты. Мәкальләр һәм әйтемнәр / Төз. Х.Ш.Мәхмүтов. – Казан: Татар. кн. изд-во, 1987. – 501 б.

4. Хатипов, Ф.М. Әдәбият теориясе. – Казан: Мәгариф, 2000. – 351 б.

## ХӘЗЕРГЕ ХИКӘЯ ЖАНРЫ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ

Вәлиева В.И.,
КФУның Алабуга институты студенты.
Фәнни җитәкче: Габидуллина Ф.И.

Татар әдәбияты мәйданында узган гасыр башыннан алып лаеклы урын алган хикәя жанры бүген дә актив үсешен дәвам итә. Алар әдәбияттагы гомуми тенденцияләрне чагылдыралар, авторларның заманның актуаль проблемаларына мөнәсәбәтен, милли-мәдәни, тарихи, икътисади әхлакый вазгыятькә мөнәсәбәтен чагылдырала. Һәр язучының, һәр хикәя остасының яратып мөрәҗәгать итә торган үз тематик киңлеге булуга карамастан, өстенлек иткән темаларны аерып чыгарырга була.

Халкыбызда дин һәм милләт темасы һәрдаим актуальлеккә ия. Дөрес Советлар чорында, сәяси вазгыятькә нисбәтле рәвештә, дини тема бөтенләй инкарь ителә яисә дини хорафатлардан көлү, аларны фаш ит, мыскыл итү тенденциясен ала, әмма XX йөзнең сиксәненче – туксанынчы елларында ук ул әдәбиятка кире кайта башлый һәм бүгенгәчә җәмгыятьнең йөзе, әхлагы, алгарышы дин һәм иманга бәйләп аңлатыла. Әлбәттә, күп кенә хикәяләрдә ислам дине, ислам әхлагын саклау идеясе алгы планга чыга, әмма тулаем алганда әдипләр һәр диннең дә үзәгендә гуманлылык хисе ятуын ассызыклыйлар. Бу яктан Айдар Хәлимнең "Ыгдыбыгды чокыры" хикәясе үзенчәлекле. Биредә милли-дини тема белән гуманистик идеаллар яктыртыла, тарихи хәтер проблемасы күтәрелә. Әсәр геройлары – марҗа әби Анна Афанасьева һәм аның ахирәте-күршесе Гайния карчык. Айдар Хәлим авылдашларның авыр тормыш шартларында бер-берләренә терәк булуын ассызыклый. Бу бигрәк тә Анна Афанасьева йорттагы бердәнбер якынын – Василиса кушаматлы кәҗәсен югалту вакыйгасында ачык чагыла. Ыгдыбыгды чокырында бүреләр тарафыннан таланган Василисаны алар бергәләп соңгы юлга кадерләр, һәрберсе үз дине догаларын укып озаталар. Хикәя тукымасына шушы чокырга бәйле истәлекләр кереп килә. Гайниянең тормыш иптәше Гали, 1942 нче елларда Алкин лагерендә сугышка әзерлек иткән җирләрдән качып кайта. Сәбәбе дә куркаклыкта түгел: әзерлек урынына кешелексез шартларда, чатнама суыкта җылы киемсез эшләү, землянканың күпме ягып та җылынмавы, командирларның рухи көч бирү урынына мәсхәрә итүләре... Шулай итеп, гади сюжет тарихы чынбарлыкны ачу, сугыш чорындагы аерым сәхифәләрне киң җәмәгатьчелеккә тарату белән дә үрелеп бара.

Милли тема Галимҗан Гыйльмановның "Бүреләр һәм Иоһанн Себастьян Бах" хикәясендә кызыклы чагылыш таба. Биредә кеше нинди генә уңышка ирешсә дә, туган телеңне белү кирәк, дигән идея үткәрелә.

Хәзерге хикәяләрдә фәлсәфи мотивлар да урын ала. Галимҗан Гыйльмановның "Похоронка" хикәясе – шундыйлардан. Әсәр үзәгендә – инде

күптән үлем яшенә җитеп тә, бар авылга кирәк булып, кадерле булып яшәүче Гыйльман карт, Ак бабай. Хикәядә Туфан Миңнуллинның “Әлдермештән Әлмәндәр” атаклы драмасы белән дә интертекстуаль бәйләнешләр ачык сизелә. Драматург әсәрендә Әлдермеш артыннан Әҗәл килсә, Ак бабай артыннан Әҗәл похоронка кәгазе рәвешендә килә. “Похоронка” мотивы әсәрдә берничә тапкыр кабатлана. Ак бабайның үзе хакында да кайчандыр хатынына ялгыш похоронка килгән, Кытай чикләрендә хезмәт иткән улларының үлемен дә бу кара кәгазь хәбәр иткән. Нинди генә авырлыклар булмасын, Ак бабайның сакраль көче – авылда һәр кешегә кирәкле булып яши белүендә. Үсмерләргә-яшьләргә атларны Сабан туена әзерләүдә булыша, кемгәдер гаилә тормышы турында кыйммәтле киңәшен бирә, кемнедер печән чабарга өйрәтә. Хәтта Әҗәл үзе дә “Вакытың чыккан, гомерең чыкмаган” дип Ак бабайны үзе белән алып китми [Гыйльманов, 2014: 269].

Хәзерге вакытта хикәяләрнең тагын бер үзенчәлекле ягы буларак фэнтези, мистика алымнарына мөрәҗәгать итүне атарга була. Әйтергә кирәк, мондый тенденция гомумән әдәбиятка хас. Европа, рус әдәбиятында мондый жанрлар актив иҗат ителә, татар әдәбиятында бу алымнарны берничә әдип кенә актив кулланыла, шул исәптән Галимҗан Гыйльманов, Марат Кәбиров кебек исемнәрне атарга була. Мәсәлән, Галимҗан Гыйльмановның “Юл читендәге авыл” хикәясендә автор тарафыннан хикәя герое Гайнанның машинага утырып баруга битараф булуы, җәяү йөрергә, аеруча йөгерергә яратуы ассызыклана. Гайнанның әнисенең болай сөйли: “Гомумән, йөгерергә ярата иде. Әнисе дә: “Канатың бардыр синең, балакаем, бу хәтле очып йөрмәс идең”, – ди иде...” [Гыйльманов, 2014: 352]. Әлеге факт үзе үк хикәя каһарманының бер дөнья кешесе генә булмавына ишарә итә. Техникага битарафлык, юлга тартылу, очу халәтенә тиңләштерерлек йөгерергә һәвәслеге аның гади кеше булмавы, алда сихри вакыйгаларга тарачагын, әйтерсең лә алдан хәбәр итә. Алга таба сюжет үстерелешендә дә Гайнанның башка дөнья кешеләре белән аралаша алуы тасвирлана, ә әсәр ахырында гомумән ул “Шәһәрдәге йорт-җирен сатып, автобус алып кайткан Гайнан Кариле белән пристань арасында кеше ташып кәсеп итә башлады. Кайчагында ялгызы гына чыгып китеп, ялгызы гына кайтып керә. Кешеләр баштарак бу хәлгә аптырыйлар иде, соңрак күнектеләр тагы: “Кайда гына йөрмәс сагышлы адәм белән чабышкы ат башы?!” [Гыйльманов, 2014: 362]. Монда инде автор грек мифологиясе белән интертекстуаль бәйләнешләр хасил итә, Гайнан беркадәр Стикс елгасы аркылы җаннарны үлеләр дөньясына ташый торган мифологик Харонны хәтерләтә. Мистик-мифологик мотивлар әдипнең “Пәйгамбәрләр күпме яши?”, “Җан сурәте” кебек әсәрләрендә дә чагылыш таба.

Әлбәттә, хәзерге хикәяләрдә дә традицион темалар актив яктыртыла. Аталар һәм балалар мөнәсәбәте, мәхәббәт, табигатькә сакчыл караш, әхлакый кагыйдәләрне саклау кебек темалар да хәзерге әдәбиятка чит түгел, һәм хикәяләрдә дә алар яктыртыла.

Нәтиҗә ясап, шуны әйтергә кирәк: хәзерге хикәяләр бигрәк тә фәлсәфи темаларны колачлый, шулай ук милли һәм шуңа бәйләнешле дини мотивлар белән баетылган әсәрләр еш очрый. Хикәяләр, әдәбият дөньясындагы тенденцияләргә сизгерлек күрсәтә. Биредә дини-мифологик, мистик, фэнтези алымнары иркен кулланыла.

**Әдәбият**

1. Гыйльманов Г. Тәкъдиргә юл: хикәяләр, новеллалар. – Казан: Рухият, 2014. – 448 б.
2. Хәлим А. А. Кыйбла: хикәяләр, новеллалар. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2005. – 382 б.

## “ТЕАТР – ЯКТЫЛЫККА, НУРГА ИЛТӘ, КИРЕ ЮЛГА ҖИБӘРМИ, УҢГА ИЛТӘ”

Газимова Р.И.,
Алабуга шәһәренең 8 урта мәктәбе укучысы.
Фәнни җитәкче: Якупова Ф.М.

Галиәсгар Камал – татар әдәбияты классигы, талантлы драматург, үзенчәлекле шагыйрь, журналист һәм җәмәгать эшлеклесе. Ул гаять зур иҗади мирас калдырган. Әдип утыздан артык сәхнә әсәре, йөздән артык шигырь – поэма, хикәя, публицистик һәм тәнкыйди мәкалә язган; ул күпсанлы пьесалар тәрҗемә иткән, матбугатыбыз тарихында күренекле роль уйнаган газета – журналларны оештырган һәм аларны җитәкләгән, театр сәнгатебезнең аякка басып килгән чорында режиссёр һәм артист буларак та, сәхнәне бизәүче сыйфатында да хезмәт куйган. Аның иҗат җимешләре бүген дә үз кыйммәтен саклый. Аерым пьесаларының һаман да сәхнәләрдә уйналуы, дәреслекләрдә төпле урын алуы, татар сәхнә сәнгатенең флагманы булган театрның аның исемен йөртүе (Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры ), әсәрләренең басыла торуы шул хакта сөйли }Мортазин 2022: 133}.

Татарның театры булмаган, аны ачарга дин әһелләре тешләре – тырнаклары белән каршы торганда, Г. Камал ничек драматургия өлкәсенә кереп китәргә җөрьәт иткән соң? Бер шәкертнең абыйсы Истанбулдан тотылган төрек әдәбиятын алып кайта. Алар арасында Нәмык Камалның “Зәваллы чожук” драмасы да була. Г.Камал аны төрек теленнән татар теленә тәрҗемә итә. 1911 нче елда Г.Кариев җитәкчелегендәге театр труппасы Шәрык клубында төпләнгәч, Камал артистларның иң якын дустына гына түгел, труппаның иң беренче ярдәмчесенә, терәгенә әйләнә.Ул театрга әсәрләре белән генә түгел, уеннары, киемнәре белән дә ярдәм итә. Оештыру эшләрендә, спектакльләр кую өчен рөхсәт алу, акча табу, кием – салым җыю, декорацияләр булдыруда булышлык итә, хәтта афишаларны үз кулы белән яза. Үз әсәрләрен куйганда, режиссёрларга ярдәм итә. Театр тудыруда, булдыруда аңа бөтен туганнары, гаиләсе дә ярдәм күрсәтә. |Мортазин 2022: 133 |.

Яңалыкка омтылучан, талантлы шәхес – Г. Камал мәдрәсәдә укыган елларында ук әдәбият һәм театр сәнгате белән кызыксына, курчак, рус театрларына йөри, сәхнә өчен язылган китапларны укый. Бигрәк тә Г.Ильясиның "Бичара кыз", Ф.Халидинең "Рәдде бичара кыз" әсәрләрен кат – кат укый һәм үзендә дә шундый китаплар язу теләге уяна.

1898 нче елда унтугыз яшьлек Галиәсгар беренче әсәрен – "Бәхетсез егет"не яза. Рус теле укытучысы Миргаяз Иманаевның киңәше буенча әсәрне Петербургка цензурага җибәрә һәм 1899 нчы елда (бер ел үткәч) басарга рөхсәт алып, әсәрне "Борадәрин Кәримевләр" басып чыгаралар | Ганиева 2004: 30 |.

1900 нче елда Г.Камал төрек теленнән "Кызганыч бала" драмасын тәрҗемә итә.Шушы елда "Өч бәдбәхет " исемле пьесасы да дөнья күрә .

1906 нчы елның 22 нче декабрендә татарның алдынгы фикерле яшьләре, укучылары Казанда "Кызганыч бала"драмасын сәхнәләштерә. Шулай итеп, татарның рәсми спектакле куела. Бу көн – татар милли профессиональ театрының туган көне.Әлбәттә, спектакль яшь драматургның зуртырышлыгы, ярдәме белән куела һәм бу көн тарихка кереп кала.

Профессиональ милли татар театры туу, үзенең әсәрен сәхнәдә күрү яшь драматургка канатлар куя, иҗат эшенә дәртләндерә, аның күңелендә яңадан – яңа әсәрләр язу теләге туа. Ул бөтен игътибарын, көчен, сәләтен татар театрын үстерүгә, яшәтүгә, яңа биеклеккә күтәрүгә багышлый. "Уйнаш", "Дәҗҗал", "Бәхетсез егет"нең икенче вариантын, "Өч бәдбәхет"нең үзгәртелгән вариантын", "Каенеш", "Көндәш ", "Өйләнәм – ник өйләндем ", Хафизәләм иркәм", "Өч тормыш", "Күзсез мастерлар", "Ахырзаман" драмаларын, "Беренче театр ", "Бүләк өчен " , " Банкрот ", " Безнең шәһәрнең серләре " исемле комедияләрен яза [Заһидуллина 2000: 259}.

"Беренче театр" комедиясендә Хәмзә бай һәм аның дуслары шәһәрдә татар театрын куйдыртмас өчен чабышып йөриләр. Кич белән Хәмзә бай өенә кайткач, гаиләсенең театрга киткәнлеген белә һәм аларны алып кайтырга дип, чыгып йөгерә, көлкегә кала.Бу үзенә күрә яңалыкның, алдынгы фикернең җиңүе, ә кара көчләрнең, байларның җиңелүе була.

Гомумән, Вәлинең зур монологларына игътибар итмәсәң, комедияне бер тында укып чыгасың. Һәрбер геройның эш – гамәлләре, үз –үзләрен тотышлары , сөйләшүләре, уй – фикерләре укучыда елмаю һәм геройга карата теләктәшлек итү хисләре тудыра. Аның уңышлы куелуы, популярлыгы шунда: Г.Камал "Беренче театр"комедиясен зур осталык белән язган. Бу комедияне сәхнәдә куймаган артистлар бик сирәк. Минемчә, яшь артистлар үзләренә сәхнәдә уйнау осталыгы дәресен нәкъ менә шушы әсәрне сәхнәләштергәндә ала.

Г.Камалның әсәрләрен укыгач, шул чорның тарихи вакыйгаларын, анда яшәгән кешеләрнен тормыш-көнкүрешен, яшәү рәвешен, холкын, хыял-омтылышларын, язмышларын күз алдына китерәсең, ә спекакль карауның өстенлеге шунда: син геройларны, аларның киемнәрен күрәсең, тавышларын ишетәсең, үз-үзләрен тотышына, холыкларына, эш- гамәлләренә игътибар

итәсең. Артистларның уйнавы шулкадәр синә тәэсир итә, хәтта син берничә көн шул геройларны уйлап йөрисең, аларның уйнауларына, эш-гамәлләренә бәя бирәсең, тормыштагы кешеләр белән чагыштырасың, аларның уртак якларын эзлисең һәм үзеңә нәтиҗә ясыйсың.

Шулай да, сәхнәдәге җанлы тормышны чынлап та күреп, ишетеп кабул итү, зал тулы тамашачылар белән бергәләп шатлык-кайгы, соклану-нәфрәтләнү, кызгану-үкенү һәм башка күп хисләрне кичерү үзе бер тамаша, үзе бер бәйрәм ул. Кайнап торган хис-кичерешләр диңгезендә "коенып", күңелләрне чистартып алу ул. Сөекле шагыйребез Габдулла Тукайның татар театры яши генә башлаган чорда, 1907 нче елда язган "Театр" шигырендәге юллар мәңгелек хакыйкать булып яңгырый:

Театр – яктылыкка, нурга илтә,
Кире юлга җибәрми, уңга илтә.
Театр көлдерәдер, уйнатадыр,
Тагын үткән гомерне уйлатадыр.

Шагыйрь әнә шулай тетар дигән серле һәм сихри дөньяны күкләргә күтәреп мактый, аңа дан-мәдхия җырлый [Ганиева 2004: 6].

Шуны да әйтергә кирәк: Г. Камал язучы, драматург кына булып калмый, татар театрының атасы булуны да үз өстенә ала. Г.Кариев карамагында "Сәйяр"труппасы төзелгәч, труппага матди һәм рухи ярдәм итә.Г.Камалны артистлар "эткәй" дип йөртәләр. (Татарстанның атказанган артисты Касыйм Шамил Г.Камалга язган хатларында аны "мәгънәви атам" дип яза). Аның киңәшләрен тоталар, аны ихтирам итәләр[Ганиева 2004: 30 ].

Кайда да булса, нинди дә булса бер драма түгәрәге Г.Камал әсәрен куярга әзерләнеп, авторның үзен ярдәмгә чакырса, Г.Камал анда шатланып бара, түгәрәкнең эш процессларында һәр көн катнаша, режиссерлык итә, грим ясый, ярамаган җирләрен төзәтә, түгәрәк членнарының иҗат көчләрен күтәрүгә төрлечә ярдәм итә |Ганиева 2004: 30 |.

Г.Камал А.Островскийның "Яшенле яңгыр", Н.Гогольнең "Ревизор", М.Горькийның "Тормыш төбендә", Мольерның "Саран", "Ирексездән табиб", А.Дюманың "Чәчәкле хатын", Р.Тагорның "Һинд кызы" әсәрләрен тәрҗемә итә. Без барыбызда беләбез : тәрҗемә итү – бик күп көч, түземлек, белем, сәләт сорый торган өлкә. Бу эшкә сирәк кешеләр генә алына.

Хәзерге вакытта шунысы сөендерә: драматургның китапларын укучылар яратып укыйлар, драма һәм комедияләре театр сәхнәләрендә куела, Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры халыкка армый – талмый хезмәт итә, яңа театрлар туа, уку йортларында театр түгәрәкләре эшли. Гомумән, Г.Камал башлаган эш дәвам итә.

**Әдәбият**

1. Ганиева Ф.Ә."Татар классик драматургиясе: Галиәсгар Камал, Мирхәйдәр Фәйзи". – Казан: Татарстан Республикасы"Хәтер" нәшр., 2004.– 463б.

2. Заһидуллина Д.Ф. Урта мәктәптә татар әдәбиятын укыту методикасы: Метод.кулланма.– Казан:Мәгариф, 2000.–335 б.
3.Мортазин М.Г. “ 150 атаклы татар турында. Кызык та, кызганыч та”: Публицистик язмалар.– Казан: “Мәгариф– Вакыт” нәшр., 2022.– 384 б.

## ПИОНЕРИЯ – ОСТАЛАРЫБЫЗ БИОГРАФИЯСЕ

Гайнуллина З.Ш.,
Алабуга районы Иске Юраш мәктәбенең 7–сыйныф укучысы.
Фәнни җитәкче: Гайнетдинова К.Ф.

“Мин кем? Галәм күзлегеннән караганда, мин – кеше. Җиһан күзлегеннән караганда мин – татар, ягъни татар булуым мине бу җирдә яшәүче башка адәм затларыннан аерып торган иң беренче сыйфат”, – дип яза М. Маликова.

Анның бу сүзләре минем уйларымны ачып сала кебек. Әйе, мин дә – татар. Кояш тирәсендә әйләнүче планетабызның Татарстан иленең гади генә татар авылында яшәүче кыз мин. Мин 7 – сыйныфта укыйм. Бер уйласаң, мин шундый зур галәм киңлегенең тузан бөртеге кадәр кисәкчеге генә. Шуңа да карамастан, шушы зәңгәр күк гөмбәзе астында үз урынымны табып, газизләрдән – газиз булган туган телемә тугры булып, халкымның гореф – гадәтләрен югалтмыйча, авылымны онытмыйча, анның мәртәбәле, ихтирамлы, зур игътибарга лаек булган чын кешеләре белән горурланып, мөмкин булганча туган авылыма ярдәм итеп яшисем килә минем.

“Үсмер чак – кеше тормышының иң мөһим чоры, ул киләчәк тормышка әзерлек кенә түгел, бәлки чын, якты, үзенә генә хас, кабатланмас тормыш. Ә тормыш – мәңгелек корылыш. Тормышыңны мәгънәле итеп кору – һәркем үзе күтәрелергә тиешле биеклек,” – ди минем укытучым Клара Федоровна.

Бүгенге көндә төп эшем – уку. Укуда “4”, “5” билгеләренә генә өлгерәм, үз өстемдә эшлим: бик күп түгәрәкләргә йөрим. Мәктәбебездә “Тел күрке сүз” дигән иҗат берләшмәсе эшли. Мин шул иҗат берләшмәсенең “Туган як тарихын өйрәнү” түгәрәгенә йөрим. Бу түгәрәктә без туган ягыбызның үткәнен, бүгенгесен, анның ихтирамга, игътибарга лаек кешеләренең тормыш юлын өйрәнәбез. “Укытучы – остаз” елында мәктәп тарихын, анда укыткан 100 укытучының тормыш юлын өйрәндек. Өйрәнгән, язылган очерк – мәкаләләребез – барысы да мәктәп страничкасында урын алып бардылар. Без аларны тупладык, максатыбыз – китап итеп бастыру. Материаллар бүгенге көндә Чаллының “Ислам нуры” типографиясендә.Мин сезне шул китаптагы бер эзләнү – иҗат эшебез белән таныштырып китәсем килә. Ул – 60–70 елларда яшәп килгән пионер оешмасы турында.

Советлар Союзы вакытында Совет яшьләренең һәрберсе өчен кадерле булган октябрят, пионер, комсомол оешмалары эшләп килә. Безнең мөгаллим– мөгаллимәләребез, эти – әниләребез – шул чор балалары. Алар хәзер дә үзләренең балачак елларын сагынып искә алалар. Без, укытучы апам белән

бергәләп, шул елларда мәктәбебездә бу оешманың ничек эшләве белән кызыксындык. Бик күп остазларыбыз белән элемтәгә кердек. “Бәләкәй чакларыбызда бу оешмаларга керү зур бәхет санала иде. Без – 70 ел балалары. Шул оешмаларда тәрбияләнеп үстек.

1922 нче елның 19 нчы мае – пионер оешмаларының туган көне. Иң беренче Бөек Октябрь социалистик революциясенең җиңүе хөрмәтенә, Октябрь бәйрәме алдыннан, 1 нче класс укучыларын октябрятка кабул итәләр иде. Бүгенгедәй хәтеремдә: В.И. Ленинның дүрт яшьлек чагындагы рәсеме төшерелгән тимер значокларны барыбыз күкрәкләребезгә тагып йөрдек.” – ди җитәкчем Клара Фёдоровна.

Пионерга керү В.И. Ленин туган көндә – 22 апрельдә бөтен мәктәп коллективы каршында тантаналы төстә үтә торган була. Беренче мәртәбә пионерия символы булган өчпочмаклы кызыл галстук алар өчен бик кадерле була. “Ул көнне мәктәптән кайтканда, изүләребезне ачып, муеннарыбыздагы кызыл галстукны җилфердәтеп, сөенеп, зур горурлык белән өебезгә кайтканым хәтеремә уелып калган.” – дип искә ала әтием.

Өлкәннәр сөйләве буенча, бик тә җанлы һәм кызыклы оешма була пионер оешмасы. Пионер – ул беренче, барлык эшләрдә дә беренче булып башлап йөрүче, ул туган илен яратучы, яхшы укучы булган. Үрнәк тәртипле, кыю. Пионер законнарын өйрәнеп, пионер сафларына керә икән укучы, инде ул үзе өчен генә түгел, барлык иптәшләре, туган иле өчен, өлкәннәр өчен дә үрнәк булып, ярдәмләшеп яшәргә тиеш булган. Чынлап та, пионерлар – дус – тату, һәркайда, һәр эштә башлап йөрүчеләр булганнар.

Аннан соң әле һәр классның үз отряды булган, ул отрядлар звеноларга бүленгән; һәр отрядның исеме, девизы булган; отрядларны мәктәпнең дружинасы берләштергән. Мәктәптә үткәрелгән бөтен чараларның үзәгендә – пионерлар, иң беренче булып оештыручы, башлап йөрүче булган алар.

“Яхшы укырга, дус -тату булырга, хезмәт сөяргә өйрәттеләр безне. Әнә шулай хезмәттә чыныгып, эшләп үстек без. Ветеран әби – бабайларга да шефлык итә идек: су китерәбез, кыш көне мичен әягабыз, кар көрибез. Шулай бар эшне бергә эшләдек, ялларыбызны да бергә оештырдык, бергә эшләгәч, күңелле дә була иде. Мәктәптә ул елларда тәртип бозучылар да булмады диярлек. Чөнки андый балаларны дружина утырышында тикшерәләр иде. Берәүнең дә дружинаны артка сөйрисе килми.” – дип сөйли торган иде укытучы булып эшләгән Фәйрүзә әбием.

Иске Юраш урта мәктәбе пионер оешмасын 60 – елларда алыштыргысыз пионервожатый – Асия апа җитәкләгән. Йөгерек, җитез, һәр эштә төгәл Асия апа һәр пионерга үрнәк булган. “Атна саен пионер линейкалары, газеталар чыгару, отряд һәм звенолар эше, шефлык гамәлләре, кичәләр һәм чаралар, җәен Игенче урманында оештырылган пионер лагерендагы ял итүләр – барысы да могҗизалар мәйданы булып хәтергә уелган! Һәр эштә сыйныф җитәкчеләребез дә катнаша иде, төрле – төрле ярышлар, эстафеталарда урын алыр өчен чын

күңелдән бердәм тырыша идек." – дип искә ала шул еллар укучысы Мөслимә Фәрехша кызы.

Пионер оешмасы безне бик кызыксындырды. Без, Асия апаның үзен эзләп табып, элемтәгә кердек, бик озак сөйләде ул безгә бу оешма турында, аның сөйләменең бер генә өлеше белән булса да сезне таныштырып үтәсем килә:"Иске Юраш урта мәктәбен 1953 енче елдан яхшы хәтерлим. Мин мәктәптә белем алган вакытлар ул. Мәктәбебез һәрчак искиткеч матур булды! Укытучылары тагын да яхшылар. Алар пионер оешмабызның чын дуслары, ярдәмчеләре иделәр. Никадәр эшләр йөкләнә иде пионерларга, һәр эшне намус белән башкарырга тырыша идек: язын -җәен металлолом җыеп, мәктәп ишек алдына зур өемнәр куя идек, көзләрен сыйныф җитәкчебез – Кадрия апа җитәкчелегендә басуга башак җыярга чыга торган идек. Кулга кәрзин я чиләк тотып, икешәрләп тезелеп басып, җырлый – җырлый басуга юнәлә идек, кырда җир өстендә алынмый калган башакларны җыеп кайтып, ындыр табагына бушата идек. Ник бер кеше бармыйм дисен, ул чорларда укытучыларда да, укучыларда да энтузиазм бик көчле иде! Тимур командасы эше турында сөйләп туймаслык! Ялгыз әби-бабайларга, Ленинград блокадасыннан Юрашка кайтып төпләнеп калган һәм авылыбызны яратып яшәгән, шунда эшләп, хезмәтләрен куйган Ольга Степановна, Зинаида Николаевналарга, сугыш һәм тыл ветераннарына һәртөрле хуҗалык ярдәмен күрсәтүне алдыбызга бурыч итеп куеп яшәдек һәм үтәдек. Хәтта блокадницаларны ахыргы юлга озатуны да пионер оешмасы эше итеп кабул иттек, табутларын кызыл тукыма белән төргән мизгелләр, озата барган мәлләр истән чыкмый. Сугыш ветераннарына аеруча игътибар итә идек, аларның йорт капкаларына кулдан үзебез ясаган кызыл йолдызларны кадаклап чыктык. Пионер, дружина линейкаларына чакырып, аларны хөрмәтли идек, сөйләгәннәрен тыңлап, истәлекләрдән язмалар эшли идек. Җиңү бәйрәме – анысы аерым тема, ул иң зур әзерлек белән бик тантаналы уза иде! Һәр отряд, альбом ясап, аны яклый, газеталар чыгарыла, республикаларны өйрәнү нинди киңлектә бара, халыкара дуслык тәрбияләүгә никадәр игътибар ителә иде бит!Авыл хезмәте авыр иде элек, кул хезмәте зур иде. Шунлыктан, колхоз терлекчелегенә ярдәм күрсәтү дә оешмабыз эшенең бер тармагы булып торды. Фермага чыгып, тәрәзә юулар, терлекчеләргә багышланган стенд -газеталар чыгару, алар каршында концерт куеп кайтулар – барысы да чын күңелдән яратып башкарылган!

1963 елдан КВН ягъни шаяннар һәм зирәкләр клубы киң таралыш алды. Герой пионерлар тарихын шул чара аша өйрәнү тәҗрибәгә керде: Павлик Морозов, Зина Портнова, Марат Казей, Володя Дубинин һәм башкаларның язмышын өйрәнү беркемне дә начарлыкка өйрәтмәгәндер, мөгаен, ә бәлки илне ярату тәрбияләп, батырлыкка өндәгәндер.Пионер туган көнне зур бәйрәм итә идек, киңәйтелгән дружина линейкасы уза иде.

Пионер оешмасының 100 еллык юбилеен Рәсәйнең барлык өлкә һәм республикалары билгеләп үтте. Алабуга шәһәрендә дә кайчандыр районыбызның пионер сафларын җитәкләгән алыштыргысыз Сорокина, зур

чара әзерләп, педагогия институтында пионер галстуклары таккан укучылары белән чыгыш ясады. Пионерия кабат торгызылмасмы дигән өмет яши әле безнең көннәрдә”.– дип сөйләде ул.

Асия апа безгә пионер оешмасының эшен көннәргә кереп калырлык итеп сөйләде. Аннан соң әле күпләр эшләгән бу юнәлештә. Гайнетдинова Гөлсинә, Закирова Зифинур, Рахматуллина Фагыйлә, Гыйбадуллина Зәлия, Яруллина Резеда – барысы да, пионер эшен мәктәп йөзенә кызыллык килмәслек итеп оештырып, ветераннар салган эздән алып барганнар. Без алар белән дә элемтәгә кердек. Аларның фикерләрен дә тыңладык. Ә мәктәп укытучылар коллективы, сыйныф җитәкчеләре һәрчак кирәкле урында аларга ярдәм иткәннәр.

Безгә бу оешманың эше белән танышу бик кызыклы булды. Үзебезнең хәзерге вакыттагы мәктәп тормышы белән чагыштырдык, нәтиҗә ясадык. Пионер оешмасының тормышы, яшәү рәвеше белән мәктәбебез укучыларын да таныштырдык. Билгеле, безнең тормыш хәзер бераз башкачарак. Яшәү өчен бар шартлар да тудырылган. Әмма алардан үрнәк алырдай сыйфатлар бик күп икән. Аларның яшәү рәвеше – безнең өчен үрнәк. Без аларда булган матур сыйфатларны үзебездә тәрбияләргә тиешбез, дип уйлыйм. Туган илгә, халкыбызга, мәктәбебезгә, өлкәннәргә, хезмәткә, укуга, иҗтимагый эшләргә булган мөнәсәбәтебезне тагын бер мәртәбә барларга, остазларыбыз йөзенә кызыллык китермәскә, ышанычларын акларга тиешбез.

## Г.КАМАЛНЫҢ “БЕРЕНЧЕ ТЕАТР” КОМЕДИЯСЕН ӨЙРӘНҮ ДӘРЕСЕНДӘ УКУЧЫЛАРНЫҢ ТАНЫП–БЕЛҮ АКТИВЛЫГЫН ҮСТЕРҮ ЮЛЛАРЫ.

Галишина И.Л.,
КФУның Алабуга институты студенты.
Фәнни җитәкче: Камаева Р.Б.

XIX гасыр башында Казанда театр уеннары уйнала башлагач, тамашачылар арасында татарларны да бик күпләп күрергә мөмкин була. Татарларда драматургия жанры XIX гасырның 80 нче елларында гына формалаша башлый. Бу төрнең башлангычы фольклорга, халык уеннарына барып тоташа. Безнең татар халкында драма элементларын эченә алган, кара-каршы сөйләшүгә, җырлашуга корылган уеннар, туй йолалары гасырлар буе яшәп килгән.

Драма, әдәби төр буларак, борынгы Грециядә Эсхил, Сафокл, Еврипид трагедияләре, Аристофан комедияләре үрнәгендә формалаша. Рус әдәбиятында драма жанры XVIII гасырда мәйданга чыга, XIX гасырда гына теоретик яктан нигезләнә. А.Н. Островский-ның «Яшенле яңгыр», А.П. Чеховның «Өч кыз туган», «Акчарлак», А.М. Горькийның «Тормыш төбендә», «Мещаннар» драмалары зур бәя ала.

XIX йөзнең соңгы чирегендә мәгърифәтчелек идеяләрен яклап чыккан Габдрахман Ильясиның «Бичара кыз» (1887), Фатих Халидинең «Рәдде бичара кыз» (1888) әсәрләре беренче татар драмалары булып санала.

Ни өчен безнең әдәбиятта драма жанры шулай соңга калып туган? Моның берничә сәбәбе бар. Беренчедән, драма – иҗат итү өчен авыр жанр. Эпик әсәрләрдән аермалы буларак, андагы геройлар, авторның сөйләп аңлатуларыннан башка, үзләренең сөйләмнәре, эш-хәрәкәтләре белән ачылырга тиеш.

Икенчедән, драма сәхнәдә кую өчен языла. Җәмгыять тормышына йогынтылары зур булган иске карашлы муллалар театр сәнгатен, мөселманга гөнаһ, дип тыеп килә.

Өченчедән, хатын-кызларга сәхнәдә уйнарга ярамаган-лыктан, ул рольләрне ир-атлар башкарырга тиеш була. Курку белмәс батыр йөрәкле кызларыбыз Сәхибҗамал Гыйззәтуллина-Волжская, Гөлсем Болгарская, Зөләйха Богданова, беренчеләрдән булып, татар сәхнәсенә күтәрелә. (Баян Гыйззәт, әдәбият белеме галиме, театр белгече, тәнкыйтьче) [Хәсәнова 2016: 215]. Укучыларга театр тарихы турында мәгълүмат биргәннән соң, әңгәмә оештырырга мөмкин. Әңгәмә өчен сораулар:

1.Казанда беренче спектакльләр кайчан куела башлаган?

2.Рус театрларына йөрү татарларга нәрсә биргән?

3. Драма жанрын кайсы халык башлап җибәргән?

4.Рус әдәбиятында драма жанры кайчан формалашкан?

5. Бездә драма жанрының соңлап тууының сәбәпләре нинди?

6. Иң беренче хатын-кыз артисткалар кемнәр булган?

Шул дәрестә укучылар Г.Камал иҗаты һәм тормыш юлы белән танышалар. Драматургның иҗаты турында язылган мәкалә буенча тезислар язып алырга мөмкин. Яки таблица төзүне оештырырга мөмкин. Татар әдәбиятының классигы Галимҗан Ибраһимов болай дип язган: “Г.Камал – татар драма әдәбиятының атасы, татар сәхнәсе өчен тууыннан алып 1916 нчы елга кадәр үзенең әсәрләре белән зур байлык бирә килгән язучы.... Ул әсәрләре белән генә түгел, үзе театр тудыру эшендә кп булышлык кылды.” (Г.Ибраһимов)

Г.Камалның тормыш юлы һәм иҗаты белән танышкач, эшләргә кирәкле биремнәр: Г. Камалның тормыш юлы һәм иҗаты буенча хронологик таблица төзегез. Ул нинди белем ала?Театрга мәхәббәте ничек туа? Г. Камалның драматурглык эшчәнлеге турында сөйләгез. Г. Камал тагы кайсы өлкәләрдә эшли? Драматург иҗатына нинди бәя бирелә? Г. Камал исеме ничек мәңгеләштерелгән? Шул турыда проект эше эшләгез.

Г.Камалның “Беренче театр” әсәрен өйрәнү дәрестә укучыларны Г.Камалның тормыш юлы һәм иҗаты белән таныштыру; театр, драматургиягә караган терминнар турында төшендерү; драматургия турында белгәннәрен тирәнәйтү; “Беренче театр”ны укый башлау; әсәрдә сурәтләнгән чор һәм катнашучылар белән танышу; укучыларның текст белән эшләү күнекмәләрен

камилләштерү; тел-сурәтләү чараларын ачыклау, иҗади фикер йөртү, бәя бирү сәләтләрен үстерү; рольләргә бүлеп уку күнекмәләрен арттыру; укучыларны театр сәнгате белән таныштыру; әхлакый-эстетик тәрбия бирү; татар халкының театрга мөнәсәбәтен билгеләү; театрның әһәмиятен, әдәби-мәдәни мирасыбызның кадерен белергә кирәклекне ассызыклау, милли традицияләребезгә ихтирам тәрбияләү максаты белән үткәрелә. Дәресне җиһазлау түбәндәгеләрне үз эченә ала: театр турында фикерләр язылган плакатлар: “Театр – кеше күңеленә турыдан-туры юл салучы сәнгать, һәм ул халык тормышыннан башка яши алмый. Милли театр бигрәк тә.” (М.Сәлимҗанов), “Театр – безнең киләчәк көннәребез өчен файдалы һәм өмидле бер нәрсә” (Г.Тукай); китаплар күргәзмәсе: Г.Камал турында китап, “Татар теленең аңлатмалы сүзлеге”, К.Фукс турында китап, театр турында материаллар; видеоролик, презентацияләр**,** туп, әдәбияттан таблицалар. Дәреснең белем-күнекмәләрне актуальләштерү этабында Г.Камалның биографиясе буенча, театр турында сорауларга җавап бирү эше башкарыла. Укучыларны дәфтәрләренә Г.Камалның яшәгән елларын язалар, “Беренче театр” комедиясен язып куялар, чөнки бу дәрестә әсәр белшн эш башлана. Укучыларга рольләр бүлеп бирелә.Укучылар әсәрне укыйлар, сүзлек өстендә эш башкарыла. Укытучы соравы: Бибинең театр нинди җир дигән соравына ничек җавап бирербез, укучылар? Көтелгән җавап: Сүз уйнату: театрга – төятергә, кислота – киез ката, асыл – асыл. Терминнар белән эшләү: ремарка – җәя эчендә автор аңлатмалары, реплика – диалогтагы кеше сүзләре, пәрдә – драма әсәрендә бүлек һ.б.

Укытучы соравы: Укучылар, “Беренче театр” әсәре сезгә ошыймы? Геройларымы, телеме, вакыйгалармы? Көтелгән җавап Бу әсәр – сәхнә әсәре, әдәби төрнең драма төренә карый.Ә драма өч төрле була: драма үзе, комедия, трагедия. Комедия нәрсә ул? Көтелгән җавап Көлкеле сәхнә әсәре.

Бу дәрестә укучылар “Беренче театр” спектакленнән өзек карыйлар, театрлар белән танышалар. Рефлексия этабында укучылар белән әңгәмә уздырыла. Сораулар: Сезгә бу дәрес файдалы булдымы? Ни өчен? Сез авырлыклар кичердегезме? Аларны җиңеп чыгарга нәрсә булышты? Үзегезнең эшегезне ничек бәялисез?

Дәрес ахырында укучылар үзбәя билгеләрен әйтәләр, укытучы укучыларга билгеләр куя.

**Әдәбият**

1.Татар әдәбияты тарихы: Алты томда, 6 том: 60-90 еллар әдәбияты / Төзүчеләре Бәширов Ф.К., Галимуллин Ф.Г., Мусин Ф.М. – Казан: “Раннур” нәшрияты, 2001. – 544 б.

2.Хатипов Ф.М. Әдәбият теориясе: Югары уку йортлары, педагогия училишелары, колледж студентлары өчен кулланама. – Казан: Мәгариф, 2000. – 351 б.

3.Хәсәнова, Ф.Ф. Татар әдәбияты: рус телендә төп гомуми белем бирү оешмалары өчен д-лек (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен). 9 нчы с-ф. Ике кисәктә. 1нче кисәк / Ф.Ф.Хәсәнова, Г.М.Сафиуллина, М.Я.Гарифуллина; [рәссамы Фәридә Ризаева]. – Казан: “Мәгариф–Вакыт” нәшр., 2016. – 207 б.

## КӘРИМ ТИНЧУРИННЫҢ “СҮНГӘН ЙОЛДЫЗЛАР” ДРАМАСЫНА АНАЛИЗ

Гаптракипова Д.М.,
«Адымнар-Әлмәт» күптелле гимназиясе» укучысы.
Фәнни җитәкче: Тамасова Я.И.

Кәрим Тинчурин – татар драматургиясенең күренекле артисты, драматургы. Ул – милли театрның нигезен салучыларның берсе дә булып тора. 1910 елда ул театрга килә. Күп кенә театрларда төп рольләрне башкара, аннары режисерлык эше белән шөгыльләнә башлый. XX йөзнең күренекле булган драматургы бик катлаулы фаҗигале тормыш үтә. Ул әдәбиятка да зур өлеш кертә. Халыкның тел байлыгыннан уңышлы файдалана. “Җилкәнсезләр”, “Зәңгәр шәл” һәм “Сүнгән йолдызлар” кебек әсәрләр яза. Бу әсәрләрендә Тинчурин халык язмышы, мәхәббәт һәм фаҗигале хәлләрне, сугыш вакытындагы авыр вакытларны яза. [Тинчурин 2003: 357]

“Сүнгән йолдызлар” драмасы – 1923 нче елда языла. Бу әсәрдә трагизм һәм драма элементлары узара бәйләнеп язылган. “Сүнгән йолдызлар” драмасында татар халкының йолалары, гореф–гадәтләре чагыла, кичке уеннар, каз өмәләре – халык көенә җырлап, уйнап сурәтләнә. Аның төп проблемасы булып – мәхәббәт хисенең зур булуы. Бу әсәрнең үзәгендә кеше язмышы һәм мәхәббәт. Автор бер–берсен яраткан ике яр арасындагы мәхәббәтне һәм алар тормышындагы фаҗигане сурәтли. Сәрвәр белән Исмагыйль икесе дә ятим балалар булалар. Сәрвәр әбисе белән яши, ә Исмагыйль Мәхдүм байга эшләп гомер итә. Сәрвәр яхшы күңелле, уңган, мәрхәмәтле җиткән кыз. Исмагыйль дә уңган, кулын бар эш тә килгән, халыкка яхшы мөгалләмәдә булган ир–егет. Мәхдүм бай да Сәрвәргә гашыйк була, әмма аның кыяфәте бик ямьсез. Анардан барысы да курка, бай булганга күрә аның белән сөйләшәләр. Әмма Сәрвәргә аның байлыгы да, кешеләр арасындагы зур урыны да кирәкми, аңарга мәхәббәт кирәк. Ул Исмагыйльгә үлеп гашыйк, Исмагыйль дә аны өзелеп яраткан. [Электрон ресурс]

Алар – авылның иң якты йолдызларының берсе. Бу ике яр бергә булу өчен барысына да әзер. Аларның мәхәббәте бик саф. Ләкин автор бу мәхәббәт белән бергә Исмагыйльнең куркыныч төшен дә сурәтли. Вакыйгалар үзгәрелеше менә шуннан тотына. Аның төше буенча һәрбер кешенең үз йолдызы бар, алар бар күкне бик якты яктыртып торалар. Әмма кинәт кенә күктәге бар йолдызлар да сүнә, аларны зур аждаһа аера. Шул аждаһа

авызыннан Сәрвәр пычак белән чыгып, үзенең сөйгәнен чәнчеп үтерә. Сәрвәр бу төшнең дөрес булуына ышанмый, Исмагыйльне дә бу саташу гына булуына ышандыра. Әмма үзенең шикләрен бастыру өчен әбисенә төшен сөйли, әбисе төштә йолдызлар сүнү яхшыга булмавын әйтә. Аннары кульминацион нокта булып, әсәрдә аждаһа образы аша илдәге сугыш башлануы күрсәтелә. Бу ике яр арасына сугыш килеп баса. Сәрвәр ике ут арасында яна башлый. Ул мәхәббәтне сайлый. Ләкин курка, чөнки яраткан кешесенең сугыштан әйләнеп кайта алуы шикле генә. Сәрвәр авылның, барысына да билгеле булган, димче хатынына бара һәм аңардан сөйгәнен сугыштан алып калу өчен дару алып кайта. Үзенең ашыгуы сәбәпле, уйлап бетермичә сөйгәненең колагына аны сала. Ләкин Исмагыйль колагының януына, башының авыртуына түзә алмыйча һәлак була. [Электрон ресурс]

Димәк, Сәрвәр үз куллары белән үзенең сөйгәнен үтерә. Шушы кайгыдан ул акылдан яза. Чыгып китеп югала, үзе белән үзе сөйләшә башлый. Ул бик еш Исмагыйльне күз алдына китерә, бергә булган көннәрен күз алдыннан кичерә. Аны юатырга Мәхдүм килеп йөри. Ул аны шашып яратуын, аның өчен барысын да эшлиячәген әйтә. Әмма Сәрвәр моны аңларлык хәлдә түгел, ул акылдан язган. Соңгы минутларында Сәрвәр “каз канаты” көен көйләп, Исмагыйльнең тавышларын ишетеп үлеп китә. Менә шулай фаҗигале бетә бу мәхәббәт. Бер-берсен яраткан парлар, мәңгелеккә бергә калдылар. Ләкин аның өчен аларга үз гомерләрен бирергә туры килде. Исмагыйль яратуы аркасында, Сәрвәргә каршы үзенең фикерен, әйтә алмый. Әгәр дә ул мондый куркыныч адымнарга бармыйча, сугышка барам дигән булса, бәлки аларның киләчәге башкачарак булыр иде. Ләкин икенче яктан карасаң, Исмагыйльне үз фикерен әйтә белми, бар авырлыкны Сәрвәр өстенә йөкли дип калдыру дөрес булмас иде. Чөнки ул Сәрвәрне башка күрә алмавыннан, аның белән мәңгегә аерылудан куркып кына, бу куркыныч адымга барды. Әмма бу ике ярга бәхетле тормыш язмаган булган, күрәсең. Чөнки ничек кенә көрәшсәләр дә, аларга каршы булган көчләр көчлерәк булып чыкты. Ул чорда шундый киртәләр булу, кызларның тормышын гаиләләре хәл итү дә күп кенә яшьләрне бәхетсез итә.

Авторның әйтергә теләгән фикере – һәр кеше үз бәхетенә омтылып яши, ләкин җәмгыять кешеләрне бәхетле итә алмый. Сугыш кешеләрнең бәхетен сүндерә, асыл егетләрнең тормышын эзә. Чылбыр рәвешендә бәхетсезлек тагын да арта. Нәтиҗәдә һәрбер кешенең бәхетсезлеге җәмгыять бәхетсезлеге булып усеп җитә. Бер-берсен шашып яраткан яшьләр чынлыкта бәхетнең мәгънәсен аңламыйча һәлак булалар. Кешеләрнең бәхетсезлеге шулай ук Фәрхи кебек им–том итүче карчыкларга бәйле. Андый кешеләрне бары матди як кызыксындыра, яшьләр бәхетлеме, бәхетсезме кызыксындырмый. Бу яктан андый карчыклар дәүләт җитәкчеләренә охшаш. [Тинчурин 2003: 359]

Нәтиҗә ясап, шуны әйтәсе килә, мәхәббәт –ул биек, шашкын хис. Бу әсәрдә дә без Сәрвәр һәм Исмагыйль образлары аша саф мәхәббәт, бер–берсен яраткан парларны күрдек. Әмма бу парга киләчәктә матур гаиләләр корып, балалар үстереп, бәхетле яшәргә язмаган күрәсең. Ләкин алар көрәште, бергә

булыр өчен бар көчләрен куйдылар, авырлыкларда бирешмәделәр. Димәк, яраткан кешең белән бергә булу өчен барысын да эшләргә кирәк. Мәхәббәт ул кешене үзгәртә, яшәртә, куркусыз булмаска, үз дигәнеңә ирешергә ярдәм итә. Мәхәббәтсез бер кеше дә яши алмый. Шунысы яхшы, хәзерге заманда яшьләр үзләре яраткан кешеләре белән гаилә корырга мөмкин. Әмма, кызганычка каршы, хәзер дә иң алгы планга байлыкны куючылар, яраткан кешесенә түгел, ә бай, яхшы гаиләдән булган кешеләр белән гаилә корырга теләүчеләр бик күп.

**Әдәбият**


1. Тинчурин К.Сайланма әсәрләр. – Казан: ТаРИХ, 2003. – 495 б.

2. Электрон ресурс: [мөрәҗәгать итү вакыты: 21.01.24] https://tugan–tel.tatar/adabiyat/dramaturgiya/Karim_Tinchurin/sungan_ioldyzlar.php


## ТАТАР ТЕЛЕНДӘ ЭНДӘШ СҮЗЛӘРНЕҢ ГРАММАТИК ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ


Гарифулина Т.Р.,

КФУның Алабуга институты студенты.

Фәнни җитәкче: Хәйруллина Ә.С.


Эндәш сүз – дип сөйләүченең сөйләме төбәлгән зат, предмет яки күренеш атамасын атыйлар. Грамматик яктан караганда, татар телендә иң еш очрый торган күренеш – ул баш килештәге исем белән белдерелгән эндәш сүзләр. Мәсәлән:

– Акылың котмы, *Янгузаров*? – дип беркем көтмәгәндә усал кычкырды да, Каюм, болан сымак сикереп, келәткә терәлеп торган киртәләр артында юк та булды [Имамов 2004: 105].

Исемләшкән сыйфатлар исә номинатив вазифа яки экспрессия тудыру вазифасын гына башкармыйлар, аларның гадәттә бәя бирү потенциалы гаять югары була. Игътибар итик:

– Болай атка атланып йөрсәң, үскәч кияү йөзе дә күрмәссең син, *денсез*!.. [Имамов 2004: 94].

Алга таба эндәш сүзләргә хас грамматик категорияләрне карап китик. Ф.Г. Галләмов шундыйлар рәтендә бер составлы булуны атый. “Синтаксик категория буларак эндәш сүзләргә иң беренче бер составлылык хас. Оештыручы үзәк бер генә, һәм ул баш килештәге исем яки исемләшкән сүз төркемнәре (сыйфатлар, тәртип саны, сыйфат фигыльләр, алмашлыклар) белән бирелә” [Галләмов 2009: 105]. Мисалларга мөрәҗәгать итик:

– Теге аның сандыкларында казына башлагач: “Имансыз кулың белән Коръән шәрифкә кагыласы булма, *кяфер*”, – дип, Габидулла хәзрәт каршы төшеп караган каравын [Имамов 2004: 134].

– Сөенегез, *карта ясаучылар,*
Тагын шатлык, тагын тантана!
Туып килгән яңа шәһәрчекне

Төшерәсез булыр картага... [Низами 2005: 29].
(“Тетри тайга”)

Беренче очракта эндәш сүзнең исем сүз төркеме белән белдерелгәнлеген күрәбез, икенче очракта – хәзерге заман сыйфат фигыль белән белдерелә. Ике очракта да эндәш сүз җәенкеләндерелмәгән.

Эндәш сүзләргә хас була ала торган тагын бер грамматик категория – җәенкеләнә алу. Ешрак эндәш сүзләрне җәенкеләндерүче кисәк буларак сыйфат фигыльләр һәм сыйфатлар килә. Мисал карыйк:

Хәтерләсәм кинәт кенә
Шул чактагы дау чорын, –
Әрни–әрни әйтеп куям:
“Хуш, *югалган ваучерым...*” [Низами 2005: 155].
(“Хуш, югалган ваучерым...”)

Кайбер эндәш сүзләргә хәбәрлек, кайберләренә ярымхәбәрлек категорияләре хас була ала. Түбәндәге мисалга игътибар итик:

– Утырыгыз, *җаныйларым*, әйдә, утырыгыз [Имамов 2004: 107].

Бу мисалда эндәш сүз төп җөмлә составында, аның уртасында килә. Бу җөмләдә эндәш сүз ярым хәбәрлекне белдерә, боерык фигыль белән белдерелгән гамәлне эндәш сүз буларак формалашкан “җаныйларым” башкара. Әмма башка очраклар да булырга мөмкин. Әйтик, түбәндәге очракта баш җөмләдәге үтәүче белән эндәш сүз туры килми, һәм мондый очраклар турында галимнәр: “семантик синтаксис күзлегеннән караганда, тулы хәбәрлек белдерелә”, – дип язалар [Галләмов 2009: 107]. Мисалларны карыйк:

– Телең, валлаһи, кычыткан сымак, *хәзрәт* [Имамов 2004: 87].

– И–и, күрде инде башлар, *Әмир абыкаем*! [Имамов 2004: 46].

Зат категориясен карыйк. Бу категория белән нисбәтлелекне тикшерү өчен, түбәндәге мисалны тикшерик:

Син оялма, гаҗәпләнмә, *чишмә,*
Күреп кызның үзеңә иелгәнен, –
Тидерсен ул салкын суларыңа
Үбелмәгән кайнар иреннәрен [Низами 2005: 34].

(“Сөюне көткәндә”)

Әлеге мисалда эндәш сүз сөйләм төбәлгән предметны белдерә, ягъни икенче зат берлек сан грамматик категориясе белән нисбәтле. Моңа ишарә булып төп җөмлә составында син алмашлыгы килүе дә тора, әмма мондый алмашлыкның булуы мәҗбүри шарт түгел.

Сан категориясе белән нисбәтлелеккә дә игътибар итик. Галим Ф.Г. Галләмов язганча, “Бу грамматик категория эндәш сүзләргә шулай ук хас. Ул сөйләм төбәлгән затның, предметның, чыннан да, санын күрсәтә. Әгәр дә сөйләм төбәлгән зат берәү генә икән, ул чагында исем, исемләшкән сүзләр белән бирелгән эндәш сүзләр берлек санда килә” [Галләмов 2009: 109]. Мондый мисалларны шактый еш күзәтергә була:

– Ай–һай, *энекәем*, бик нык ялгышасың [Имамов 2004: 131].

– Качабыз, дисең инде, *Яков дәдәй* [Имамов 2004: 132].

Шулай итеп, грамматик яктан эндәш сүзләр исем яки исемләшкән сүз төркемнәре белән белдерелә, хәбәрлек, зат һәм сан категорияләре белән характерлана, эндәш сүз үзенчәлекләре буларак бер составлы булу һәм җәенкеләнә алуны да атарга мөмкин.

**Әдәбият**


1. Галләмов Ф.Г. Эндәш сүзләргә хас грамматик категорияләр // Татар синтаксисыннан очерклар. – Алабуга: АДПУ нәшр., 2009. – Б. 105 – 112.
2. Имамов В. Тозлы яра: Роман. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2004. – 384 б.
3. Низами Р. Тормыш трамвае: Шигырьләр, поэма. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2005. – 238 б.


## “РӘВЕШ” ТЕМАСЫН ӨЙРӘТҮ ДӘРЕСЕНДӘ КҮРСӘТМӘЛЕЛЕКНЕҢ РОЛЕ


Гильмутдинова.Ф.Ф.,
КФУның Алабуга институты студенты.
Фәнни җитәкче: Камаева Р.Б.


Күренекле француз фәлсәфәчесе, мәгърифәтче Жан Жак Руссо “сизем-тойгылар һәрвакытта да предметлар турында дөрес күзаллау бирә, шуңа күрә белем бирү күрсәтмә формада булырга тиеш” дип саный [цитата: Кашапова 2016: 52]. Чех педагогы, гуманист Ян Амос Коменский шулай ук күрсәтмәлелекне “дидактиканың алтын кагыйдәсе” дип атый. Галим фикеренчә, мөмкин булган барлык әйберләрне хис-тойгылар белән кабул итәрлек итеп, ягъни күренә торганны күреп, ишетелә торганны ишетеп, исләрне ис сизеп кабул итәрлек итеп тәкъдим итәргә кирәк [цитата: Кашапова 2016: 52]. Заманча дәрес әле һаман да күрсәтмә чаралардан башка үтми, шуңа күрә педагогика классикларының фикерләре бүген дә актуаль булып кала. Күрсәтмәлелек чаралары уку-укытуның нәтиҗәлелеген үстерә, укучыларда белем алуга кызыксыну тудыра, моннан тыш, укучыларның гамәли күнекмәләрен формалаштыра, чөнки алар теорияне практика белән бәйләргә ярдәм итә. Педагогик эшчәнлектә системалы рәвештә һәм киң файдаланылган, кулланылышта шактый гади һәм уңайлы булган күрсәтмәлелек формасы булып таблица тора. Таблицаларның төп дидактик бурычы – кагыйдәләрне куллануга, төшенчәне үзләштерүгә ориентир бирү; кагыйдә яки төшенчә нигезенә салынган закончалыкларны чагылдыру; конкрет тел материалын истә калдыру процессын җиңеләйтү. Таблицалар “Рәвеш” темасын өйрәнүдә дә уңышлы кулланыла ала. Әйтик, алтынчы сыйныфта укучылар “Рәвеш төркемчәләре” темасы белән таныша [Сәгъдиева 2017: 96]. Шушы тема кысаларында укучылар игътибарына рәвеш төркемчәләре буенча өч графага бүленгән таблица тәкъдим

ителергә мөмкин. Аның беренче графасы рәвеш төркемчәсе атамасы, икенчесе – морфологик билгеләр, өченчесе – мисаллар дип исемләнә. “Рәвеш” темасы өйрәнелә генә башлаган беренче дәрестә укытучы таблицаның барлык графаларын да тулы килеш тәкъдим итә. Тема өйрәнелгәннән соң, укучыларның белемнәрен тикшерү максаты белән теманың аерым графалары буш калдырыла. Мәсәлән, укытучы беренче графага саф рәвешләр дип һәм өченче графага мисаллар язып, аның икенче – морфологик билгеләр дип исемләнгән графасын буш калдыра, әлеге буш графаны укучы тутырып бетерергә тиеш була. Шул рәвешле, укучының теманы үзләштерү дәрәҗәсе дә күренә, укучылар хәтерендә дә “Рәвеш төркемчәләре” темасы озаграк саклана. Әлбәттә, икенче очракта, беренче һәм икенче графаларга кирәкле мәгълүмат язылып, өченче графа буш калдырыла ала. Бередә инде укучылар билгеле бер төркемгә караган рәвешләрне теркәп куярга тиеш булалар.

Заманча педагогик технологияләрдән күрсәтмәлелек алымнарына бигрәк тә тәнкыйди фикерләү технологиясе бай. Әлеге технологиягә караган кластер, фишбоун, чагыштырма таблица һ.б. алымнар барысы да күрсәтмәлелек формасы булып торалар. Шулардан кластерга тукталып үтик. “Кластер (инглиз телендәге “cluster” – “төркем” сүзеннән) – материалны системалаштыруның график алымы, әмма әлеге алым материалны системага салу өчен генә түгел, ә алдарак өйрәнелгән материалны контрольгә алу, гомумиләштерү өчен дә кулланыла ала. Ул өйрәнелә торган теманы төрле яклап анализларга ярдәм итә торган нәтиҗәле коралдан гыйбарәт” [Тагирова 2024: 219]. Кластерларның төрле төрләре бар, алар йөзем тәлгәшләре, идеяләр кәрҗине, арт кластер, төркемнәрдә кластер һ.б.лар буларак формалашырга мөмкин. Уйлавымча, “Рәвеш” темасына кагылышлы кластерны йөзем тәлгәшләре формасында тәкъдим итү уңышлы булачак. Мондый кластерның уртасына “Рәвеш” сүзе языла. Бу сүздән дүрт “йөзем тәлгәше” аерып чыгарыла, әлеге тәлгәшләргә рәвеш сүз төркеменә характеристика бирүне максат иткән түбәндәге сүзләр языла: сүз төркеме, мәгънә ягыннан төрләре, җөмләдә кулланылышы, ясалыш ягыннан төрләре. Әлеге дүрт тәлгәш тагын да тармаклана. Әйтик, сүз төркеме тәлгәшеннән мөстәкыйль сүз төркеме дигән тармак аерып чыгарыла. Мәгънә ягыннан төрләре тәлгәше үзе өч тармакка аерыла: урын рәвешләре, вакыт рәвешләре, сәбәп-максат рәвешләре. Ясалыш ягыннан төрләреннән ике тармак аерып күрсәтелә: тамыр рәвешләр, ясалма рәвешләр. Җөмләдә кулланылышы тәлгәше бер тармакны аерып күрсәтә: хәл булып килә.

Әлбәттә, күрсәтмәлелек түбәндә әйткән алымнар белән генә чикләнми. Соңгы елларда мәгълүмати-коммуникацион, цифрлы технологияләр интенсив үсеш алу белән мультимедиа күрсәтмәлелек – презентацияләр куллану активлашты. Мондый күрсәтмәлелек материалны төрле, ачык төсләрдә тәкъдим итү мөмкинлеге бирә. Ул “Рәвеш” темасын өйрәнүдә дә уңышлы кулланыла ала.

Нәтиҗәләргә килеп шуны әйтә алам: иҗади фикер йөртүче укытучы “Рәвеш” темасын өйрәтү өчен кызыклы, файдалы күрсәтмә материаллар

әзерләргә мөмкин. Әлеге материалны яңа тема өйрәнүдә дә, белемнәрне ныгытуда да кулланып була. Бу очракта укучылар бер типтагы биремнәр башкарудан котыла, аларның эшчәнлеге төрләнә.

**Әдәбият**

1. Кашапова Э.Н., Яковлева Е.В. Приемы работы с таблицей в обучении русскому языку // Филологический класс. – 2016. – № 2(44). – С. 52-56.

2. Сәгъдиева Р.К. Татар теле : рус телендә төп гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен) 6 нчы с-ф. / Р. К. Сәгъдиева, Р. М. Гарәпшина, Г. И. Хәйруллина; [рәссамы Л. Хисамова]. - Казан : «Мәгариф - Вакыт» нәшр., 2017. 191 б.

3. Тагирова Д.Р. Приём “кластер”: особенности способа организации учебного материала на уроках русского языка // Наука и образование в контексте глобальной трансформации: Сборник статей XIII Международной научно-практической конференции, Петрозаводск, 15 января 2024 года. – Петрозаводск: Международный центр научного партнерства “Новая Наука” (ИП Ивановская И.И.), 2024. – С. 218-222.

## ГАЛИӘСГАР КАМАЛ – ТЕАТР СӘНГАТЕНӘ НИГЕЗ САЛУЧЫ

Гилмуллина А.Л.,
Алабуга шәһәренең 10 нчы күппрофильле лицей укучысы.
Фәнни җитәкче: Гилмуллина Л.С.

Галиәсгар Камал (1879-1933) - татар халкының бөек драматургы, язучысы, егерменче йөз башы татар әдәбияты, мәдәнияте һәм сәнгате тарихында зур урын алып торган әдипләрнең берсе, татар милли театрын үстерү эшенә зур көч куйган шәхес.

1906 нчы елның 22 нче декабрендә Казанда яңа клуб бинасында югары һәм урта мәктәпләрдә укучы татар яшьләре халык өчен ачык спектакль куярга җыеналар.

Сәхнәгә кую өчен Г. Камал тарафыннан төрекчәдән тәрҗемәи телеп бастырылган «Кызганыч бала» һәм башка бер әсәр  сайлыйлар. Бу спектакльне оештыру эшендә Г. Камал актив катнаша.Бу спектакль өчен кирәк булган афишаларны үзе кулдан яза һәм билетларсату эшен оештыра.  Әдипнең якыннан катнашуы һәм практик ярдәме белән оештырылган әлеге ачык спектакль куелу көне татар мәдәнияте тарихында татар  профессиональ театрының туу датасы булып теркәлә.

1907 нче елда «Сәйяр» труппасы төзелгәч, ул бу труппага турыдан–туры булышлык итә: артистлар өчен киемнәр табышып бирә һәм башка ярдәмнәр күрсәтә. Бигрәк тә Мәкәрҗә ярминкәсе вакытларында бу труппага зур булышлыклар итә. 1910 нчы елда Казандагы «Шәрык клубы» яңа бинага

күчкәннән соң, Г. Камал һәм Г. Коләхметов инициативасы белән, «Сәйяр» труппасы артистлары айлык хезмәт хакы алып эшләргәкерешәләр. Шул сезонда Г.Камалүзе труппада режиссерлык итә. Ул үзенең туган энеләре Габдулла һәм Габдрахман Камалларны шул ук труппага артист итеп кертә. Соңрак улы Әнәс тә драматург, сәләтле режиссер һәм артист булып китә

Профессиональ театр туу Г. Камалны иҗатка рухландыра. 1907-1912 нче еллар аралыгында үзенең иң көчле, сәнгатьчә иң камил булган әсәрләрен яза. Нигездә, ул драматургиянең ике жанрында иҗат итә. «Бәхетсез егет» (1907, икенче варианты), «Уйнаш» (1910), «Өч бәдбәхет»нең үзгәртелгән варианты), «Дәҗҗал», «Каенеш», «Көндәш» , «Өйләнәм – ник өйләндем» кебек драмаларында җәмгыятьтәге әхлакый түбәнлек, кешелексезлек проблемалары яктыртыла. «Беренче театр», «Бүләк өчен», «Банкрот», «Безнең шәһәрнең серләре» исемле комедияләре үз чорының актуаль мәсьәләсен, тормышчан вакыйгаларын сәхнәгә күтәрү белән аерылып тора. Г.Камал үзен комик ситуация, сатирик тип тудыру остасы итеп таныта. Аның драмаларында композицион бөтенлек, халыкчанлык хас. Әсәрләр «Сәйәр» труппасы тарафыннан сәхнәләштерелеп, халык арасында популярлык казана.

Г.Камал театр репертуарында рус һәм дөнья классикларының әсәрләрен татарчага тәрҗемә итеп тә баета: Н.Кәмал – «Кызганыч бала» (1900), А.Н.Островский – «Яшенле яңгыр» (1914), Мольер – «Саран» (1915), «Ирексездән табиб» (1916),«Скапен хәйләләре» (1924), А.Дюма – «Чәчәкле хатын» (1924) һ.б. Г. Камал үз гомерендә барлыгы 102 исемдә оригиналь һәм тәрҗемә сәхнә әсәрләре язды.Бу әсәрләр шул еллардагы театр сәхнәләрендә кат – кат уйналып, татар сәнгатен идея – эстетик яктан баета. Аның үсешенә уңай йогынты ясый.

Октябрь революциясеннән соң Г.Камал «Эш», «Эшче, «Кызыл көрәшче»газеталарында чор таләпләренә буйсынып язылган күпсанлы сәяси,сатирик шигырьләр – декламацияләр бастыра.Егерменче елларда һәм утызынчы еллар башында», «Тәкый гаҗәб яки Ахыры заман», «Могҗиза»,«Ысул кадимче»исемле сатирик комедияләр, «Хафизәләм –иркәм» (1921–1922), «Күзсез мастерлар» (1930), «Өч тормыш» (1930) исемле драмалар, кечкенә күләмле эстрада әсәрләре яза. «Хафизәләм – иркәм»әсәре Татар академия театры сәхнәсендә 1922,1949 нчы елларда уйнала.

1923 нче елда Г.Камалга иҗат эшенең 25 еллык бәйрәме уңае белән Хезмәт Батыры, 1926 нчы елда «Татарстанның халык драматургы» дигән мактаулы исемнәр бирелә. Хәзер исә Казанда урнашкан Татар дәүләт академия театры Галиәсгар Камал исемен йөртә.

**Әдәбият**

1. Даутов Р. Галиәсгар Камал турында истәлекләр – Казан: Татар. кит. нәшр.,1979. – 192 б.

2. Ганиева Ф., Яруллина Р., Саттарова А. Татар драматурглары: библиографик белешмәлек – Казан: Татар. кит. нәшр., 2007. – 271 б.

# А.ХӘЛИМ ХИКӘЯЛӘРЕНДӘ ӘДӘБИ ДЕТАЛЬ ФУНКЦИЯЛӘРЕ

Гилязов А. Л.,
КФУның Алабуга институты студенты.
Фәнни җитәкче: Габидуллина Ф.И.

Деталь – әдәби әсәрдә белдерелүче эмоциональ-мәгънәви көчкә ия төгәллек. Әдәби деталь сыйфатында геройларның тышкы кыяфәт билгеләре, сөйләм үзенчәлекләре, алар яшәгән тирәлек (табигать, урын, өй һ.б.лар) сурәте килергә мөмкин. Әдәби детальләрне күпләп куллану, санап бару ярдәмендә язучы образны укучы күз алдына бастыра [Әдәбият белеме, 2007: 45]. Айдар Хәлим дә моны аңлап эш итә. Әйтик, язучының "Җырлар вакыт" дип исемләнгән хикәясендә төс детале әһәмиятле роль уйный. Биредә ак һәм кара төсләре капма-каршылыкта, поляр позицияләрдә килә. Хикәянең төп герое Сәгъдәт туган авылының моңлы сандугачы, аның җырлавын бөтен авыл халкы диярлек яратып тыңлый. "Кирәкми безгә багана башындагы җансыз ырадиу! Аяулы ырадиуыбыз – Сәгъдәтебез исән булсын!" диләр аның турында авылдашлары [Хәлим, 2005: 96]. Ләкин, бу моң чишмәсеннән көнләшүчеләр дә булмый түгел. Сәгъдәтнең сыйныфташы – Кара Якуп шундыйлардан. Дөрес, Якуп үзе дә җырларга ярата. Әмма хикмәт шунда: тавышы Сәгъдәтнеке кебек көчле бәрхет тавыш түгел. Сәгъдәт җырлаган өянкене эштән кайтучы авылдашлары уратып алалар да туктаусыз кул чабалар, Якуп өянкесе каршында алар йә бөтенләй туктап тормый, йә "ә-ә, бу да җырлап азаплана икән" дигәндәй, адымнарын сүлпәнәйтеп, кулларын тирбәтеп кенә үтеп китәләр. Бу хәл Якупны ярсу хәленә җиткерә. Ул Сәгъдәткә "Җырлама! Җырлама, дим! Җырлама!!!" дип кычкырына башлый [Хәлим, 2005: 103]. Мондый кыланышның һичбер сәбәбен аңламаган Сәгъдәт башлаган җырын тәмамламыйча туктамый, әлбәттә. Бу исә Якупны тагын да ярсыта. Ул, ятып, йодрыклары белән җирне төя башлый:

"– Җырлама, бур! Әтигә әйтәм! Җырлама, хәерче!.." [Хәлим, 2005: 103].

Биредә авторның герой кушаматына кара төс детален чыгарып бирүе әһәмиятле роль уйный, дип уйлыйбыз. Төсләр төрле милләт вәкилләрендә төрле ассоциацияләр тудыра. Кара төс татар мәдәниятендә, башлыча, негатив коннотациягә ия. Бу әлеге төснең траур, бәхетсезлек белән бәйле булуы, аның кайгы һәм үлемне символлаштырып килүе белән аңлатыла. Шулай ук, кара төс гөнаһ, көнчелек төсе дә булып тора. Әсәр героена автор Кара кушаматыннан тыш, башка кушамат та бирә алган булыр иде, әмма аңа әлеге геройның эчке дөньясын, асылын нәкъ менә шушындый тискәре семантикага ия колоратив берәмлек белән белдерү мөһим.

Кара Якупка капма-каршылыкта язучы әсәр тукымасына Ак сакаллы бабай образын кертеп җибәрә. Биредә шулай ук төс компонентына мөһим мәгънә салынган. Бит ак төс яктылык, дөреслек, гаделлек, яхшылык, игелеклелек, бәхет-шатлык белән ассоциацияләшә, моннан тыш, ак төс – тынычлык символы. Нәкъ шуңа күрә дә, әсәрдәге сакаллы бабай образы ак төс

детале белән тәкъдим ителә. Ул Сәгъдәтнең тормышында иң кирәкле вакытларда пәйда булып, ярдәм итеп тора:

“Җырлый башлар алдыннан аңа әллә нәрсә була: ниндидер АК САКАЛЛЫ БАБАЙ (әсәрдә нәкъ шулай зур хәрефләр белән бирелә – искәрмә безнеке) аңа күзләрен йомарга куша. Күктә ул үзе. Кулына ниндидер китап тоткан. Менә шул чакта маңгай күзләре түгел, йөрәге күрә башлый аның. Шулай итмәсә, күзләрен дөньяга шар ачып җырласа, җырында ялганлар, моңында ялгышыр кебек тоела” [Хәлим, 2005: 96].

“Иң кирәк вакытында гына килә ул Бабай Сәгъдәтнең зиһененә. Китабын тотып, аякларын бөкләп, болытка менеп утырган ул. Сәгъдәткә нинди халәттә нинди адым ясарга кирәклеген пышылдап әйтеп тора...” [Хәлим, 2005: 102].

Язучының “Трофей ашъяулык” хикәясендә ашъяулык детале мөһим вазифа башкара. Әсәрдә Бөек Ватан сугышында Җиңүнең бер еллыгына бүләк ителгән тишек ашъяулык шул чордагы тормышны, дәүләтнең гади кешегә мөнәсәбәтен чагылдыра. Әсәрнең үзәгендә сурәтләнгән әлеге җәймә төп конфликтка да сәбәпче була. Ашъяулык хикәядә берничә урында телгә алына һәм һәрберсендә төрле тасвирлама белән: “кат-кат бөкләнгән аксыл тукыма хатын кулында талпынып җилпенде һәм аннан алтынсу-сары путалы, чит-читләре кыска-кыска чуклар белән чукланган киҗеле ашъяулык хасил булды” [Хәлим, 2005: 66], “тишек чүпрәк”, “тишек ашъяулык”, “таланган чүпрәк”, “трофей ашъяулык”. Әлеге тасвирламаларда солдатка хатынның шундый бүләк өчен рәнҗүе ачык чагыла. Ә менә Миңсылу өчен кадерле булган бирнәне автор җентекләп сурәтли: “...Менә ул сандык эченнән, астан, иң астан күзнең явын алырдай ап-ак, иң вак тәрәш аша тукылган чүпләмле ашъяулык тартып чыгарды. Аның шикәрдәй ак төсеннән барлык йорт эче яктырып киткәндәй булды” [Хәлим, 2005: 66]. Ике ашъяулык ике дөньяны чагылдыра: “ике дөнья, ике система бүләген: үзенең ирен үтерүчеләр иленнән килгән тишек трофей ашъяулык һәм һәлак ителгән ирнең Туган Ватанындагы хатынының үз куллары белән чәчкән, суккан, талкыган, эрләгән, салкын чишмәләрдә юган, киптергән, тукыган җитен тукымадан тегелгән ашъяулык” [Хәлим, 2005: 73]. Айдар Хәлим бу очракта да икенче ашъяулыкны тасвирлауга урынны күбрәк биреп, аның никадәр кадерле булуын ассызыклый.

Нәтиҗәгә килеп шуны әйтергә мөмкин: Айдар Хәлим тарафыннан кулланылган әдәби детальләр мәгълүмат бирү вазифасын башкара, герой психологиясен ачу чарасы итеп кулланыла. Кайчакта деталь символик мәгънә алып әсәр идеясен аңлауга ачкыч ролен үти башлый.

**Әдәбият**

1. Әдәбият белеме: терминнар һәм төшенчәләр сүзлеге / Төзүче-авторлар: Д.Ф. Заһидуллина, В.Р. Әминева, М.И. Ибраһимов, Н.М. Юсупова, Ә.М. Закирҗанов, Т.Ш. Гыйлаҗев, Г.Р. Гайнуллина. – Казан: Мәгариф, 2007. – 231 б.

2. Хәлим А. Кыйбла: хикәяләр, новеллалар. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2005. – 382 б.

## ГАЛИӘСГАР КАМАЛ – ТАТАР ТЕАТР СӘНГАТЕНӘ НИГЕЗ САЛУЧЫ.

Гиматова А.Р.,
Алабуга шәһәренең 10 нчы күппрофильле лицей укучысы.
Фәнни җитәкче: Усманова Р.Н.

Татар әдәбияты классигы, атаклы драматург, публицист һәм күренекле җәмәгать эшлеклесе Галиәсгар Камал 1879нчы елның 6 нчы гыйнварында Казанда вак һөнәрче–мехчы гаиләсендә дөньяга килә. Башлангыч белемне әнисенең туган авылында ала. Аннан Казанга кайтып укуын “Госмания” мәдрәсәсендә дәвам иттерә.

1880 елларда – «Госмания» һәм «Халидия», 1890 елларда «Мөхәммәдия» мәдрәсәләрендә укый, бер үк вакытта өчьеллык рус мәктәбендә башлангыч белем ала.

Улын мулла итеп күрергә теләгән атасының ихтыярына каршы килеп, Г.Камал үзен халыкны агарту эшенә багышлый. 1901 елда ул китап бастыру һәм тарату эше буенча «Мәгариф көтебханәсе» дигән җәмгыять оештыра һәм 1905 елга кадәр аның белән җитәкчелек итә.

1905 елда – «Казан мөхбире» дип аталган беренче татар газетасында, 1906 елда «Азат» газетасында эшли, соңгысының фактик җитәкчесе була; шул ук елны – «Азат халык» дигән яңа исем белән чыга башлаган әлеге газетаның нашире һәм мөхәррире. 15 саны чыкканнан соң, революцион эчтәлекле материаллар бастырган өчен газета ябыла, ә Г.Камалга штраф салына.

1908-1909 елларда ул «Яшен» сатирик журналын чыгара һәм аның нашире була, 1917 елга кадәр – «Йолдыз» (191-1913 елгы Балкан сугышы вакытында - Төркиядә үзхәбәрче), 1917 елдан соң «Эш», «Эшче», «Кызыл Армия» газеталарында эшли.

Г.Камал – драматург мәгърифәтчелек реализмы әдәбиятындагы сәнгатьчә традицияләрнең гомуми юнәлешендә иҗат итә. Әлеге әсәрләрнең лейтмотивы – татар гаиләләрендә өстенлек алган патриархаль тәртипләрне тәнкыйтьләү.

Алдагы елларда Г.Камалның комедиограф буларак та таланты ачыла. Ул милли драматургияне һәм театр сәнгатен «Беренче театр» (1908), «Бүләк өчен» (1909), «Банкрот» (1911), «Безнең шәһәрнең серләре» (1911) комедияләре белән баета. Аларда Камал XX йөз башы татар җәмгыяте тормышын сатира күзлегеннән чыгып гәүләндерә, аталар һәм балалар, и белән хатын, гаилә-көнкүреш мөнәсәбәтләре проблемаларын күтәреп чыга; патриархаль рухта тәрбияләнгән милли сәүдәгәр –мещаннар мохите вәкилләренең истә калырлык образларын иҗат итә.

Иҗат тематикасының төп юнәлеше – патриархаль тәртипләрнең җимерелүен, яңа мөнәсәбәтләр, карашлар тууны, искелек белән яңалык арасындагы каршылыкларны, көрәшне яктырту.

Г.Камал пьесаларында персонажлар «җәмәгать» һәм «мәдәният» эшләре белән мәшгуль (Фатих, Насыйр, Гариф, Кәрим – «Безнең шәһәрнең серләре»), һәр яңалыкка каршы (Хәмзә бай – «Беренче театр»), үзләренең комсыз теләкләрен һәм ихтыяҗларын бар нәрсәдән дә өстен куялар (Хәмидә – «Бүләк өчен»), кешеләр арасындагы эшлекле мөнәсәбәт һәм әдәп кагыйдәләрен бозалар (Сираҗетдин – «Банкрот»). Г.Тукай югары бәяләгән «Безнең шәһәрнең серләре» пьесасында шәһәрдә яшәүче татар халкының барлык катлаулары да (зыялылар, руханилар, чиновниклар, хезмәтчеләр һәм башкалар) гәүдәләнеш таба.

Г.Камал комедияләре конфликтларның үткенлеге, вакыйгаларның хәрәкәтчәнлеге, бай эчтәлекле булуы белән аерылып тора; аларда геройларның рухи дөньясы оста яктыртыла, милли йолалар, гореф-гадәтләр, көнкүреш детальләре (йорт җиһазлары, аларның урыны, чисталык, тәртип; милли аш бүлмәсе һәм башкалар) ачык сурәтләнә. Автор үзен диалог остасы буларак та күрсәтә, аның комедияләренең теле халык юморына бай.

Г.Камалның поэтик иҗаты татарның иҗтимагый тормышында 1905–1907 елгы Революция чорында барлыкка килгән уй–фикер һәм халәтләрне чагылдыра. Ул милләтнең ихтыяҗлары, ирекکә омтылуы, өмет–хыяллар белән яшәве хакында, милли мәгариф, мәдәният һәм фән үсеше турында яза («Азатлык», «Өндәү», 1905; «Безнең кирәк», «И, мөселман, йокламагыл!», 1906 һәм башкалар).

Г.Камал публицистика өлкәсендә дә күп темаларны яктырта:

1905 елгы Дәүләт думасы һәм манифестка мөнәсәбәт («3 нче ноябрь манифесты ни бирә?»; «Дума, дума, дума», 1906; «Депутатлар озату», 1907 һәм башкалар), татар иҗтимагый тормышы мәсьәләләре («Кем гаепле?», 1905; «Искелек сакчыларына ачык хат», 1906; «Ачларга ярдәм эшләре», 1907; «Иван Николаевич Харитонов», 1909; «Кыз сату», 1912 һ.б.).

Хикәяләрендә Г.Камал бушка, юкка вакыт сарыф итүне тәнкыйтьли, халыкка һәм җәмгыятькә файдалы эшләр башкарырга чакыра («Сабирхәзрәт яки гыйбрәт», 1903; «Күгәргән алтыннар», 1909).

Г.Камал татар әдәбияты һәм театры үсешен игътибар белән күзәтә, күп санда әдәби–тәнкыйть мәкаләләре һәм рецензияләр бастырып чыгара («Татарча театр», «Габдулла Тукаев шигырьләр», 1907; «Ачлык кушты», 1908; «Яңа әсәрләр», 1909; һәм башкалар).

Ул, революцион эчтәлекне традицион поэтик формаларда сурәтләп, гражданнар сугышы елларында илдә һәм республикада барган вакыйгаларны яктырта.

Г.Камал күп кенә рус һәм чит ил драматургларының әсәрләрен татар теленә тәрҗемә итә: «Өйләнү» – «Женитьба» һәм «Ревизор», Н.В.Гоголь; «Яшенле яңгыр» – «Гроза», А.Н.Островский; «Саран» – «Скупой» һәм

«Ирексездән табиб булу» – «Лекарь по неволе», Ж.Б.Мольер; «Һинд кызы» – «Индианка», Г.Хәмид һәм башкалар.

Г.Камал рәсем ясау остасы да була. Ул Г.Тукай әсәрләренә беренче иллюстрацияләр ясый, шулай ук «Яшен» (1907–1908), «Ялт–Йолт» (1908–1910) журналларындагы актуаль иҗтимагый һәм сәяси темаларга сатирик рәсемнәр авторы да.

1920 елларда Г.Камал татар каллиграфиясен камилләштерә, «Чаян» журналы, «Кызыл байрак» газетасы өчен шрифтлар эшли. Ул Татарстан драматургиясе классигы, җәмәгать эшлеклесе. Галиәскар Камалның әдәби–драматургия эшчәнлеге татар театры барлыкка килгәнче күпкә алдарак башлана. Нәкъ менә шул сәбәптән аны Татарстан драматургиясенең атасы дип саныйлар.

Аның истәлегенә Татар дәүләт академия театры Г.Камал исемен йөртә. Казанда Г.Камал урамы бар.

**Әдәбият**

1. Әхмадуллин А. Татар драматургиясенә нигез салучы // Татар драмасының горизонтлары: әдәби–тәнкыйди мәкаләләр. Казан, 1983 ел

2. Гайнуллин М.Галиәскар Камал // XIX гасыр татар әдәбияты Казан, 1975.

3. Чыганак: https://tatarica.org/tat/razdely/kultura/literatura/shheslr/kamal–galisgar Онлайн – энциклопедия Tatarica

4. Чыганак: https://biographe.ru/znamenitosti/galiaskar–kamal

## 10 СЫЙНЫФТА “ТЕЛ ҺӘМ СӨЙЛӘМ” ТЕМАСЫН ӨЙРӘНҮ

Гимранова Э.Ф.,
КФУның Алабуга институты студенты.
Фәнни җитәкче: Камаева Р.Б.

“Дәрес – мәктәптә укыту-тәрбия процессын оештыруның төп формасы. Ул процесс– укытучы һәм укучының бердәм-эзлекле эшләве. Укучылар зур активлык күрсәткәндә, укытучы аның активлыгын уңышлы оештырганда гына дәресләр нәтиҗәле була ала” [Вәлиева 2000: 66].

Мәктәпләр алдына куелган бурычлар яктылыгында, укыту процессын интенсивлаштыру таләп ителә. Укыту процессын интенсивлаштыру –белем суммасын арттыру белән бергә, белемнең сыйфатын камилләштерү дә ул. Менә шуңа күрә дә укытучыдан дәресләрне укучыларга ныклы белем бирерлек, алган белемен тормышта файдалана алырлык, укучыларның акыл сәләтен үстерерлек һәм аларга төрле тәрбия бирерлек итеп оештыру таләп ителә.

Дәрестәге эшнең күләме һәм эзлеклелеге дәүләт программасы тарафыннан билгеләнә. Дәреснең максаты укучыларга билгеле бер күләмдә белем бирү генә түгел, программада каралган кадәр күнекмәләр булдыру. Шуңа күрә дәрестә эш өйрәнүне дә ныгытуны да кабатлауны да үз эченә ала. Дәрестә

өйрәнелә торган материал барлык укучылар өчен дә мәҗбүри, шуңа күрә аңлау дәрәҗәсен күзәтү, игътибарда тотуны, бәяләүне таләп итә.

Бу эшебез кысаларында без Р.К.Сәгъдиева авторлыгындагы 10 нчы сыйныф өчен татар теле дәреслегендә “Тел һәм сөйләм” темасы буенча күнегүләр системасын һәм күрсәтмәлелекне анализлауны максат итеп куйдык.

*1.Күнегүләр системасына анализ.*

*Белем бирү максатыннан* (ягъни теманы аңлату өчен) *түбәндәге күнегүләрне файдаланырга мөмкин:*

27 нче күнегү. Рәсемне карагыз. Марсель Галиев язган җөмләне укыгыз, русчага тәрҗемә итегез, мәгънәсен аңлатыгыз.

Сүздән тәкыялар үрелә, сүздән кылыч йөзе канлана, сүздән гөл илләр көл ителә, сүздән чәч толымы еланга әверелә. (Марсель Галиев)

33 нче күнегү. Рәсемнәрне карагыз, мәгънәләрен аңлатыгыз.

Сез бер-берегез белән ничек аралашасыз? Гомумән, кешеләр әйтәсе фикерләрен ничек җиткерәләр?

35 нче күнегү. Рәсемнәрне карагыз. Балалар нишли? Аларның фикерләрен телдән әйтеп карагыз. Нинди нәтиҗә ясый аласыз?

36 нчы күнегү. Рәсемнәрне карагыз, сөйләм төрләрен исегезгә төшерегез, нәтиҗә ясагыз.

*Күнекмәләр үстерү максаты*ннан *түбәндәге күнегүләрне файдаланырга мөмкин:*

*1)русчадан татарчага, татарчадан русчага тәрҗемә итү күнекмәләрен үстерү:*

28 нче күнегү. *Танылган америка сәясәтчесе Даниел Уэбстер фикерен укыгыз татарчага тәрҗемә итеп языгыз.*

30 нчы күнегү. *Укыгыз, эчтәлеген татарча сөйләгез.*

*2) Сәнгатьле уку күнекмәләрен үстерү:*

28 нче күнегү. *Шигырьне сәнгатьле итеп укыгыз.*

32 нче күнегү. *Шигырьне сәнгатьле итеп укыгыз. Сүзнең көче турында тагын нәрсәләр әсти аласыз? Сыйныфташларыгыз белән фикер алышыгыз.*

*3) Бәйләнешле сөйләм телен үстерү:*

34 нче күнегү. *Текстны укыгыз, эчтәлеген татарча сөйләгез, фикер алышыгыз. Кайбер телчеләр хәзерге заманда язма һәм телдән сөйләмнән тыш өченче төр – Интернет- сөйләм дә киң җәелеш таба дп белдерәләр.Үзегезнең тәҗрибәдән чыгып Интернет-сөйләмгә хас үзенчәлекләрне әйтеп карагыз.*

*37 нче күнегү. Укыгыз, исегездә калган аңлатмаларны сөйләгез. Укучыларны өмәгә чакырып монолог төзеп языгыз.*

39 нчы күнегү. *Укыгыз, эчтәлеген русча аңлатыгыз. Сыйныфташларыгыз белән төрле ситуацияләргә бәйле диалоглар төзегез.*

*4) Дөрес язу күнекмәләрен үстерү.*

40 нчы күнегү. *Нокталар урынына тиешле хәрефләрне куеп укыгыз. Күчереп языгыз.*

*5)Иҗади фикерләү сәләтен үстерү.*

44 нче күнегү. Сүзләрне 3 төркемгә бүлеп языгыз. Кайсыларын берничә жанрга кертеп була? Сыйныфташларыгыз белән төркемнәргә бүленеп, берничә очракка мисал үрнәгендә, бер-берегезгә презентацияләр тәкъдим итегез.

*“Тел һәм сөйләм” темасында күрсәтмәлелек.*

Дәрестә төрле күрсәтмәлелектән файдалануның әһәмияте зур. Күрсәтмәлелек программа материалын укучының аңлы рәвештә үзләштерүе өчен шарт булып тора. Күрсәтмә материал берничә яктан ярдәм итә: 1) абстракт күренешләрне конкретлаштырырга; 2) конкрет фактларны өйрәнүдән йомгаклауга, кагыйдәләрне өйрәнүгә, лексик һәм стилистик формалардан дөрес файдаланырга; 3) укучыларда фән белән кызыксынуны, күзәтүчәнлекне үстерергә [Вәлиева 2000: 22].

“Тел һәм сөйләм” темасын өйрәнгәндә түбәндәге күрсәтмә материаллар файдаланырга мөмкин: таблица, рәсем, карточкалар, картина.

*Таблица.*

| Монолог | | |
|---|---|---|
| Хәбәр итә торган | Ышандыра торган | Йогынты ясый торган |
| Белдерү, чыгыш, отчет, доклад, лекөия | Тәбрикләү, тантаналы чыгыш, уңыш теләү, хәерле юл теләү | Сәяси чыгыш, көрәшкә яки укуга өндәү |

[Сәгъдиева 2017: 26]

Таблица өстендә эшне укучылар үзләре мөстәкыйль рәвештә нәтиҗәгә, гомумиләштерүгә килә алырлык итеп оештыруның әһәмияте зур. Аның эчтәлеге укучыларда ныгып калсын өчен, аларның үз мисаллары яки әдәби әсәрдән алган мисаллар белән таблицаны дәфтәрләренә сыздыру, контроль эшләр яки имтиханнар алдыннан, яисә чирек азагында алардан кабат файдалану һ.б. алымнар куллану бик әһәмияле. Дәреснең актульләштерү этабында кулану уңай нәтиҗә бирә.




Сүздән тәкыялар үрелә, сүздән кылыч йөзе канлана, сүздән гөл илләр көл ителә, сүздән чәч толымы еланга әверелә. (Марсель Галиев)

[Сәгъдиева 2017: 20]

*Рәсем.* Рәсем яңа материалны аңлатканда һәм нәтиҗә чыгарганда, аны ныгытканда файдаланыла. Ул укучыларның танып белү эшчәнлеген үстерергә,

мөстәкыйль фикер йөртергә һәм үткәнне хәтердә ныгытырга ярдәм итә. Рәсемнәр ярдәмендә мисал һәм нәтиҗәләр аңлаешлырак була; абстракт нәтиҗәләр рәсемнәрдә күрсәтелгәннәрдән чыгып бирелә.

*Карточка.*

| |
|---|
| 1 нче карточка.<br>*Бирем.* Бирелгән сүзләрне өч төркемгә аерып языгыз.<br>Записка, лекция, интервью, дусларча әңгәмә, ток-шоу, гаиләдә сөйләшү, рәсми сөйләшү, доклад, шәхси көндлектәге язмалар, диспут, рәсми хат, оратор чыгышы, теләк теләү, телефоннан сөйләшү, доклад турында фикер алышу. |

Карточкалар укытуны индивидуальләштерү, вакыттан дөрес файдалану, укучыларны мөстәкыйль эшләргә өйрәтү һәм аларның фикер йөртүләрен, акыл эшчәнлекләрен үстерү, нәтиҗәдә, дәресләрнең нәтиҗәлеген үстерү өчен гаять кирәкле. Карточкаларны, укучыларның белем даирәсе һәм материалны үзләштерү дәрәҗәсе төрле булуга карап, берничә вариантта эшләргә була.

Дәреслектәге күнегүләр системасы һәм күрсәтмәлелек укытучыга дәресне мавыктыргыч итеп үткәрү мөмкинлеген бирә. Дәреслектә бирелгән материалдан тыш укытучы үзе дә карточкалар, рәсемнәр әзерләргә мөмкин. Шулай ук электрон ресурслардан файдалану да өйрәнелә торган материалны тирәнрәк үзләштерергә ярдәм итә.

Таблицалар, схемалар, төрле рәсемнәр укыту процессын камилләштерүгә мөмкинлек бирә, укыту сыйфатын яхшыртуга йогынты ясый, укучының фикерләү сәләтен үстерүгә, шәхес буларак формалашуына, эстетик-зәвык булдыруга йогынты ясый.

**Әдәбият**

1.Вәлиева Ф.С. Урта мәктәп һәм гимназияләрдә татар телен укыту методикасы / Ф.С. Вәлиева, Г.Ф.Саттаров. – Казан: Раннур, 2000. – 455б.

2.Дәрес эшкәртмәсе үрнәкләре. Татар теле һәм әдәбият. 1 кисәк. – Казан: РИЦ “Школа”, 2005. – 500б.

3.Сәгъдиева Р.К. Татар теле:рус телендә урта гомуми белем бирү оешмалары өчен уку әсбабы (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен) 10 сыйныф. – Казан: “Мәгариф-Вакыт” нәшрияты, 2017. – 167 б.

## МӘКТӘПТӘ УКУЧЫЛАР ЭШЧӘНЛЕГЕН БӘЯЛӘҮ СИСТЕМАСЫ

Григорьева Е.Н.,
КФУның Алабуга институты студенты.
Фәнни җитәкче: Камаева Р.Б.

Укучылар эшчәнлеген бәяләү проблемасы хәзерге заман мәгарифенең төп проблемаларының берсе булып тора. Белем бирү казанышларын бәяләүдә заманча дөнья тенденцияләре мәктәп программаларын үзләштерү дәрәҗәсен

билгеләүгә түгел, ә укучыларның мәктәптә алган белемнәрен һәм тормыш ситуацияләрендә куллану сәләтен бәяләүгә юнәлтелгән.

Уку нәтиҗәләренә карата таләпләр белем бирү процессын оештыруда сизелерлек үзгәрешләрне күз алдында тота: укытуда системалы эшчәнлек алымына күчү һәм уку нәтиҗәләрен бәяләүдә яңа алымнар булдыру. “Контроль – белем бирү сыйфаты белән идарә итү системасының аерылгысыз бер өлеше, укытучы һәр укучыны контрольдә тота һәм бәяләүне оештыра. Куелган билгеләрнең дөреслеге һәм объективлыгы һәрвакыт беренче урында тора. Белем бирү процессының уңышлы эшләве белем бирү максатларының, эчтәлегенең һәм алымнарының ни дәрәҗәдә заманча булуы белән бәйле. Билгеле булганча, укучыларның белемнәрен тикшерү һәм бәяләү максаты – аларның белем сыйфатын, аларның үсеш дәрәҗәсен тәэмин итү дигән сүз” [Мөхәммәтҗанова 2015].

Дәреснең һәр этабында уку эшчәнлегенең нәтиҗәләрен бәяләү укучыларга хаталарны бетерү буенча эшне мөстәкыйль планлаштырырга мөмкинлек бирәчәк. Контроль ысуллары түбәндәгеләр: телдән сораштыру, язма контроль эш, диктант, зачет, мөстәкыйль эш, контроль эш, практик эш, лаборатор эш, тест. Контрольнең традицион булмаган ысуллары да бар. Дәресләрдә тикшерү эшләре һәр темага кроссвордлар, башваткычлар, ребуслар, шарадлар, викториналар да булырга мөмкин. Контрольнең традицион методларыннан тыш, яңа тикшерү чаралары тәкъдим ителә: кейс, проектлар, портфолио, тестлар. Һәр нәтиҗәнең үзэшчәнлеген бәяләү критерийлары (эшчәнлек критерие) бар.

Бәяләүнең якынча критерийлары:1. Өй эше ни дәрәҗәдә үтәлгән. 2. Дәрестә эш активлыгы. 3. Дәрес темасын ничек аңлау. 4. Укытучының сорауларына ничек җавап бирү. 5. Дәрестә дисциплина. 6. Төркемдә эшләү (хезмәттәшлек).

Кейс – бу биремнәр пакеты, индивидуаль яки төркемле, алар реаль проблеманы ассызызыклый, ул гына да түгел, үзенчәлекле чыгу юлын эзләү өчен укучы, өйрәнелә торган фән буенча белемнәрен кулланып, проблемалы ситуациягә анализ ясарга, карарлар тәкъдим итәргә һәм нәкъ менә шушы вариантларны нигезләргә тиеш. Кейс – контроль инновацион бәяләү чарасы. Уку процессында кейс белән эшләү технологиясе түбәндәге этапларны үз эченә ала: укучыларның кейс материаллары белән индивидуаль мөстәкыйль эше; төп проблеманы күзаллауны килештерү буенча кечкенә төркемнәрдә эшләү; гомуми дискуссиядә кечкенә төркемнәрнең нәтиҗәләрен тәкъдим итү һәм экспертиза үткәрү (уку төркеме кысаларында).

Кейс-методны куллану төрле мәгълүмат чыганаклары белән эшләү күнекмәләрен үстерергә мөмкинлек бирә. Кейста бәян ителгән проблеманы хәл итү процессы – танып-белү эшчәнлегенең коллектив характерын күздә тоткан иҗади белем бирү процессы. Кейс-метод катлаулы булмаган структуралаштырылган проблемаларны хәл итәргә өйрәтә, аларны аналитик ысул белән хәл итәргә булмый. Кейс-метод шәхеснең компетентлы

сыйфатларын үстерә: аналитик осталык, гамәли осталык, иҗади осталык, коммуникатив осталык, социаль осталык. Кейс-метод структурасында бәхәсләр, дискуссияләр, аргументацияләр булу фикер алышуда катнашучыларны аралашу нормаларын һәм кагыйдәләрен үтәргә күнектерә [Камаева 2015].

Портфолио – мәктәп укучыларының шәхси казанышларын бәяләү методы буларак кабул ителә. Портфолио укучыларның уку-укыту, иҗади, социаль, коммуникатив һ.б. төр эшчәнлекләрендә ирешкән нәтиҗәләрен исәпкә алырга мөмкинлек бирә [Крылова 2015: 218].

Проект – заманча бәяләү алымнарына карый. Укытучы күзлегеннән бу проблема рәвешендә формалаштырылган бирем; укучыларның максатчан эшчәнлеге һәм алар тапкан проблеманы хәл итү ысулы буларак эшчәнлек нәтиҗәсе; бу-укучыларны үстерү, укыту һәм тәрбияләү чарасы. Укучылар күзлегеннән бу нәрсә дә булса кызыклы, мөстәкыйль эшләү мөмкинлеге; бу үз-үзеңне күрсәтергә, белемнәрен ныгытырга, ирешелгән нәтиҗәне күрсәтергә мөмкинлек бирә торган эшчәнлек. Проектлар методы укытучыга уку эшчәнлегенең традицион алымнарын, формаларын үзгәртү өчен киң мөмкинлекләр бирә, укыту процессын оештыруның бөтен системасын сыйфат ягыннан яңа дәрәҗәгә чыгара. Ул төрле яшьтәге укучылар белән эшләүдә, төрле катлаулылыктагы материалны өйрәнгәндә дә кулланыла ала.

Дәрестә укучыларның үз эшчәнлекләрен бәяли белүләре – заманча дәрес кысаларында бик мөһим фактор. Аны төрле этапларда эшләргә мөмкин. Рефлексия – кешенең үз халәтең, үз эшен, кылган гамәлләрең һәм узган вакыйгаларны анализлауга юнәлтелгән уйлануы. Шул ук вакытта рефлексиянең тирәнлеге, үзанализ кешенең белемлелегенә, әхлакый хисләр үсешенә һәм үз-үзен тикшерү дәрәҗәсенә бәйле. Рефлексия ул гади генә үзең белән сөйләшү. Рус теле сүзлеге рефлексияне үзанализ буларак аңлата. Заманча педагогикада рефлексия ул – үзанализ һәм аның нәтиҗәләре. Рефлексия дәрестә төрле чаралар ярдәмендә тормышка ашырыла.

**Әдәбият**

1.Камаева Р.Б. Федераль дәүләт белем бирү стандартларын тормышка ашыруда татар теле һәм әдәбияты укытучысына фәнни-методик ярдәм / Р.Б.Камаева, А.Х. Мөхәммәтҗанова. – Казан: Татарстан Республикасы Мәгарифне үстерү институты, 2015. – 110 б.

2.Крылова О.Н. Технология формирующего оценивания в современной школе: учебно-методическое пособие. – Санкт-Петербург: КАРО, 2015. – 128 с.

3.Мәхәммәтҗанова А.Х. Татар теле һәм әдәбияты укытучысына ярдәмгә: ФДББС турында белешмәлек һәм терәк схемалар/төз. А.Х.Мөхәммәтҗанова, Р.Б.Камаева. – Казан: Татарстан Республикасы Мәгарифне үстерү институты, 2015. – 68б.

# ГАЛИӘСГАР КАМАЛ ИҖАТЫНЫҢ ТӨРЛЕЛЕГЕ

Гурьева К.С. ,
Мамадыш шәһәренең Кызыл Тау урта белем мәктәбе укучысы.
Фәнни җитәкче: Антонова Д.А.

Галиәсгар Камал үзенең 35 еллык иҗат гомерендә бик күп иҗат җимешләре язган шәхес. Аның иҗатының төрлелеген – сәхнә әсәрләренең күп өлешен комедияләр, аннан кала драма һәм пьесалар алып тора. Галиәсгар Камалның инкыйлабка кадәр һәм аннан соң язган сәхнә әсәрләре бик күп, әлбәттә.

Галиәсгар Камалның *"Беренче театр"* комедиясе – үлми торган, яшәргә тиешле иҗат җимеше. Әлеге *«Беренче театр»* комедиясендә, иң үзәк образлардан берсе – бөтен искелекне, кирелекне, үзсүзлелекне, мин беләмлекне үзендә гәүдәләндергән карт Хәмзә бай. Ул, үзенең характеры белән, яңалык булганлыгы өчен генә яңалыкка каршы торучы кеше буларак сурәтләнә. Ул, һәрбер кеше минемчә уйларга, минемчә яшәргә, минемчә торырга, киенергә, минемчә йөрергә тиеш дип уйлый. Әгәр көченнән килсә, ул яшьләрне дә үзенчә генә яшәтер иде, ләбаса [Камал 1929: 9].

*«Беренче театр»* комедиясендәге башка образлар да: Вәли белән Гафифә, Биби һәм Хәбибрахман белән Факиһә образлары да бик матур эшләнгәннәр. Тик аларга караганда күп көчле эшләнгән Хәмзә бай тибы белән томаланып кына, алар беркадәр кечерәя төшәләр [Камал 1929: 19].

Әсәрдә сурәтләнгәнчә, Гафифә Хәмзә байның үзенчә тәрбияләп үстергән кызы. Ул гомерендә асыл күлмәк белән ат кәмитеннән башка нәрсәне белмәгән чеп–чи мещанка. Театрга барырга хәзерләнгәч, егермеләп күлмәкне төсләре, материяләре һәм тегелү формалары белән санап чыгуга карамастан, театрга киеп барырлык килешле күлмәк таба алмый; ахырдан: *«Үзең дә ичмаса, бер кеше төсле чибәр күлмәк алып биргәнең дә юк. Бер җиргә бара башладың исә, киеп барырлык һичбер юньле матур күлмәгем юк»,* – дип иренә үпкәли [Камал 1929: 22].

Галиәсгар Камал үзенең инкыйлабтан соң язган әсәрләрендә критик реализмнан социалистик реализм методына күчә. Аның инкыйлабтан соң социалистик реализм нигезендә язылган зур әсәрләреннән *«Хафизалам иркәм»* пьесасы бар. Инкыйлабка кадәр, 20 ел буена шәһәрнең буржуа–мещан тормышын язып килгән Галиәсгар Камал, Бөек Октябрь инкыйлабыннан соң әдәбиятта авыл темасын яктырту турында да кайбер тәҗрибәләр ясап карый. Аның *«Җантаһир белән Җанзөһрә»*се шул юлда ясалган беренче адым булса, *«Хафизалам иркәм»* комедиясенә шул юлда ясалган икенче бер җитдирәк адым дип карарга туры килә. Галиәсгар Камал, балалык вакытын авылда уздырганлыктан һәм авыл белән һәрвакыт бәйләнештә булганлыктан, авыл тормышын бик яхшы белә [Камал 1929: 32].

Галиәсгар Камалның драматурглык, шагыйрьлек һәм артистлыктан тыш, сәнгатьнең башка өлкәләрендәге хезмәтләре дә бар. Ул үз заманында татар

дөньясында танылган карикатурачы һәм художник. Татар динчеләре һәм татар феодаль буржуазиясе карашыңча рәсемгә төшү, *«сурәт ясау»* һәм өйгә сурәт кертү *«хәрам»* булып танылган бер заманнарда, Галиәсгар Камал Г. Тукай белән үзе тарафыннан чыгарылган көлке *«Яшен»* журналының бөтен карикатураларын үзе ясый һәм, *«сурәт ясауга»* каршы кампания алып баручыларның үз сурәтләрен ясап бастырып, укучы массага аларны фаш итә, алардан көлә. Карикатурачылыктан кала, Галиәсгар Камал үз заманында танылган каллиграф та әле. Ул гарәп хәрефләре белән бик матур язучы иде. [Гайнуллин 1978: 11].

Шулай ук, Галиәсгар Камал татар матбугаты һәм әдәбиятында, иң башлап дип әйтерлек, тәрҗемәчелек эшенә керешеп, шул өлкәдә күп эшләгән язучы буларак та дан тота. Аның тәрҗемәчелеге ике тармак буенча бара: берсе, алданрак башланганы исә – әдәби тәрҗемәчелек, икенчесе, гомеренең иң күп өлешен куеп эшләгәне – гади тәрҗемәчелек. Ләкин әлегә кадәр аның тәрҗемәчелек эше бөтенләй тикшерелгәне юк дип әйтсәк, ялгыш булмас. Хәтта аның тарафыннан тәрҗемә ителгән сәхнә әсәрләренең дә дөрес кенә хисабы алынып җиткәне юк. Бәлки ул үзе дә аның хисабын югалткан булгандыр, һәрхәлдә, аның тарафыннан рус һәм төрек телләреннән тәрҗемә ителгән сәхнә әсәрләренең саны 50 – 60 тан да ким булмаска тиеш. Болардан, әлбәттә, бик күбесе басылмаганнар һәм хәтта, сәхнәдә дә уйналмаганнар.

Галиәсгар Камалның әдәбият өлкәсендә драматургиядән кала иң күп эшләгән жанры – поэзия. Аның мәдрәсәдә укыган вакытларында ук шигырьләр язганлыгы мәгълүм. Ләкин матбугатка чыкмаганлыктан һәм сакланмаганлыктан, аның ул вакыттагы шигырьләре турында бернәрсә дә әйтергә мөмкин түгел. Аның 1901 елда язылып, басылмыйча, Мәкәрҗәдә халык алдында декламировать ителгән беренче шигырьләреннән *«Приказчик»* дигән шигыренең кайбер өзекләре генә сакланып калган. Ул шигырь шулай башланып киткән:

*Приказчикны кем дисең,*
*Әллә аны белмисең?*
*Хуҗалары кул астында*
*Тоткын булган кол алар* [Камал 1942: 38].

Ягъни, әлеге шигырь юлларыннан күренгәнчә, Галиәсгар Камал үзенең беренче шигырьләрендә үк приказчикларны яклап, байларга каршы чыга.

Аның күп кенә шигырьләре музыкаль һәм башка фольклор (җыр, такмак, бәет) формаларына ияреп язылганнар. Андыйлардан: *«Бишек җыры»* көенә ияреп язылган *«Байлар бишеге»*, *«Сандугач күгәрчен»* көенә салып язылган «*БурясУи теләге»*, *«Әппипә»* көенә салып язылган *«Бию көе»*, *«Яңа типта халык җырлары»*, *«Һай дөнья»*, *«Матур яр, кәнәри»*, *«Яңа җизнәкәй»*, *«Табышмаклар»* һәм башкалар бар.

Нәтиҗә ясап шуны әйтергә кирәк, Галиәсгар Камал – XX йөз башы татар иҗтимагый һәм мәдәни тормышында үзәк фигураларның берсе. Актив иҗат эшчәнлеген XIX йөз азагында ук башлап җибәргән Галиәсгар Камал киңкырлы

талант иясе буларак танылa. Ул бер үк вакытта мөхәррир дә, прозаик та, публицист та, драматург та, шагыйрь дә, хәтта рәссам–карикатурчы да. Мондый киң колачлы шәхесләрне табуы да бик кыен. Әлбәттә, Галиәсгар Камал чын милли характерлар иҗат иткән шәхес. Аның абыстайларын, асрауларын, абзыкайларын башка бер генә милләт вәкилләре белән дә бутап булмый. Алар үзләренең кимчелекләре: наданлыклары, кирелекләре, сөйләү рәвешләре, бүген бик тә вак күренгән омтылыш–теләкләре белән гаять милли, үзенчәлекле, кабатланмас характерлар булып торалар. Алар чын татарча сөйләшәләр, уйлыйлар–ниятлиләр, аларның кирелекләре дә, наданлыклары да чын татарча. Халыкчан, чын сөйләм телен сәхнәгә кертүдә, сәхнә телен формалаштыруда Галиәсгар Камал гаять зур роль уйнады, бу юлда чын остаз була белде.

**Әдәбият**


1. Камал Г. Галиәсгар Камал әсәрләре: 2 томда: 1 т.: пьесалар / кереш сүз авт. Ф.Сәйфи. – Казан: Яңалиф,– 1929. – 178 б.
2. Гайнуллин М.Х. Галиәсгар Камал (1879 – 1933). – Казан: Татар. кит. нәшр., 1978. – 40 б.
3. Камал Г. Сайланма әсәрләр. – Казан: Татгосиздат, 1942. – 388 б.


## МӘГЪРИФӘТЛЕ ҺӘМ МӘДӘНИЯТЛЕ БУЛУ – ҺӘР ХАЛЫКНЫҢ МӘҢГЕЛЕК ХЫЯЛЫ


Гыйльметдинов А.С.,
Алабуга шәһәренең 8 урта мәктәп укучысы.
Фәнни җитәкче: Якупова Ф.М.


Татар халкының талантлы каләм ияләре, мәгърифәтчеләре, җәмәгать эшлеклеләре, артистлары бик күп. Шулар арасында Галиәсгар Камал лаеклы урынны алып тора. Татарның иң абруйлы театры да аның исемен йөртә. Бу театрның тууы, үсүе, танылуы талантлы драматург, актер, режиссер Г.Камал исеме белән бәйле. Ул оста тәрҗемәче, шагыйрь, рәссам – карикатурачы да була. Татар халкының газета һәм журналлары чыга башлавы да шушы исемгә барып тоташа.

Галиәсгар Галиәкбәр улы Камалетдинов 1879 нчы елның 6 нчы гыйнварында Казанда туа. Шул заманның алдынгы мәдрәсәләреннән саналган “Мөхәммәдия”дә укый, бер үк вакытта рус мәктәбендә дә башлангыч белем ала.Шул елларда әдәбият һәм театр сәнгате белән кызыксына башлый.”Бәхетсез егет” исемле беренче драма әсәрен яза.Камал Гоголь, Островский, Горький, Мольер һәм башкаларның әсәрләрен татар теленә тәрҗемә итә.

1923 нче елда аңа “Хезмәт герое” исеме, 1929 нчы елда “Татарстанның халык драматургы” дигән мактаулы исемнәр бирелә.

Г.Камал 1933 нче елның 16 нчы июнендә Казанда вафат була.

1939 нчы елда Татар дәүләт академия театрына Г.Камал исеме бирелә. Казан, Чаллы, Алабугадагы урамнар аның исемен йөртә | Мортазин 2022: 132 |.

Г.Камал, шул чор язучыларына хас булганча, татар әдәбиятының әһәмиятен, ролен, бурычларын югары дәрәҗәдә күзаллый. Татар халкын аңлы – белемле итүгә, киң һәм тулы мәгънәдә аның культурасын үстерүгә үзенең гомерен багышлый. Мәгърифәтле һәм мәдәниятле булу – һәр халыкның мәңгелек хыялы.

1905 нче ел революциясе татар халкына шифалы ирек җилләрен алып килә, киләчәккә өмет уята. Манифест игълан ителә, татарча – газета журналлар басыла башлый.| Ганиева 2004 : 9 |.

1906 нчы елның 22 нче декабрендә Казанда беренче мәртәбә ачык рәвештә татарча спектакль куела; татар театры яшибашлау драматургиягә дә куәт, этәргеч бирә, чөнки театр яшәсен өчен, яңадан – яңа пьесалар кирәк, театрга ярдәм кирәк| Ганиева 2004 : 10 |.

Драматургия театрның канаты икәнлеген яхшы аңлаган Г.Камал драма һәм комедияләр яза. Ул иҗат иткән "Беренче театр", “”Бүләк өчен”, “Банкрот”, “Безнең шәһәрнең серләре” комедияләрен, “Хафизәләм иркәм”, “Өч тормыш” , “Бәхетсез егет”, “Уйнаш” дрмаларын халык яратып укый, театрга йөри. Чыннан да, әсәрләре “ Сәйәр ” труппасы тарафыннан сәхнәләштерелеп, халык арасында популярлык казана. Казан яшьләре Г.Камалны үзләренә чакырып, спектакльләр күрсәтә, аннанкиңәшләр сорый. Камал аларга бик теләп ярдәм итә, беркайчан да каршы килми.

Башлап йөрүче Галиәсгар Камал булса, аңа ярдәмгә ашкынып торучы талантлы язучылар, мәгърифәтчеләр: Фатих Әмирхан, Гафур Коләхмәтов, Сәгыйт Рәмиев, Кәрим Тинчурин була. Прозаиклар, шагыйрьләр, артистлар да пьеса язалар. Араларында зур драматург булып, аерылып чыгучыларын да беләбез. Димәк, Г.Камал тирәсенә талантлы язучылар, көчле шәхесләр туплана; татар драматургиясе, әдәбиятның поэзия, проза төрләреннән дә егәр алып, зур тизлек белән үсеп китә һәм XX гасыр башында ук инде татар классик әдәбиятының көчле бер тармагына әйләнә.|Ганиева 2004: 10 |.

Г.Камал театр белән генә чикләнеп калмаган. Ул бик күп редакцияләрдә ару – талуны белми эшләгән. 1904 –1905 елларда Хәнәфиевләр, Һ. Атласиның “Мәгариф” нәшриятындагы китап кибетендә ялланып эшли.Алкинның “Казан мөхбире” газетасында хезмәт куя. Апанаевның”Азат” газетасында секретарь була. Мулланур Вахитов чыгара торган “Кызыл байрак”газетасында һәм “Совет восточного фронта”ның нәшрият бүлегендә тәрҗемәче булып эшли. “Кызыл Татарстан” газетасын оштыручыларның берсе була. “Кайвакыт мин бөтен редакциядә утырып калам. Редактор да, секретарь да, корректор да, экспедитор да үзем булам, курьер да булам, икешәр – өчәр көн өйгә кайтмыйча, шунда эшләп утырам”, – дип яза Г.Камал бу еллардагы эшчәнлеге хакында | Мортазин 2022: 133 |.

Г.Камал Габдулла Тукай, Фатих Әмирхан, Сәгыйт Рәмиев, Шәриф Камал, Мәҗит Гафури, Галимҗан Ибраһимовлар белән фикердәш, хезмәттәш булып

эшли. Эшчәнлеген санап чыгу да: 1900 нче елда “Мәгариф көтебханәсе”н оештыра, 1906 нчы елдан “Азат халык”, “Йолдыз” газеталарында эшли; Тукай белән бергәләп, “Яшен”, “Ялт – йолт” сатирик журналларын чыгара; татар театр оештыру эшендә турыдан – туры катнаша –Галиәсгар Камалның ни дәрәҗәдә белемле, киң фикерле, алдынгы карашлы шәхес һәм талант иясе икәнлеген раслап тора. Ул үзенең замандаш язучылары, культура – иҗат әһелләре белән татар дөньясындагы каралык, караңгылык белән көрәшә; шуның өчен замандашларының, укучыларының һәм тамашачыларының ихтирамын казана | Ганиева 2004: 9 |.

Шулай итеп, белгәнебезчә, Г.Камал татар халкын мәгърифәтле итү өчен, армый –талмый, үзен кызганмый хезмәт куя: “Мәгариф китапханәсе” исемле китап бастыру һәм тарату ширкәтендә эшли, бик күп газета һәм журналлар аның тырышлыгы белән чыга.

Уйлап куясың да, гаҗәпкә каласың. Ул кайдан барысына да вакыт тапты микән? Үз халкын мәгърифәтле, белемле итеп күрергә теләү, янында үзе шикелле талантлы, милләт өчен янып – көеп йөрүче язучылар, шагыйрьләр, җәмәгать эшлеклеләре булу Г.Камалга көч һәм дәрт биргәндер.

Г.Камал үзенең әсәрләре белән дә татар халкын тәрбияләде. “Бәхетсез егет” дрмасындагы Закир ни өчен бәхетсез? Сәбәп кайда? Кем гаипле? Бу сораулар ачык итеп куелган һәм Г. Камал мәгърифәтчелек позициясеннән торып, ачык җавап бирә – Закир тәрбиясез, әхлаксыз булганы, бозык юлга кереп киткәне өчен бәхетсез. Камал Закир язмышын хәл иткән төп сәбәп итеп, аңа гаиләдә дөрес тәрбия бирелмәүне, аның әтисенең сәүдә эшләре белән мавыгып, улына җитәрлек игътибар бирмәвен, таләпчән булмавын саный. Әнисенең дә улын иркәләп бозуы – дөрес тәрбия булмауның үрнәге. Әсәрдә бу фикер турыдан –туры әйтелә, һәм бу гаиләгә капма-каршы итеп, Сабитовлар гаиләсе тасвирлана. Менә бу гаиләдә ата-ана да, кыз һәм егет булып җиткән балалары да җитди мәсьәләләр турында гына уйланалар, сөйләшәләр. Тәүфыйклы булгач, балалар да бәхетле ]Ганиева 2004: 11].Балалар бәхетле булса, әти – әниләр дә бәхетле.

Шулай итеп, Г.Камал үзенең гомерен татар халкын мәгърифәтле итү эшенә багышлый : матбугатыбыз тарихында күренекле роль уйнаган газета – журналларны бастырып чыгаруны оештыра һәм җитәкли, бик күп сәхнә әсәрләрен татар теленә тәрҗемә итә, клубта эшләүче хезмәткәрләр өчен кулланмалар яза, реаль чынбарлыкны чагылдырган драма һәм комедияләр иҗат итә. Аның әсәрләре драматургиябезнең нигез ташын тәшкил итә, әдәбиятыбызның алтын хәзинәсе булып тора. Әсәрләре күпме буын кешеләрен тәрбияли.

Без татарның талантлы улы – Г.Камалның иҗатын, мәгърифәт өлкәсендәге эшчәнлеген белергә һәм дәвам итәргә тиеш.

**Әдәбият**

1. Ганиева Ф.Ә.”Татар классик драматургиясе: Галиәсгар Камал, Мирхәйдәр Фәйзи”. – Казан: Татарстан Республикасы”Хәтер” нәшр., 2004.– 463б.

2. Мортазин М.Г. “ 150 атаклы татар турында. Кызык та, кызганыч та”: Публицистик язмалар.– Казан: “Мәгариф– Вакыт” нәшр., 2022. – 384 б.

## ТАТАР ТЕЛЕНДӘ РӘВЕШНЕҢ ЛЕКСИК–ГРАММАТИК АСЫЛЫ

Гыйльметдинова.Ф.Ф.,
КФУ ның Алабуга институты студенты.
Фәнни җитәкче: Хәйруллина Ә.С.

Морфологик яктан сүзләр татар теленең XVIII йөз ахырында чыга башлаган беренче грамматикаларында ук сүз төркемнәренә берләштереп өйрәнелүгә карамастан, аларны төркемләүдә әле бүгенге көндә дә бәхәсле һәм ахырга кадәр хәл ителмәгән мәсьәләләр бар.

Объектив кыенлык – грамматик (морфологик һәм синтаксик) яктан охшаш сүз төркемнәре булу. Шуңа бәйле рәвештә хәзерге татар тел белемендә сыйфат һәм рәвеш сүз төркемнәрен бер–берсеннән аеру иң бәхәсле мәсьәләләрнең берсе булып тора. Сыйфат та, рәвеш тә морфологик яктан төрләнми, аларга өлешчә дәрәҗә категориясе генә хас. Синтаксик яктан сыйфатның җөмләдәге типик функциясе аергыч һәм хәбәр булып килү; сыйфат сүз төркеменә кергән бер төркем сүзләр (*матур, яхшы, начар* һ.б.) җөмләдә хәл булып та килә алар: ***матур*** *җырлый*, ***яхшы*** *эшли*, ***начар*** *күрә* һ.б.

Рәвеш башлыча җөмләдә хәл функциясендә килә, аерым очракларда ул, сыйфат кебек, аергыч булырга мөмкин: ***күп*** *халык*, ***аз*** *сүз*, ***әкрен*** *кеше* һ.б. Сыйфат һәм рәвешне аеру өчен иң әһәмиятле критерий итеп, аларның лексик–семантик ягы алына, ягъни – сыйфатлар тел кулланылышында күбрәк предмет билгесен, ә рәвешләр эш–хәл билгесен белдерәләр.

Хәзерге тел белемендә сүз төркемнәрен аеру, сүзләрне төркемләүдәге төп бәхәсле моментлар сыйфат–рәвеш сүз төркемнәренең үзара мөнәсәбәтен ачыклауга кайтып кала.

Телебездәге бу чыннан да катлаулы күренешне аңлатуда башка төрле карашлар да бар. Татар телендә сүз ясалышын өйрәнүгә багышланган хезмәтләрендә, мәсәлән, Ф.Ә.Ганиев мәсьәләне башка фәнни юнәлештә чишүгә омтылыш ясый. Рәвеш һәм сыйфатның охшаш кулланылышын галим конверсия ысулы белән сүз ясалышы буларак билгели [Татар грамматикасы, Т. I]. Бу караш шулай ук татар теленең 3 томлык аңлатмалы сүзлегендәге искәрмәләрдә дә чагылыш тапкан. Әмма бу очракта, безнең карашыбызча, типологиядә сүзләрне төркемләүгә карата куелган төп таләп бозыла, чөнки бер үк сүз, бер үк вакытта һәм бернинди тышкы билгеләрсез, төрле сүз төркемнәренә карый алмый: *матур* – сыйфат, *матур* – рәвеш; *яхшы* – сыйфат, *яхшы* – рәвеш дип билгеләү сүзләрне төркемнәргә бүлү зарурлыгын да юкка чыгара.

Рәвешләрнең күп кенә өлешен тамыр сүзләр тәшкил итә. Мәсәлән: *еш, бик, аз, соң, гел, юри, иртә, кинәт, шәп, җәяү, элек, һаман, гаять, хәзер, ифрат* һ.б. Нигездә болар – гомумтөрки сүзләр, ләкин араларында гарәп һәм фарсы алынмалары да бар: тәмам, ифрат, гаять, һаман һ.б.ш. Рәвешләрнең төп өлешен ясалма сүзләр тәшкил итә. Аларның лексик һәм грамматик структуралары кушымчалау, сүзләрнең кабатлануы, кушылуы һәм рәвешкә күчүе юллары белән тулылана һәм камилләшә. Кушымчалау юлы белән рәвешләр төрле сүз төркемнәреннән, шул исәптән рәвешләрнең үзләреннән дә ясала: *кыскача, бөтенләй, бушлай, икеләтә, күпләп, берәмләп* һ.б. [Татар грамматикасы, Т. II].

Сүзләрне кабатлау юлы белән түбәндәге рәвешләр ясалган: *вакыт–вакыт, гомер–гомергә, алмаш–тилмәш, борын–борыннан, әледән–әле, елның елына, буйдан–буйга.* Сүзләрне кушу нигезендә түбәндәге рәвешләр барлыкка килгән*: бүген, беркөн, быел, берсүзсез, яланаяк, ялангөс* һ.б.

Лексик–грамматик мәгънәләре буенча рәвешләр билге рәвешләре һәм хәл рәвешләренә бүленәләр.

Билге рәвешләре эш–хәл яки билгенең сыйфатын, үтәлү рәвешен, микъдарын, күләм–чамасын белдерәләр һәм үз эчләрендә ике төркемчәгә бүленәләр:

1. Эш–хәлнең үтәлү рәвешен белдергән рәвешләр: тиз (йөрү), кызу (сөйләү), җәяү (кайту), бушлай(бирү), үрле–кырлы (сикерү), ава–түнә (йөрү), батырларча (сугышу), бергә (эшләү), урталай (бүлү) һ.б. Гөлбану ***тиз–тиз*** атасы яныннан китү ягын карады (Г. Ибраһимов).

2. Күләм–чама рәвешләре: сирәк (килү), еш (очрашу), күп (уку), һаман (искә алу), озак (йөрү),икеләтә (түләү), гомергә (онытмау), бераз (ял итү), бөтенләйгә (кайту), ара–тирә (күрешү) һ.б. ***Әкрен*** генә иртәнге салкын җил исеп куйды, усак яфраклары шөлдер–шөлдер итә башладылар (Г. Әпсәләмов).

Эш–хәлне төрле яклап ачыклап килгән рәвешләр мәгънә буенча берничә төркемчщгә бүленә: эш–хәлне үтәлү рәвеше буенча характерлый торган, яки күләм–чамасын, үтәлү дәрәҗәсен белдергән рәвешләр билге рәвешләре дип, ә эш–хәлнең үтәлү вакытын, урынын, сәбәбен, максатын һ.б. белдергән рәвешләр хәл рәвешләре дип атала.

1. Урын рәвешләре: ары (бару), бире (килү), бирегә (килү), югары (очу), түбән (төшү), ерак (бару), еракта (йөрү), ерактан (күренү),якын (килү), янәшә (йөрү) һ.б. Кара болыт зәңгәр итәгеен өстерәп, ***бирегә*** таба килә башлады (И. Гази).

2. Вакыт рәвешләре: кышын (эшләү), җәен (ял итү), көнозын (йөрү), һәрчак (истә тоту), башта (уйлау), былтыр (тәмамлау), быел(эшли башлау), бүген (очрату), иртәгә (кайту), күптән (белү), соң (кайту) һ.б. ***Күптән*** киселгән сынык бит инде ул, ***күптән*** онытылган иде бит инде! (Ә. Еники).

3. Сәбәп–максат рәвешләренә юкка, юктан, бушка, тикмәгә, юри, тиктомалга, заяга кебек рәвешләрне кертәләр. Бу дөньяда без яшибез икән, юкка түгел, юкка түгелдер (Н. Нәҗми)

Шулай итеп, үзләренең гомуми лексик–грамматик мәгънәләре – процесска бәйле булмаган билге белдерүләре белән рәвешләр, башка телләрдәге рәвешләр кебек үк, сыйфатларга якын торалар.

**Әдәбият**


1. Татар грамматикасы: өч томда / проект җит. М.З. Зәкиев; ред. Ф.М. Хисамова. – Тулыландырылган 2 нче басма. – Казан: ТӘhСИ, 2015. – Т. I. – 512 б.

2. Татар грамматикасы: өч томда / проект җит. М.З. Зәкиев. – Тулыландырылган 2 нче басма. – Казан: ТӘhСИ, 2016. – Т. II. – 432 б.

3. Рәвешләрнең ясалышы // studfile.net URL: https://studfile.net/preview/9542680/page:45/ (мөрәҗәгать итү датасы: 17.02.2024).


## ТУГАН ТЕЛ УЛ – БЕЗДӘН СОҢ ДА ЯШӘР ӨЧЕН ТУГАН ТЕЛ


Закирова А.Л.,

Алабуга районы Иске Юраш урта мәктәбе укучысы.

Фәнни җитәкче: Юнусова Л.М.


Гасырлар буе кешелек дөньясында бер тылсымлы көч яши. Борын–борыннан бөек акыл ияләре, укымышлылар, иҗат кешеләре бу көчнең зурлыгына, нәфислегенә сокланганнар.Ул безнең туган телебез – татар теле!Халык тел аша матур хисләрен, күңел түрендә яткан тирән кичерешләрен, киң хыялында гәүдәләнә торган изге теләкләрен белдергән. Телдә халыкның рухы да, табигате дә һәм тормыш–көнкүреше дә чагыла. Һәркемгә кадерле, бернәрсәгә дә тиңе булмаган кыйммәт ул – туган тел. *"Иң татлы тел – туган тел, анам сөйләп торган тел", – дип юкка гына әйтми халык.* Бу телдә әти–әнием сөйләшә, ерак әби–бабаларым дататар телендә сөйләшкән.*"Ананың балага биргән иң зур бүләге – тел". Чынлыкта да, бу шулай. Без өйдә саф татар телендә сөйләшәбез. Ана телендә тәрбияләнгән бала гына, милләтенә, аның теленә һәм гореф–гадәтләренә чын мәгънәсендә ихтирамлы була ала, дип уйлыйм мин.Халкыбызның гасырлар буе яшәп килгән, буыннан–буынга тапшырылган тормыш тәҗрибәсе, гореф–гадәтләре, йола–бәйрәмнәре, әдәбият һәм сәнгать әсәрләре, кыскасы, милләтебезнең рухи байлыгы тел аша буыннардан буыннарга күчә бара. Шулай булганда гына ул сакланып кала, яши.*

Татар теле – үзенең универсальлеге һәм популярлыгы буенча 14 дөнья теле арасында тора. Әмма дөньяда бик күп телләргә бетү, яшәештән туктау куркынычы яный. Соңгы елларда татар теле дә глобальләшү шартларында яшәп калырлык дәрәҗәдә тамыр җәя алмады. Моның сәбәпләрен белергә теләп һәм саклау юлларын эзләп, фәнни эшебезне шушы өлкәдән алдым.

Фәнни эшнең максаты:

1.Татар теленең сакланып калу юлларын барлау.

2.Туган телне, тарихыңны яхшы белү .

3.Милләтпәрвәрлек хисләре, ныклы тормыш позициясе булдыру.

Ана теленең хәзерге хәле безгә туган телгә карата бик җитди мөнәсәбәттә булу бурычын йөкли.

Татарстанда тел сәясәтенең яңа принципларын булдыру мәсьәләсе көн тәртибенә үткән гасырның 80 нче еллар ахырында килеп баса. Бу елларда федерация дәрәҗәсендә дә тиешле норматив–хокукый база формалашабашлый. 1991 елда «РСФСР халыклары телләре турында» федераль закон кабул ителә.

1992 елның июнендә Россия Федерациясе Югары Советының Милләтләр Советы Россия Федерациясе халыкларының телләрен саклау һәм үстерү буенча Дәүләт программасы концепциясен раслый. Россия Федерациясенең Татарстан Республикасы дәүләт суверенитеты турындагы Законы нигезендә, Республикада кабул ителгән закон Татарстан Республикасында дәүләт телләре буларак татар һәм рус телләрен билгели һәм әлеге ике телгә тигез хокук бирелә.

1994 нче елның 20 нче июлендә ТР халыкларының телләрен, бигрәк тә татар телен саклау, өйрәнү һәм үстерү буенча Дәүләт программасы кабул ителә. Ләкин 60 ел буе милли телләрне юк итү сәясәтенең традицияләре көчле булып чыга, русларның гына өстенлеген танырга тырышкан шовинизм үз позицияләрен тиз генә бирергә теләми. Шуңа күрә татар телен тергезү, саклау һәм үстерү эше зур, бик зур кыенлыклар белән бара.

Телләр турындагы Законда язылган ике дәүләт телен дә тигез гамәлгә кертү Югары Совет карары буенча ун ел эчендә, ягъни 2002 нче елда тәмамланырга тиеш, дип карала. Бу – Татарстанда һәр кеше рус телен дә, татар телен дә эштә аралашу дәрәҗәсендә өйрәнергә, белергә тиеш дигән сүз була. Ләкин бу вакыт реаль булып чыкмый. Шуңа күрә 2004 нче елда ТР Дәүләт Советы “Татарстан Республикасы халыклары телләре турында” ТР Законын, үзгәрешләр һәм төзәтмәләр кертеп, яңадан кабул итә. Аның исеме дә бераз үзгәртелә: ул хәзер “Татарстан Республикасы дәүләт телләре һәм Татарстан Республикасында башка телләр турында” ТР Законы дип атала.

Телләр турындагы Законны гамәлгә ашыру өчен, 1994 нче елда кабул ителгән Дәүләт программасы да үзгәртелеп, яңадан төзелә. 2004нче елда “2004–2013 нче елларга Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү буенча ТР Дәүләт программасы” дип исемләнгән яңа программа кабул ителә. Аннан 2014–2020 елларга дәүләт программасы эшләнә. Хәзерге вакытта "2023–2030” елларга Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасындагы башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү“ дәүләт программасы эшли.

Бу программалар кабул ителү нәтиҗәсендә, туган телебезне саклау, өйрәнү һәм үстерү өчен, шактый күп әһәмиятле эшләр эшләнгән: татар телен Татарстанда яшәүче барлык милләт балаларына да укыту кертелгән, татар телендәге матбугат материаллары, радио-телевидение тапшырулары күпкә арттырылган. Төрле массакүләм мәгълүмат чараларыннан файдалану арта бара. 2011нче елдан “Вконтакте” (vkontakte.ru) социаль челтәре тулаем тәрҗемә белән рәсми рәвештә кулланыла башлый. Дөнья буенча сибелеп

яшәгән 7 миллион татарны берләштерү максатын күздә тоткан мәгълүмати ресурслы "Татар иле" порталын – киң мөмкинлекләр мәйданы, дияргә була. Хәзерге вакытта әлеге ресурста кулланучылар өчен шактый киң мөмкинлекләр ачылган. Биредә интернет челтәренең татар сегментына караган сайтлары тупланган, татар китапханәләрендә урнашкан китапларны онлайн–режимда уку мөмкинлеге ачылган, энциклопедик мәгълүмат урын алган. Шулай ук порталда татар халкының фикерен ачыклау, татар дөньясының халәтен билгеләү өчен сораштыру бүлеге дә эшли.

Татар шәхесләре уңышлары, татар дөньясында булган төрле вакыйгалар порталның “Истәлекле даталар” бүлегендә яктыртыла. “Татар иле”ндә бар дөньяга сибелеп яшәгән татар халкының тормышы чагыла. Порталда татар халык җырлары һәм көйләренең сыйфатлы онлайн базасы булдырылган. “Аудио” бүлегендә җырлар белән бергә аларның текстлары да урнаштырыла һәм һәр кулланучы караоке режимында теләсә кайсы җырны үзе дә кушылып башкара ала. Музыкаль әсәрләрне авторлары, җыр исемнәре һәм җыр текстындагы сүзләр буенча эзләп табу мөмкинлеге каралган. “Видео” һәм “Фотогалерея” бүлекләре дә киң мөмкинлекләр ача. “Видео” бүлегендә фильмнар (документаль, фәнни–популяр, нәфис фильмнар), мультфильмнар, концертлар һәм спектакльләр, телевизион тапшырулар һәм әңгәмәләр урын алган.

“Татар иле” кысаларында татар теленә дә өйрәнергә була. Төп бүлекләрнең берсе – ”Аралашу” бүлеге. Анда социаль челтәрләргә хас гамәлләр башкарырга, үз профилеңне булдырырга, дуслар табып аралашырга, төркемнәр булдырырга, аларга язылырга һәм башка төр мәгълүмат алырга була.

Порталның төп максаты – башка халыклар арасында Татарстанны таныту, аның мәдәниятен, рухи байлыгын популярлаштыру, республикабызга, татар дөньясына карата кызыксыну, хөрмәт уяту [tatar–duslyk.ru].

Белем.рупорталы – татартелендәге интернет–белем үзәге–иң уңайлы белем алу чыганакларыннан санала. Кирәкле мәгълүматларны табудан тыш,

милли китапханәдән электрон китаплар, электрон вариантта газета–журналларга язылу, татар телендә мультфильмнар карау, җыр тыңлау, яңалыклар белән танышу, татар милләтенең күренекле шәхесләре иҗаты белән танышу кебек чаралардан файдаланырга була [belem_ru].

Татар зыялыларының (Рөстәм Миңнеханов, Минтимер Шәймиев, Энгель Фәттахов, Разил Вәлиев, Рузәл Юсупов,Фәрит Мифтахов, Искәндәр Гыйләҗев) эш–гамәлләрен, уй–фикерләрен өйрәнеп, шундый нәтиҗәгә килдем. Татар телен саклау һәм үстерү өчен:

– төптән уйланылган, гаять киңкырлы дәүләт программасы таләп ителә;
– татар теленең кулланылышын дәүләт тарафыннан тәэмин итү;
– милли җәмгыятьләр, татар берләшмәләре, илкүләм оешмалар оештыру;
– татар телен өйрәтү, укыту системасын камилләштерү, яхшырту;
– шәһәрдә чын татар мохитен булдыру: барлык белдерүләр һәм язмалар;

–Татарстанда җитештерелгән барлык әйберләрнең язулары ике телдә булу;

– чит илләргә чыгарлык дәрәҗәдә сыйфатлы татар телевидениесенбулдыру;

– миллиүзаңныүстерүмаксатында,зур реклама компаниясе булдыру;

– балалар бакчасында һәм башлангыч мәктәптә телләрне өйрәтүгә ныграк басым ясау нәтиҗәлелекне арттырыр иде.

Тагын өстәп шуны әйтәсе килә: татар милләтеннән булган теләсә кем “Мин бит татар баласы” дигән фикер белән яшәсә, телне саклауга үзеннән өлеш кертсә, башкарылган эшләрнең нәтиҗәсе дә тиешле югарылыкта булыр.

**Әдәбият**

1. http://belem_ru
2.http://kitap.net.ru/sattar.php?lang=tat
3.http://www.yeshlek.ru/node/1803
4.http://www.tatmedia.ru/tat/obzor_press/telne_sakl/
5.http://tatar–duslyk.ru

## Ф. ЯРУЛЛИН ПОЭМАЛАРЫНДА ӘХЛАКЫЙ КЫЙММӘТЛӘР

Захарова А. Д.,
КФУ ның Алабуга институты студенты.
Фәнни җитәкче: Габидуллина Ф.И.

Гомумкешелек, ягъни мәңгелек кыйммәтләр рәтендә кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләр белән бәйле булган гаделлек, шәфкатьлелек, мәрхәмәтлелек кебекләрне дә атыйлар. Мондый мәңгелек кыйммәтләр әдәбиятыбызда электән үзәктә торалар, чөнки аларны югалту гомумән кешелек өчен һәлакәт булыр иде. Галимнәр Фәнис Яруллин (1938-2011) иҗатында бигрәк тә шәфкать, мәрхәмәт кебекләрне атыйлар һәм моны әдип биографиясе белән бәйләп карыйлар. Ф. Яруллинның әтисе кырык яшендә сугышта һәлак була. Ә. Хуҗиәхмәтов әдипнең әтисез балачагының иҗатка тәэсирен түбәндәгечә аңлата: “алты нарасый бер ана кулында калып, бер сынык икмәккә, ата назына тилмереп үскәнгәме, әллә дөньяга килгәндә үк сизгер җанлы, нечкә күңелле булып тугангамы, гаделсезлек, әхлаксызлык кебек яман сыйфатлар аның каләме игътибарыннан читтә кала алмый” [Яруллин, 2002: 12]. Шагыйрь әсәрләрендә кат-кат ассызыклана: еш кына кеше тормышын сүндерүче көч ул – шәфкатьсез җәмгыять, җылы җитмәү; шәфкатьлелек исә иң авыр шартларда да яшәү көчен бирүче изге нур. Шәфкатьсезлекнең кеше гомерен өзергә сәләтле булуы “Ак үлем” поэмасында да ассызыклана. Наркоманга әверелгән лирик герой нәкъ менә ярдәмчесез, җылы сүзе булмаган, ятим-мохтаҗларга барлык ишекләрне ябык тоткан дөньяда бер тамчы ләззәт тояр өчен шушы агулы матдәгә ияләшүен аңлата:

Шәфкатьсезлек йөзе йөзләремә
Килеп бәрелгәндә җанны өтеп –

Мине бары шул коткарып килде,
Кайнар дулкыннарны читкә этеп [Яруллин, 2019: 28].

Бу яктан С. Хәкимова фикере белән без тулысынча килешәбез: “Ак үлем” поэмасында Фәнис Яруллин, беренчеләрдән булып, әдәбиятта, аерым алганда поэзиядә, наркомания темасын күтәрә. Поэма язылган вакытта (1990) әле бу афәт безнең илдә хәзерге кебек үк тамыр җәймәгән иде. Аның кешене нинди хәлгә төшерүен автор кыз бала язмышы аша тасвирлый. Әтисез, торыр урынсыз, мәхәббәттә алданган кыз юанычны наркотиклардан таба һәм упкынга тәгәрәвен үзе дә сизми кала. Алдагы поэмаларда күтәрелгән проблема бу поэмада да дәвам итә: гаделсезлек, җәмгыять тарафыннан яклау булмау, мәрхәмәтсезлек “Ак үлем”дә наркоманиягә илтүче юлларның берсе буларак күрсәтелә [Хәкимова, 2018: 115].

Шәфкатьлелек, мәрхәмәт турында сөйләгәндә, “Нәсел агачы” поэмасы, андагы Зәйнәб әби белән Сәләх бабай образларына аерым тукталу сорала. Болар – балаларга туган булмаса да, күңелләренә шәфкатьлелек орлыклары сала белгән шәхесләр. Әдип сугыш елларындагы аяусыз елларны тасвирлый. Кышкы суык. Әни кеше эштә (ул елларда тылда калучыларны да “Барсы да фронт өчен” дигән шигарь белән ялсыз диярлек эшләтүләре гомумбилгеле факт), дежур вакытта төнгә генә кайтып җитә. Салкын өйдә ярымач балалар физик уңайсызлыкларны гына түгел, психологик газаплар да кичерәләр: караңгы йорттагы һәр шәүлә аларга йортка кергән угры, куркыныч зат булып тоела. Әмма, иң авыр вакытта Зәйнәб әби белән Сәләх бабай ярдәмгә киләләр:
Зәйнәб әби, Сәләх бабай
Торды гүя сакта гына.
Килеп керә иде алар
Иң-иң кирәк чакта гына [Яруллин, 2019: 11].
Балалар салкын өйдә куркып, һәр тавыштан шүрләп калтыраганда, Зәйнәб әби алар янына керә, чәй куеп җибәрә, бал белән сыйлый. Сәләх бабай исә – авылда оста мичче. Зәйнәб әби чәй белән җылытса, Сәләх бабай мич куеп җылыта. Салган мичләре өчен мондый мохтаҗлардан ул акча да алмый:
Җылылыклар сатылмый дип
Алмый иде акчасын да.
Шаярта иде: “Берәр җимеш
Тияр оҗмах бакчасында” [Яруллин, 2019: 11].
Шул рәвешле биредә мәрхәмәт, шәфкать җылы чәй, мич образлары белән тулылана, физик күренеш буларак җылылык күңел җылысы символы белән баетыла.
Шушы ук аспектта “Коткарыгыз” поэмасына да тукталу кирәктер. Биредә дә “Ак үлем” һәм “Нәсел агачы” поэмаларындагы кебек үк аерым шәхес язмышы һәм хакимияттәге гаделсезлек проблемасы яктыртылган. Ләкин, гаделсезлекнең иң ачы җимешен татып, иң югары кыйммәтләрнең берсе – ireклектән мәхрүм ителгән ана төрмәдән баласына хат язганда, гадел булу, харам малга кызыкмау белән бергә шәфкатьле булырга да чакыра:

Өченчесе, иң мөһиме:
Шәфкатьсез була күрмә:
Шәфкатьсез кеше – Тиран ул,
Шәфкать юк илләр – Төрмә [Яруллин, 2019: 46].

Биредә илне Төрмә белән чагыштыруга бу Ананың тулы хокукы бар. Аның ире сугыш кырында батырларча һәлак була. Өйгә гәүдәсе кайтмаса да, ордены кайта. Шушы батыр ир хәтере хөрмәтенә Ана, балалар, әлбәттә, дучар мөгамәләдән азат ителергә тиеш иделәр, кечкенә булса да ярдәмгә лаеклар алар. Кешелекнең югары кыйммәтләреннән саналган гаделлек, ихтирам шуны таләп итә. Әмма аяусыз чынбарлык, намуссызлык моңа юл куймый. Поэмадагы иң үзәк өзгеч эпизодларның берсе – соңгы сыерны алып китәргә килгән хәкимият әһелләре алдында ананың түбәнсетеп ялваруы, тезләнеп сыерсыз калдырмаска үтенүе:

Әни озак өзгәләнде
Түбәнсетеп горурлыгын,
Юкса күреп торды инде
Боларда һич шәфкать югын [Яруллин, 2019: 40].

Ана белән балалар өйдә ачлыкка дучар ителсәләр, йорттан йортка кереп, налог җыючыларның тамагы һәрчак тук. Әдипнең мондыйларга нәфрәте зур:

Заманы шул: куркак җаннар
Намус сатып батырлана.
Һәм яманлык ил буенча
Миллион тапкыр тапкырлана [Яруллин, 2019: 40].

Бу йортта да сыер алып китү күренеше соң чиккә җиткерелгән фаҗига төсмерен ала: ярсыган, гаҗизлектән нишләргә белмәгән ана файдасыз орденны идәнгә атып, аяклары белән таптый. Әлбәттә, шушы гамәле өчен ул төрмәгә үк алып кителә, йортта тагын ятим балалар кала.

Аталган поэмалар арасында “Юылмас хурлык” әкият-поэмасы үзенчәлекле урын алып тора. Аның жанрын әкият-поэма дип тә әйтеп була. Поэма геройлары – кешеләр түгел, ат, колын, бүреләр булса да, мәңгелек кыйммәтләр бирелеше ягыннан ул кешелек җәмгыяте, кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләргә дә кагыла. Әнкәй-атның кисәтүе дә кешеләр дөньясында ананың бала мөрәҗәгате буларак кабул ителә ала:

Берүк алай ерак итмә,
Югалта күрмә юлың.
Урманнар алар – сихерле,
Алдагыч була болын [Яруллин, 2019: 59].

Ана белән бала мөнәсәбәтләре традицион якын, мөлаем. Ана улына – тайга карата бетмәс мәхәббәт белән яна. Колын, балаларга, үсмерләргә хас булганча беркадәр масаебрак карый, дөньяның явызлыгына каршы торырлык дәрәҗәдә көч булуын сизгәндәй була. Әмма поэмага фаҗигале аһәңнәр килеп керә: колын, ярамаган урынга чаба, ә энисенә бу вакытта бүреләр һөҗүм итә. Әмма трагизм моның белән аңлатылмый, мөһиме шул: колын, мөмкинлеге булса да,

әнисен коткарырга килергә курка, бүреләрдән поса. Ул килгәндә, әнисеннән инде сөякләр генә калган була. Ф. Яруллин телгә килгән баш мотивын куллана (кисекбаш). Үлгән аттан калган баш улының гафу үтенүенә, куркаклыктан котылу чарасын табу серләренә төшендерә. Бу очракта кешенең батыр түгел, ә шәфкатьле, михербанлы булуы әһәмиятлерәк икән:

“Батырлык башлана, улым,
Иң беренче йөрәктән.
Һәм мәрхәмәтле булудан,
Башкаларны сөюдән.
Йөрәктәге гамьсзелекне,
Мин-минлекне җиңүдән [Яруллин, 2019: 61].

Әкият-поэманың иң соңгы юлларында автор шуңа басым ясый, куркаклык арасында хурлыкка каласың икән, сине инде алдагы тормышыңдагы батырлыкларың, данлыклы эшләрен дә гафу итә алмый, чөнки конкрет бу очракта дөньядагы иң газиз, синең өчен теләсә-нинди авырлыклар кичерергә әзер торган әни вафат була. Бу очракта автор фикерен “яра” сүзе аеруча төгәл белдерә. Поэманың соңгы дүрт юлында әлеге нигез сүз өч тапкыр кабатлана:

Тән ярасы төзәлсә дә,
Төзәлми җан ярасы.
Шул яраны ялый-ялый
Гомер буе барасы [Яруллин, 2019: 60].

Шул рәвешле, мәрхәмәтле булуның әһәмияте тагын да ныграк аңлашыла.

Шагыйрь иҗатында, поэмаларында гуманистик кыйммәтләр, мәрхәмәт турында сөйләгәндә, тагын бер аспектка игътибар итү сорала. Бу – шагыйрьнең үзенең автор буларак гуманизмы. Әйтик, “Нәсел агачы” шигыре сиволик мәгънәгә ия булган аваз – бала елау авазы яңгыравы белән тәмамлана.

Ишетелә авыл ягыннанмы,
Йолдызлардан әллә килгәнме,
Әллә инде Зәйнәб әби оныгы –
Феникстай туган көлдәнме?
Ишетәм аны, ишетәм. Бу тавышны
Торган саен ныграк ишетәм.
“Кешелекнең киләчәге мин!” – дип
Дәшә бугай бала бишектән [Яруллин, 2019: 27].

Бала тавышының символик мәгънәсе шуннан гыйбарәт: димәк, халык, милләт бетмәгән, Зәйнәб әбиләрнең дәвамчысы булган сабый бала бишектә ята, аваз бирә, димәк, нәсел дәвам итәчәк, хәтер яңарачак.

Нәтиҗә ясап, шуны әйтергә кирәк: мәрхәмәт, шәфкать Фәнис Яруллин иҗатында кешелекне коткаручы көч буларак бирелә. Киресенчә, бу кыйммәтләр юкка чыкканда, җитмәгәндә, аерым шәхесне, гомумән, кешелекне афәт көтә, дигән фикер ассызыклана. Шунысы да аянычлы, гади кешеләр уңай кыйммәтләрне йөртүчеләр булса, хакимият аларны таптаучы буларак бирелә.

Кеше тормышы, яшәү, хәтер кебек кыйммәтләр үзәккә куелган поэмаларның аһәңе, лирик герой бирелешләре лирик поэма үзенчәлекләренә (автобиографик мотивлар, тәүбә итү яки үткән гомерне искә төшерү, тирән кичерешләр бирелеше) туры килсә дә, аларга иҗтимагый яңгыраш та ят түгел. Әйтик, тип проблема – нәсел агачларының югалуы, коруының сәбәбен әдип бары аерым шәхесләрнең гамьсез-битараф булуы белән аңлатмый, ә барыннан да элек иҗтимагый-сәяси шартлар йогынтысын да ассызыклый; наркомания чире дә иҗтимагый шартлар белән аңлатыла.

**Әдәбият**


1. Яруллин Ф. Ачы язмыш сәхифәләре // Казан утлары. – 1993. – №5. – Б. 154 – 156.
2. Яруллин Ф. Г. Сайланма әсәрләр / Ә.Хуҗиәхмәтов кереш сүзе. – Казан: Хәтер, 2002. – 480 б.
3. Яруллин Ф. Йөрәкләрдә кабат терелә: поэмалар, шигырьләр / төз. Н.Яруллина. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2019. – 399 б.
4. Хәкимова С. Әдип иҗатына бер караш // Казан утлары. – 2018. – №2. – Б. 113 – 120.


## ТАТАР ТЕЛЕН ӨЙРӘНҮНЕҢ АКТУАЛЬ МӘСЬӘЛӘЛӘРЕ


Зиганшина А.Р.,
Алабуга шәһәренең 6 нчы урта мәктәбе укучысы.
Фәнни җитәкче: Гайсина Р.С.


Татар теле бик күп кенә галимнәр тарафыннан өйрәнелсә дә, әле чишелмәгән мәсьәләләр шактый күп.

Язу– телнең график формасы, ул аралашу өчен гаять әһәмиятле корал булып санала. Язу күпләр белән, бик ерактагылар белән аралашырга мөмкинлек бирә. Шуңа күрә билгеле бер тәртипкә салынган,әдәби телдә кабул ителгән язу кирәк.

Орфография язу теленең әнә шул тәртипкә салынган кагыйдәләрен, дөрес язу юлларын үз эченә ала.

Язу, эчтәлек ягыннан төзек һәм кызыклы булып, орфографик яктан грамотасыз булса, ул уңай бәяләнә алмый. Кеше дөрес язмаса, бердән, аны уку авырлаша,икенчедән,язучы бирергә теләгән фикер дөрес аңлашылмый, ул сүзнең мәгънәсе бозыла һәм, өченчедән, ялгыш язу кешенең грамотасызлыгын күрсәтә, аның дәрәҗәсен төшерә.

Әдәби тел грамматик закончалыклар, орфоэпик һәм орфографик кагыйдәләр белән нормалаша. Әмма теләсә кайсы әдәби телдәге күренеш һәм фактларның барлык үзенчәлекләре дә аерым кагыйдә,хәтта искәрмәләрдә чагылып бетмәскә мөмкин. Бу хәлне исәпкә алмау китап,газета һәм журнал битләрендә төрлечә язуга сәбәп була.

Һәрбер телнең үзенә хас әйтелеш нормалары була. Дөрес әйтелеш кагыйдәләренең, нормаларының җыелмасы *орфоэпия* дит атала (orthos –туры һәм epos – сөйләм). Орфоэпиянең нигезен һәрвакыт теге яки бу телнең фонетик системасы тәшкил итә, ә соңгысына фонемалар составы, фонемаларның көчле һәм көчсез позициядәге үзенчәлекләре керә. Орфоэпия шушы үзенчәлекләрне теге яки бу әдәби теленең әйтелеш нормасы итеп күтәрә.Бу нормалар үзгәрергә дә мөмкин.

Орфоэпик кагыйдәләрнең сакланмавы төрле сәбәпләр белән аңлатыла:

1) әйтелеш белән язылыш арасында зур аерма булу (канәгать [кәнәгәт]);

2) әдәби телгә диалекталь тәэсир булып, дөрес сөйләм нормалар

бозылырга мөмкин.Мәсьәлән, көнбатыш диалектта кече тел тартыкларының әйтелмәве, [ч] авазы урынына [ц] яки [ч] әйтү, Минзәлә сөйләшендә [з] авазы урынына интердентал, ”сакау”[d] әйтелү һ.б. диалекталь тәэсир булып торалар.

3) аерым очракларда теге яки бу авазны дөрес үзләштерергә икенче

телнең тәэсире мөмкинлек бирми. Мәсьәлән, татар телендәге [h] авазын[х] дип әйтү, [w] урынына [в] әйтү рус теле тәэсире белән аңлатыла.

Татар телендә орфографик нормалар, нигезендә, ике сәбәп аркасында бозыла:

1) сөйләүченең нindидә булса җирле диалект үзенчәлекләреннән аерыла алмавы ,сөйләгәнчә язуы;

2) татар телендә әйтелеш белән язылыш арасында зур гына аерма булу;

Беренче сәбәптән котылу юлы – диалекталь сүзләрнең әдәби телдә әйтелеш һәм дөрес язу кагыйдәләрен үзләштерү.

Икенче сәбәп тирәнрәк. 30 нчы еллар ахырында СССР дагы бик күп халыкларны, шул исәптән татарларны да көчләп рус алфавитына, кириллицага күчерәләр. 1939 нчы елда М.Корбангалиев һәм Ш.Рамазанов тарафыннан ашык – пошык кына төзелгән алфавит проекты (рус әлифбасына 6 хәреф өстәлгән хәзерге әлифба хөкүмәт указы белән рәсми рәвештә раслана.)

1999 нчы елда “Латин графикасы нигезендә татар алфавитын торгызу турында” Татарстан Республикасы Законы кабул ителде, һәм бу Законны гамәлгә кую буенча эш башланды.

Татар телендәге бик күп авазлар “хәрефсез” калалар . Аларны белдерү өчен, рус телендәге шуларга охшашлырак авазларның хәрефләрен куллана башлыйлар. Бу авазларны аеру өчен өстәмә кагыйдәләр уйлап чыгарыла.Шулай итеп, бер төрле язылa, икенче төрле укыла торган бик күп сүзләр килеп чыга.

Орфография–дөрес язу кагыйдәләре.Ул сүзләрнең һәмкушымчаларның дөрес язылышын;сүзләрнең кушылып,аерым һәм сызыкча аша язылуларын;баш хәрефләрнең кулланылышын һәм сүзләрне юлдан–юлга күчерү кагыйдәләрен билгели.

Татар теленең орфографиясе төрле принципларга нигезләнә:

1) ф*онетик принцип*(ишетелгәнчә язу).Мәсьәлән ,татар телендә бер үк кушымчаның 2–4–6 варивнты булу – шушы принципның чагылышы.Хәзерге татар язуы башлыча шушы принципка корылган,хәтта кайбер аваз үзгәрешләре дә язуда чагылыш таба(китап –китабы ,халык –халкы һ.б.)

2) м*орфологик принцип*(морфемаларны, ничек ишетелүләренә карамастан,һәрвакыт бер генә төрле язу).Мәсьәлән, о,ө хәрефләренең беренче иҗектә генә язылуы,кайбер аваз үзгәрешләренең язуда күрсәтелмәве:*унбиш [умбиш],әнкәй [әңкәй]һ.б.*

3) т*арихи–тарадицион принцип (*шул телнең элеккеге язу үзенчәлекләрен, традицияләрен саклап язу).Татар язуы чагыштырмача яңа булганга, бу принцип зур чагылыш тапмый: цифрлардан соң килә торган кушымчаларны сызыкча аша язмау (8 әр кеше, 100% тан артык һ.б.),кайбер сүзләрнең язылышы әйтелеш нормаларына туры килмәсә дә, элеккеге язылышны саклау (сәламәт, бәла,һәлак,кәгазь һ.б.)

4) г*рафик принцип* (рус теленнән һәм рус теле аша кергән алынма сүзләрне рус телендәгечә язу).Мәсьәлән,самолет,бухгалтер,компьютер; Рус теленнән элегрәк кергән сүзләр фонетик принципта языла (әфлисун,эскәтер,сумала һ.б.)

Хәзерге татар орфографиясендә дифференцияләнгән (яки дифференциаль) язылыш та кулланыла.Бу әйтелеш бертөрле кайбер омонимнарны аеру өчен (*баерак – байрак ), Аерым һәм кушылып язу очраклары да күзәтелә ( өч почмак – өчпочмак,һ.б.).Язылышлары төрле булгач ике төрле мәгънә бирәләр.*

Орфографик нормалар дөрес укылышны, дөрес язылышны тәэмин итәләр.Сөйләм культурасын үстерүдә дә аларның әһәмияте зур.

Татар телендә в хәрефе ике авазга билге булып йөри. Татар телендә иҗек башында в ирен–ирен тартыгы [w] авазын белдерә*вакыт*. Рус телендә в ирен–теш тартыгы [в] *Вася*. Алынма сүзләрдә һәм фамилияләрдә ирен –теш [в] авазын белдергән в хәрефе, сүз һәм иҗек ахырында [ ф] булып ишетелсә дә, в хәрефе языла: *актив, совхоз.*Ә татар теленең үз сүзләрендә һәмгарәп – фарсы алынмаларында ирен –ирен[w]авазын белдерә, язуда в хәрефе белән күрсәтелә: *тавык, әүвәл,давыл* .Бу очракта в хәрефе бары тик сүз башында гына языла.

Татар телендә к,г тартыклары ике авазга бүленә.Бу бүленеш язылышта ялгышлар тудыра.

Татар теленең л, м, н, р, с, т, ф хәрефләре үзләре ишетелгән урыннарда гына язылалар.

Икеләтелгән тартыклар кергән сүзләрне юлдан юлга күчерү дә үзенчәлекле. Кайбер сүләрдә янәшә тартыкның берсе икенче юлга күчә, кайберсендә күчми: *мәххәбәт, мөгаллим,тәвәккәл һ.б.*

Сузыклар кыскару язуда чагылыш тапмый диярлек. Ләкин кыскару күренеше орфографиядә чагылыш тапкан очраклар да бар. Мәсьәлән: сеңел – сеңлем, бәгырь – бәгърем;

Гарәп теленнән алынган сүзләрдә а яки ә хәрефләрен язу авыр мәсьәлә. Гарәп телендәге озын а татар теленәкириллицада – а хәрефе, кыска а исә татар теленә ә хәрефе булып кергән.Шулай итеп, әйтелеш белән язылыш туры килми. Бу бигърәк транскрипцияләгәндә ачык күренә: хатирә – [хәтирә], мөбарәк – [мөбәрәк] ;

Гарәп – фарсы алынмалары, әйтелеш нормасы туры килмәсә дә,гарәп хәрефләре белән язылышны күздә тотып, график – традицион принципта язылалар.

Телебезнең башка бүлекләрендәдә күп кенә бәхәсле мәсьәләләр бар.

Без әле бүген орфоэпия һәм орфографиядә булганнарына гына тукталдык.

Татар телендә булган актуаль мәсьәләләр галимнәр тарафыннан өйрәнелгән һәм өйрәнелә. Әмма язу – халкыбызның аралашу өчен гаять әһәмиятле коралы. Аларны өйрәнәсе дә өйрәнәсе. Киләчәктә безнең язуыбызны тагын да ныклабрак тикшерүче галимнәребез, бәлки, үз арабыздан ук чыгар дип ышанам.

**Әдәбият**

1.Латыйпова Г. Х. Татар теле һәм әдәбияты: үткәне һәм бүгенгесе һәм киләчәге. – Алабуга: К(И)ФУ АФ нәшр., 2012. – 160 б.

2.Сәлимов Х. Х., Хәзерге татар әдәби теле: Татар теле укытучылары һәм студент – филологлар өчен кулланма. – Алабуга., 2002. – 12–14 б.

3.Татар теленең орфографик сүзлеге. –Татар. кит. нәшр., 1983. – 141б.

## ТЕМА ВОЙНЫ В ТАТАРСКОЙ ПРОЗЕ НАЧАЛА XX ВЕКА

Ибрагимова М.И.,
студентка Елабужского института КФУ.
Научный руководитель: Даутов Г.Ф.

В прозе начала XX века тема войны звучала актуально. Война в прозе передается через реалистическое описание. В рассмотренных произведениях делается упор на то, что война – это не чувство патриотизма, а бессмысленная, ужасная сила. Но в отдельных случаях именно в бою герои осознают, кто настоящий враг в стране.

Ученый, критик Ф. Баширов делает обзор влияния Первой мировой войны на политическую, общественную ситуацию. Тему войны изучает произведения, поставленные в центр. Написанный неизвестным автором «Рассказ солдата, заблудившийся», он обвиняет в построении фальшивого патриотизма, цитирует газеты и журналы «Вакыт», «Дин вә әдәп», подчеркивая, что подобные мотивы занимают место и в периодической печати. Другие произведения, по мнению ученого, «утвердили мотивы грозы, усиливающие год войны, как единственный путь перед человечеством, выдвинули идею, что бессмысленно тягаться с злой действительностью» [«Башир, 2002:218]. Прежде всего выяснилось, что в рассказах значительное

место занимает реалистический опись, в отдельных случаях даже натуралистическое описание. В качестве примера остановимся прежде всего на произведении М. Гафури «Солдат хатыны Хамида».

В рассказе Мажита Гафури «Солдат хатыны Хамида» главная героиня повествует о том, как в мирную жизнь семьи вступила война. Разделив рассказ писателя на несколько отделов, он именует их в связи с событиями:“Ябыштырганнар”, “Гариф алынган”, “Гарифны озаттылар”, “Гариф – солдат”, “Хәмидәнең калага баруы”, “Озату”, “Хат килми башлады”. Мажит Гафури описывает насколько опасна для этой семьи война, как Гариф участвует в войне. В конце произведения он уже два месяца не получал писем, а только в письме Ахмадуллы, посещавшего вместе с Гарифом войну, сказал: “Мы вступили в бой вместе с Гарифом. В то время, как мы жили в одном лесу, на нас “посыпали”.Когда нас стали окружать соплеменники, мы спрятались вместе. В это время Гариф абзый куда–то исчез. В наш полк не вернулся», – говорится [Гафури, 2007: 270]. По нашему мнению, автору важно показать, что война сильно повлияла на деревню. Хамида, например, осталась с тремя детьми, с неубранными полями. У них еще есть надежда выжить: во–первых, муж рекомендует продать черную корову для уборки хлеба; во–вторых, рядом свекр и родственники, они могут быть опорой.А вот односельчане Зинната ушли на войну, у него осталась жена, четверо детей, да еще и без зерна, и дажеродных нет. Напомнив, что таких людей много, писатель Гариф, встречаясь с ним, говорит: “И брат ушел на войну. У нее двое детей остались в руках. Два моих сына на войне. У меня дома еще четверо детей. На ней сегодня есть пожилая сестра, которая может умеретьв любой момент, на одинокую жену остается еще семь душ» [Гафури, 2007:246]. Таким образом, в этом произведении описывается влияние годы Гражданской войны на народ, его трудности.В реалистическом плане описываются события войны в повести Мажита Гафури «Уроки жизни»: «За два с лишним года трудно было испугаться черных облаков, которые беспрестанно громом, громом и градом падали... Народ, решив, что это угнетение возможно только собственными руками, поверил в то, что все цари, его генералы и губернаторы – враги им, и вступили в путь их воодушевления. С этой мыслью вскоре начали ждать, когда что–нибудь произойдет» [Гафури, 2007:293].М. Гафури добивается описания солдат не только как борцов на поле боя, но и как людей с разной степенью развития горизонта видения и политической позицией. Среди них есть и сторонники старого, и равнодушные, и новые мыслители, то есть те, которые понимают, что царская власть – это угнетение. «Некоторые солдаты, как и прежде, высказались за старое. Некоторые думали, что для нас будет что угодно. Некоторые, находясь во всем новом мнении, косясь на жизнь, которая дошла до сих пор, начали ходить с мыслью о вражде к делам власти, о дружбе к тем новым людям, которые противостояли им», – пишет он [Гафури, 2007:261]. Такие описания позволяют более полно представить ситуацию войны того времени, стать свидетелем развития сознания героев, солдат.

Конечно, татарская проза начала XX века не ограничивалась жанром рассказа, повестями, а обращались отдельные писатели, например, к жанру романа Галимзяна Ибрагимова. Тот факт, что первый вариант его произведения «Наши дни» был написан в 1914 году. Срок записи произведения определяется как 1914–1920 годы. Событиями, заложенными в развитии литературы того периода, стали, как известно, такие исторические события, как Февральская и Октябрьская революции, гражданская война, установление тоталитарной системы. Как исторический фон этот период, как и свойственно произведениям, получившим эти революции, Галимзян Ибрагимов в предреволюционные годы изображает простые люди – крестьяне, трудные условия жизни рабочих.Обращаясь к кровавым революционным годам как исторический фон романа «Наши дни», писатель нацелен на то, чтобы описать воздействие на народ тех событий, которые текли этим потоком, повернули историю страны в совершенно иное русло.Д.Ф. Заһидуллина заявляет, что в татарском обществе, демонстрируя вызванные революцией 1905 года действия, их влияние на судьбы людей из разных слоев населения, изменение истории требует от человека больших жертв, чтобы он полностью посвятил себя этой борьбе [Загидуллина, 2017:13].

Подводя итог, следует отметить, что описание войны в татарской прозе дается в основном элементами реалистического, даже натуралистического описания. Авторы часто настаивают на том, что события происходят. Произведения о войне можно разделить на несколько: события на поле боя, ужас войны; тяжелая жизнь тыловиков; рост самосознания солдат в войне, осознание угнетения.

**Литература**

1. Бәшир Ф. XX йөз башы татар прозасы: монография. – Казан: Фикер, 2002. – 287 б.

2. Гафури М. Сайланма әсәрләр. – Казан: “Хәтер” нәшр., 2007. – 479б.

3. Заһидуллина Д.Ф. Галимҗан Ибраһимов идеаллары: “Мин хәят эзләдем, хәятта мәгънә эзләдем...” // Наследие Галимджана Ибрагимова в контексте многообразия культур: материалы международной конференции, посвященной 130–летию со дня рождения Г. Ибрагимова. – Казань: ИЯЛИ, 2017. – Б. 9 – 16.

## Г.КАМАЛНЫҢ “БҮЛӘК ӨЧЕН” ӘСӘРЕН МӘКТӘПТӘ ӨЙРӘНҮ

Исмәгыйлова Г.Р.,
КФУның Алабуга институты студенты.
Фәнни җитәкче: Камаева Р.Б.

Татар теле һәм әдәбияты дәресләрендә заманча укыту технологияләрен куллану фәнгә кызыксыну уяту, танып-белү активлыгын үстерү, аралашу процессында үзара аңлашу һәм ярдәмләшү мохите тудыру, укучыларның иҗади сәләтләрен ачыклауга һәм формалаштыруга ярдәм итә.

Үстерешле укыту технологиясенә XIX йөзнең беренче яртысында чит ил педагоглары И.Г.Пестолоцци, А.Дистервег, рус галим-педагоглары К.Д.Ушинский, Л.С.Выготский тарафыннан нигез салына. Аның асылын укучыларның танып белү мөмкинлеген активлаштыру һәм үстерү тәшкил итә. Алга таба бү юнәлештә Л.В.Занков, Д.Б.Эльконин, В.В.Давыдов һ.б. педагоглар эшлиләр. Л.В.Занков технологиясе шәхесне төрле яклап үстерүне күздә тота, Д.Б.Эльконин – В.В.Давыдов технологиясе акыл эшчәнлеге үсешен алга куя. [Камаева, Мөхәммәтҗанова 2015: 17]

Ә.З. Рәхимовның үстерешле укыту технологиясе укытучының эшчәнлеген тулысынча ФГОС таләпләренә туры китереп билгели. Укытучы уку формаларын, ысулларын һәм алымнарын сайларга ирек бирүче дәреснең план-конспектын куллана. Дәрескә әзерләнгәндә укытучы дәреслек, өстәмә әдәбият, интернет - ресурслар кулланырга мөмкин. Дәреснең яртысыннан артыгы укучыларның мөстәкыйль эшчәнлеге тәшкил итә. Укытучының төп максаты булып балаларның мәгълүмат эзләү һәм эшкәртү эшчәнлеген оештыру тора [Маркова 2012].

Галиасгар Камалның “Бүләк өчен” комедиясе мәктәп программасы буенча 10 сыйныфта өйрәнелә. Бу әсәрне өйрәнү дәресенең кайбер этапларына күзәтү ясыйк.

Үстерешле укытуга юнәлтелгән дәрес бер-берсенә бәйләнгән 3 этаптан тора: ориентлашу-мотивлаштыру этабы, уку мәсьәләсен чишүэтабы, рефлексия этабы. Уку мәсьәләсен чишү этабында әсәрне анализлау эше оештырыла. Беренче чиратта, укытучы укучыларны әсәр язылган чор белән таныштыра. Әсәр язылган чор белән таныштыру төп өч этаптан тора:

1.Бу чордагы илдәге вакыйгаларга күзәтү ясау *(XX гасыр башы үзенең тарихи вакыйгалары белән үзенчәлекле: 1904 елда Россия Япония белән сугыша. 1905 елда буржуаз революциясе була, 1907 елда - кара реакция еллары башлана.1914 елда бөтендөнья сугышы башлана. Ә тагын өч елдан – 1917 елда – Февраль революциясе кузгала.)*2. Әсәр язылган чорда әдәбияттагы яңалыклар *(1905 елгы революция илгә азмы-күпме ирек алып килә. Татар китаплары күпләп басыла башлый, газета-журналлар саны арткannan-арта бара. Цензураның йомшаруы кешеләргә үз фикерләрен яшермичә әйтергә һәм язарга мөмкинлек ача. Әдипләр бу елларда поэзия, проза, драма әсәрләре иҗат итәләр. Г.Камал бу шомлы кара революция елларында татар дөньясындагы негатив күренешләрне тәнкыйтьләү өчен комедия жанрына мөрәҗәгать итә.)*

Язучының иҗади югарылыгы. “Бүләк өчен” комедиясенең язылу тарихы. *(Әсәр 1909 елда языла, басылып чыга, шул ук елны “Сәйяр” труппасы сәхнәләштерә. Әсәр драматургның җитлеккән чорында языла. Бу чорда (1907-1912) Г.Камал үзенең иң көчле әсәрләрен иҗат итә: “Бәхетсез егет”, “Банкрот”, “Беренче театр”, “Бүләк өчен” һ.б.)*

Киләсе эш итеп әсәрнең темасы, идеясе, проблемасы ачыклана, сюҗет элементлары билгеләнә.

Г.Камалның «Бүләк өчен» комедиясенең *темасы* – кешенең акчага, байлыкка омтылуы, *идеясе* – бәхет акчага сатылмый, *проблемасы* – максатсыз акча, байлык җыю. *Экспозиция* – Хәмидә Габдуллаҗанга улларын Хисами бай кызына өйләндерү теләген сөйли. *Төенләнеш* – Габдулаҗан әнисенә каршы чыга, Хисами бай кызына өйләнмиячәген әйтә. *Вакыйгалар үстерелеше* – Хәмидә Мәхтүп яучыга улының өйләнүгә ризалыгын белдерә. *Кульминация* – Хәмидә кулмәкнең йон булачагын белгәч, бай кызын хурлап ташлый, туй булмаячак ди. *Чишелеш* – Хисамиларның асравы килеп, бай бикәсенең ялгышканын әйтә, Хәмидә бик нык үкенә, ләкин аңа берседә ышанмый.

Персонажлага характеристика бирүне төркемнәрдә оештырырга мөмкин. Укучылар әсәрдә булган төп *(Хәмидә, Әхмәтҗан, Габдуллаҗан һәм Мәхтүпҗамал)* һәм ярдәмчел *(Хисами бай, Әсмәбикә, асраулары Бәдриҗамал)* персонажларны билгелиләр. Һәр төркем әсәрдәге бер төп персонажга бәяләмә бирә, аның гамәлләре, характеры турында сөйли. Биремне алгач, укучылар төркемнәрдә фикер алышалар. Җавап бирү барышында бер төркем икенчесен тулыландырып бара. Эшнең нәтиҗәсендә төп характеристикалар буенча схема төзелә.

Үстерешле укыту технологиясендә һәр бирем билгеле бер адым булып тора. Һәрбер адым саен укытучы сорау куя, уйланырга вакыт бирә, җаваплар тыңлана, нәтиҗә ясала, башкарган эшкә бәя бирелә. Әгәр бала эшчәнлеге даими бәяләнеп бармаса, ул проблема үзенең мөстәкыйльлеген югалта. Дәреснең соңгы – рефлексия этабында укучылар дәрестә нәрсә эшләгәненә, ничек эшләгәненә нәтиҗә ясый.

Әдәбият дәресләрендә үстерешле укыту технологиясен куллану укучыларның шәхесләрен һәрьяклап үстерүгә ярдәм итә, аларның әхлакый, рухи һәм фикерләү сәләтен, фәнни-тикшеренү күнекмәләрен үстерергә булыша.

**Әдәбият**

1. Татар әдәбияты. 10 сыйныф: рус телендә гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен)/ Ф.Г.Галимуллин [һ.б.]; [Ф.Г.Галимуллин редакөиясендә]. – Казан : Татар. Кит. Нәшр., 2016. – 358 б.: рәс. б-н.

2. Камаева Р.Б., Мөхәммәтҗанова А.Х. Федераль дәүләт белем бирү стандартларын тормышка ашыруда татар теле һәм әдәбияты укытучысына фәнни-методик ярдәм: уку-укыту ярдәмлеге. – Казан: Татарстан Республикасы Мәгарифне үстерү институты, 2015. – 110 б.

3. Камаева Р. Б. Татар теле һәм әдәбияты дәресләрендә яңа педагогик. алымнар. – Алабуга: АДПУ нәшрияты, 2010. – 103 б.

4. Маркова Е.Н. Развивающее обучение в действии: технология творческого развития А.З.Рахимова в свете требований нового ФГОС URL: https://school.tver.ru/system/methodic_documents/files/000/001/359/original/1425305512.pdf?1425305512

5. Рахимов А.З., Педагогическая технология деятельностного подхода в обучении. – Уфа,1989.

## ГАЛИӘСГАР КАМАЛҺӘМ АНЫҢ ИҖАДИ МИРАСЫ

Казионова О.С.,
Алабуга шәһәренең 10 нчы күппрофильле лицей укучысы.
Фәнни җитәкче: Кантуганова Г.М.

Г. Камалның ата-баба ягыннан ерак шәҗәрәсе документаль рәвештә хәзергә төгәл билгеле түгел. Энесе Габдрахман Камал раславынча, аларның атасы ягыннан бабалары Жомагыл исемле булып, ул үз гомерен хәзерге Арча районының Сикертән авылында крәстиян хезмәтендә яшәп уздырган. Җомагылның 1850 елда Галиәкбәр исемле улы туа. 12 яше тулгач, Галиәкбәрне, үз көнен үзе күрергә дип, Казанга чыгарып җибәрәләр. Башта ул камчат, кама, төлке мехлары белән кәсеп кылучы байларда хезмәт итә. Аннан соң шул ук мехларбуенчаүземөстәкыйльэшбашлап, 1874 елда Арча төбәгенең Масраавылык рәстияне, волость старшинасы Хәбибулла дигән кешенең олы кызы Мәүгыйзәгә өйләнә. Татар әдәбияты һәм сәнгате дөньясында “Камаллар" дип дан казанган династиянең тәүге буыны нәкъ менә шушы ике яшь кеше кушылган бәрәкәтле гаиләдә туып үсә. Галиәкбәр белән Мәүгыйзәнең дүрт баласы – өч малай белән бер кызлары була.

Иң өлкәне — Галиәсгар Камал (1879–1933), татар әдәбиятының классигы, атаклы драматург, татар профессиональ театрына нигезс
салучы һәм аны үстерүчеләрнең берсе. Казандагы татар дәүләт академия театры 1939 елдан аның исемен йөртә.

Габдулла Камал I (1893–1933) – Г. Камалның бертуган энесе, күренекле артист, режиссер һәм театр эшлеклесе. 1910 елдан “Сәйяр" труппасында уйный башлый. Октябрьдән соң Оренбургта, Урта Азия республикаларында беренче милли театрлар оештыруда якыннан катнаша, 1929–1931 елларда Ашхабадта үзе оештырышкан Төрекмән дәүләт театрында баш режиссер булып эшли. Вафаты Казанда.

Габдрахман Камал I (1896–1948), артист һәм режиссер. 1912 елдан “Сәйяр"дә уйный башлый. Егерменче елларда Уфа, Пермь, Троицк, Ташкент театрларында эшли, 1925-1939 елларда

– Казанда Татар академия театры артисты. Абыйсы Г. Камалның әдәби мирасын туплау буенча зур эш башкара, 1941 елда аның уникаль альбомын төзеп чыгара.

Зәйнәп Камалова (1899–1977), Галиәсгар Камалның бертуган сеңелесе, Татарстанның атказанган артисткасы. Озак еллар Урта Азия театрларында һәм Татарстан дәүләт күчмә театрьнда эшләде.

Инде Камаллар нәселенең икенче буынына күчик. Галиәсгар Камал үз гомерендә ике тапкыр өйләнә. Беренчесе – Зәүҗәсе Бибигайшәдән (ул 1918 елны вафат була) 6 бала туа: Әхмәт, Әминә, Фәһимә, Әнәс, Мөхәммәт, Зөфәр.

Болардан беренче өчесе сабый чакларында вафатбула. Соңгысы Әнәс Камал (1908–1978), драматург, артист, режиссер. Кырыклап сәхнә әсәре авторы. 30 нчы елларда күчмә колхоз-совхоз театрын оештыручылардан берсе. Озак еллар Татарстан Язучылар идарәсендә әдәби консультант, Татарстан китап нәшриятында редактор-мөхәррир булып эшләде. Әтисе Галиәсгар Камалның тормышы һәм иҗаты турындагы хикәя, очерк китаплары һәм мемуарлары белән дә мәгълүм.

Мөхәммәт Камалов (1914–1993), озак еллар элемтә системасында эшләгән белгеч, сугыш ветераны, әтисенең соңгы көннәре турындагы истәлек авторы. Бер малай, бер кыз тәрбияләп үстерде.

Зөфәр Камалов (1916–1942), Ватан сугышының беренче көннәреннән үк фронтка җибәрелеп, 1942 елда Орел шәһәре өчен барган сугышларда һәлак була.

Галиәсгар Камалның икенче хатыны Әсма Мифтахетдин кызы Сәгъдиева-Камалетдиновадан (1887–1941) туган балалар:

Фаикъ (1919–1942), сугыш алдыннан Казанда театр техникумын тәмамлап, Арча колхоз театрында артист булып эшли башлый, язучылык хезмәте беләндә шөгыльләнә. 1941 елда фронтка җибәрелә һәм Ростовны икенче кабат азат итү сугышларында батырларча һәлак була.

Фәрит (1921–1976), сугыш ветераны. Әлмәттәге Миңлебай газ-бензин заводында техник-механик булып эшли. 4 кыз тәрбияләп үстерәләр.

Наилә (1924–1925), яшьли вафат була.

Рәфыйка (1926 елда туган), Г. Камалның төпчек кызы. Медицина фәннәре кандидаты, хәзер пенсиядә. Бер кызы пианистка, Казан педагогия университетында эшли, икенчесе – табибә. Инде аларның да үз балалары һәм оныклары бар.

Галиәсгар Камалның энесе Габдулла Камал Інең гаиләсендә тулаем актерлар гаиләсе дип бәяләргә була. Аның хатыны – Татарстанның халык, РСФСРның атказанган артисткасы Фатыйма Камалова (1903–1974), ә кызлары Гәүһәр Камалова (1922–1990) шулай ук Татарстанның халык һәм РСФСРның атказанган артисты исемнәрен йөрткән актриса. Тик менә, кызганыч ки, Гәүһәр Камаловадан соң бу нәсел кешеләреннән татар театры сәхнәсендә бүтән яңа исемнәр әлегә күренми. Озакка сузылырмы бу бушлык? Кистереп әйтеп булмый, ләкин өметне өзмик.

Татарның бөек шәхесләреннән сирәкләренең генә оныклары татар халкына хезмәт итә. Галиәсгар Камалның оныклары исә киресенчә. Алар бабаларының истәлеген – Нариманов урамы, 48 йортта урнашкан Камал йортын яңарту белән шөгыльләнә. Бу йортны XIX азагында күн белән сату иткән сәүдәгәр Садыйк Хәйбуллин төзетә. Ул мәчет төзетеп, анда "үз" мулласын куярга һәм шул рәвешчә, мөселман дөньясында танылган кешегә әйләнмәкче була.  Әмма аның туганнары арасында мулла итеп куярга кулай кешеләр булмый. Бай кызы Бибигайшәне "Мөхәммәдия" мәдрәсәсендә укыган Галиәсгарга бирә һәм аны мулла итеп куярга уйлый. Әмма Галиәсгар мулла

булудан баш тарта. Бабасы белән килешүгә киләләр – Галиәсгар сәүдә эшенә – китап сатуга керешә. Садыйк бай 1902 елда кияве һәм кызына шушы йортны төзетә. 1908 елда бу йортта киләчәктә тагын бер күренекле шәхес булачак кеше – язучының улы Әнәс туа.

1959 елда йорт тарихи истәлек булып танныла. 2012 елда урман хуҗалыгы министрлыгы "Нурлат" лесхозы тырышлыгы белән реставрация проектын ясата.

**Интернет чыганаклардан алынды**

Тулырак: https://intertat.tatar/news/gali–sgar–kamalny–onyklary–babalaryny–mirasyn–saklyy–bu–tatarstanny–m–d–niyat–yorty–diyarg–bula

Тулырак: https://intertat.tatar/news/gali–sgar–kamalny–onyklary–babalaryny–mirasyn–saklyy–bu–tatarstanny–m–d–niyat–yorty–diyarg–bula

## ГАЛИӘСГАР КАМАЛНЫҢ БАЛАЧАГЫННАН КЫЗЫКЛЫ МИЗГЕЛЛӘР

Корбанова З.Г.,
Түбән Кама районы Кама Аланы «1нче гомуми
урта белем бирү мәктәбе» укучысы..
Фәнни җитәкче: Габделхакова Г.И.

Галиәсгар Галиәкбәр улы Камалетдинов  Казанда тире эшкәртүче (камчатчы) хезмәткәр Галиәкбәр һәм Мәүгыйзә гаиләсендә беренче бала булып туа. Аның әтисе Галиәкбәр күп балалы ярлы гаиләдә үскән, ул яшәгән Сикертән авылында балаларга белем бирерлек кеше дә, аларны  укытырлык мөмкинлек тә булмаган.

Тормыш  авыр булу сәбәпле,  Камалетдин абзый  унике яшьлек Галиәкбәрне бер якын туганына ияртеп, Казанга җибәргән. Укый да, яза да белмәгән, бик начар киемле, чабаталы малайны Мифтахетдин исемле бер байга йорт хезмәтчесе итеп урнаштыра алганнар. Галиәкбәр  анда дүрт ел буена бары тик тамагын туйдырыр өчен генә хезмәт иткән. Аннары ул камчат, кама, төлке тиреләре белән эш итүче Фәтхулла Мамаев дигән кешедә эшли башлаган һәм Галиәкбәр  бу эшне бик яратып өйрәнгән, үз эшенең остасына әйләнгән.

Егерме сигез яшьлек Масра авылының бай крестьяны, волостной старшина кызы Мәүгыйзәгә өйләнә, ләкин юньле торыр урыны булмаганга, хатынын Казанга алып килә алмаган, үзенең атасы гаиләсенә Сикертәнгә кайтарып куйган. Бай гаиләдә үскән Мәүгыйзә авыр шартларда яшәргә теләмәгән, елга бер генә тапкыр кайта торган Галиәкбәргә  зарлана торгач, ике елдан гына ул аны Казанга алып килә алган. Аларның 1879 елның 6 гыйнварында (искечә – 1878 елның 25 декабрендә) беренче балалары Галиәсгар туа.

Галиәкбәр бик коры, кискен табигатьле, аз сүзле, ләкин үз сүзендә тора торган кеше була. Бу гаиләдә, туктаусыз эш белән шөгыльләнгәнгәме, әти–әнисе, гомумән, бала җанлы булмыйлар. Кечкенә генә кысан  бүлмәдә гомер

иткән гаиләдә балага рәхәт яшәү өчен, әлбәттә, мөмкинлекләр бөтенләй булмый. Тугач ук елак булган Галиәсгар, башка балалардан аермалы буларак, бик озак тәпи китә алмый. Ата–аналары бу хәлгә бик борчылалар, сәбәбен дә идәннең салкынлыгыннан, таш фатирның юеш һавасыннан күрәләр.

Галиәсгарзур башлы, тулы йөзле,киң маңгайлы, зур коңгырт күзле малай була. Баланың башының зур булуынада фатирдагы дымлы һаваның тәсире бардыр дип борчылган эти–әнисе, икенче фатир эзләп табалар. Ниһаять, гаилә Тихвинский урамындагы Мәҗәр Фазлыйның дворына күчә. Алар Фазлулла бай өенең бер почмагындагы ян бүлмәгә урнашалар. Бу двор өе дә шау–шулы, бик салкын була, чөнки бу йорттан туктаусыз кеше өзелми: берсе керә, берсе чыга, шунлыктан өйдә җылы тормый. Әти–әнисе һаман эшләгәнгә күрә, баланы озын,киң сәкегә чыгарып утырталар. Галиәсгар кергән–чыкканны, ботка пешерүче егет Әхмәтфакилҗанның ашарга пешергәнен карап, күзәтеп утыра. Кайвакыт аңа ботканың көйгәне дә эләгә, ул аны бик яратып ашый, карап торучылар: “Нәни Әскәр сөяк ныгыта, менә тиздән тәпиенә басар”, – дип көлә торган булалар.

Ә бервакыт мич ягучы Гайнелгаян абзый чыгып киткәч, караучысыз калган кечкенә Әскәрмич каршына барып утыра, җылыга оеп китә һәм өстенә ут каба. Моның кычкыруына йөгереп чыккан эти–әнисе нишләргә белми чабышканда, Гайнелгаян абзый килеп кереп, өстендәге чикмәнен бала өстенә каплый. Болай да авыру балага тагын да ныграк газаплар килә. Әскәрнең әнисе Мәүгыйзә, бай кызы булса да, яшьтән үк эшкә өйрәнеп үсә, хәтта татарлар ашамаган гөмбәләрне танып җыя, алардан төрле ризыклар әзерли белә торган була. Дару үләннәрен дә җыеп киптерә белгән хатын малайның яраларын төрле үләннәр ярдәмендә дәвалый. Бала терелгәч, аны сөннәткә утырталар. Заманасы өчен малайлар узарга тиешле иң олы саналган бик изге эштән соң, бала, ниһаять, туп–туры тәпиенә баса һәм йөри башлый.

Инде урамнарга чыгып уйный башлаган Галиәсгарны гел карап торырга гаиләнең вакыты җитми башлый, икенче кызлары тәпи йөрергә җыена, әниләре тагын өченчегә авырлы. Галиәсгарга биш яшь тирәсендә, аны караулы булыр дип, Масрадагы бабаларына озаталар. Бер кыш муллада дин дәресләре укыса да, бала анда бернигә дә өйрәнә алмый. Галиәкбәр абзый икенче кышта Галиәсгарны шәһәргә алып килеп, «Госмания» мәдрәсәсенә укырга бирә. Әтисе фатирны еш алыштырганга күрә, Галиәсгарга еш кына яңа фатирга якынрак булган мәдрәсәгә күчәргә туры килә.

Шулай йөри торгач, 14–15 яшьләрендә, ул «Мөхәммәдия» мәдрәсәсенә керә, шунда торып укый башлый. Галиәсгар анда яңача фикер йөртүче шәкертләр белән танышып, аралаша башлый. Ул вакытта татар дөньясында атаклы булган Ш. Мәрҗани һәм К. Насыйриларның әсәрләрен укый. Әтисе дә «Адрес язарлык өйрәнсә өйрәнсен инде», дип, «Мөхәммәдия» мәдрәсәсе тирәсендә ачылган өч класслы шәһәр башлангыч мәктәбендә Миргаяз Иманаев дигән учительдән русча да укуына каршы тормый.

Шулай итеп, ул елларда Галиәсгар кышын мәдрәсәдә укып, җәен атасы белән бергә Мәкәрҗә *ярминкәсенә*[1] йөри. Чөнки ул вакытта Казандагы татар кустарьларының кайберләре үзләренең эшләгән товарларын Мәкәрҗә ярминкәсенә алып барып сата торган булганнар. Галиәкбәр абзый да, үзенең эшләп хәзерләгән якаларын һәм мехларын сату өчен, һәр ел Мәкәрҗә ярминкәсенә йөргән, иптәшкә Галиәсгарны да үзе белән алып барган. Бу нәрсә яшь Галиәсгарга кустарьлар тормышы белән танышуда зур ярдәм итә. Эштән бушаган вакытларында Галиәсгар Мәкәрҗә ярминкәсендә күрсәтелә торган төрле «кәмитләр» (фокуслар, күчмә театр,балаганнар, цирклар) карап, шулар белән бик нык кызыксына башлый. Киләчәктә драматург һәм артист булачак яшүсмердә бу уеннар яңа чаткылар кабындыра. Ярминкәләрдән Казанга кайткач та, «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә укыла торган дин дәресләреннән аның күңеле бөтенләй суынып, театр белән кызыксына башлый. Галиәсгаряхшәмбе көннәрендә, әти–әниләреннән качып кына булса да, шәһәр театрындагы көндезге спектакльләргә йөри,сәхнә өчен язылган китапларны мавыгып укый һәм үз чорының татар әдәбияты белән якыннан таныша,үзе дә сәхнә әсәрләре язу турында хыяллана башлый. Шулай итеп, ул тормышының икенче этабына аяк баса.

Балачак – кеше тормышында була торган иң кадерле вакытларның берсе. Никадәр генә авыр, яисә рәхәт булса да, кеше үзенең балачагын, үсмерлек чорын артта калдырып, яшьлегенә якынлаша. Тик бу балачак һәркемнең күңелендә мәңге җуелмас бер хәтирә булып, киләчәк тормышына ясаган беренче адымнары булып тора. Галиәсгар Камал да, балачагында очраган беренче каршылыкларны җиңеп, яшьлек язына якынлаша. Менә бу хакта мин икенче вакытта сөйләрмен, чөнки аның турында язылган истәлекләр шулкадәр кызыклы, алар белән танышасы, драматургның тормышын, иҗатын өйрәнәсе, калганнарга да сөйлисе килә.

*Искәрмә.* Мәкәрҗә ярминкәсе (рус. *Макарьевская ярмарка*) – Россиядәге иң дәвамлы сәүдә ярминкәләренең берсе. 1817 елга кадәр Идел елгасының сул ярында, Макарьево авылы (хәзерге Түбән Новгород өлкәсе Лысково районы Макарьево бистәсе) янында урнашкан булган.

**Әдәбият**

1.Абдуллин И. Г. Камал драмаларының теле. – Казан: Татар.кит.нәшр.,1968. 198б.

2.Гайнуллин М. Галиасгар Камал (1879–1933). Тормышы һәм иҗат юлы. – Казан: Татар.кит.нәшр.,1978.

3. Г.Камал турында истәлекләр. Төзүчесе Рәис Даутов. – Казан, Тат. кит. Нәшрияты, 1979. 192 бит. (3–43 нче битләр)

4.Камал Ә.Халык драматургы Г. Камал – Казан: Татгосиздат, 1950.

5. Камал Ә. Гүзәл тормыш сәхифәләре. – Казан: Таарт.кит.нәшр., 1958.– 78б.

# ТАТАР ТЕЛЕНДӘГЕ КАБАТЛАУЛАРНЫҢ СИНТАКСИК ФУНКЦИЯЛӘРЕ

Маннапова Г.Р.,
КФУның Алабуга институты студенты.
Фәнни җитәкче: Хәйруллина Ә.С.

Хәзерге татар әдәби теленең сүзлек хәзинәсендә кабатлаулы конструкцияләр тотрыклы урын алып тора. Х.Х. Сәлимов искәртүенчә, “кабатлау – грамматик чараларның бер төре. Тамырны, нигезне яки бөтен сүзне тулысынча яисә өлешчә кабатлап, грамматик мәгънә белдерү. Сүзләрнең яңа төрләрен, яңа сүзләр яки тәгъбирләр ясау өчен кулланыла. Мәсәлән, *сап–сары, бара–бара, матурдан матур*” [Сәлимов, 2005: 54]. Кабатлаулы конструкцияләр галимнәрдә бик борынгы чорлардан ук кызыксыну тудырып килә. Антиклык чорында кабатлаулар риторик чаралар төркеменә кертеп карала, соңрак, стилистика аерым фәнгә аерылып чыкканнан соң, ул стилистик күренеш буларак өйрәнелә башлый. XX гасырда кабатлауларны җөмләдә бәйләүче чаралар буларак өйрәнүгә багышланган хезмәтләр барлыкка килә. Күпчелек очракта тикшеренү эшләре поэтик текстлар, проза әсәрләре материалында үткәрелгән [Ковальчук, 2004: 11].

Татар тел гыйлемендә лингвистик күренеш буларак кабатлау киң планда өйрәнелмәсә дә, ул гел игътибардан читтә калды, дию дөрес булмас. Кабатлауларның структур типлары беренче тапкыр тулы итеп Гыйбад Алпаровның “Татар телендә кушма төрләр” мәкаләсендә күрсәтелә. Ул аларны “кабатлы кушмалар” дип атый һәм аларның түбәндәге төрләрен аерып чыгара:

1) хәл фигыль: *килә–килә, сугып–сугып җибәрде*;

2) барлык һәм юклык формаларның янәшә килүе: *явар–яумас*;

3) исем сүз төркемнәренең кабатлануы: *төркем–төркем*;

4) сыйфатларның кабатлануы: *матур–матур, гүзәл–гүзәл*;

5) саннарның кабатлануы: *өчәр–өчәр, йөзләп–йөзләп*;

6) рәвешләрнең кабатлануы: *тиз–тиз, шәп–шәп*;

7) –ма/–мә/–бә кисәкчәле интерпозициядәге сүзләр кабатлануы: *күзмә–күз, башма–баш, бермә–бер, йөзмә–йөз* [цитата буенча: Галлямов, 2003: 13].

Кабатлауларның татар телендә киң таралышы, телдән сөйләмдә дә, язма сөйләмдә дә, төрле стильгә караган текстларда да киң кулланылышы җөмләдәге вазифаларының да күптөрле булуына алшарт булып тора. Баш кисәк буларак, алар җөмләдә ия дә, хәбәр дә булып килә алалар. Традицион рәвештә мондый очракларда иң элек ия булып килү үзенчәлекләрен тикшерәләр. Эшебезне башкару дәвамында ясалган аерым күзәтүләребезгә тәфсиллерәк тукталыйк.

Ия буларак кабатлаулар күбрәк ике составлы җөмләләрдә киләләр. Тупланган мисаллар арасында бердәй булмаган компонентлы, компонентлары фонетик яктан аерылып торган кабатлауларның ия вазифасында килү очраклары ешрак теркәлде. Мәсәлән:

Менә ипи катылары тоткан, озын чыбыклар кыстырган *әби–чәбиләр,* сүсләп үргән камчыларын ярыша–ярыша шартлатып, мактанышып, көтү каршысына *малай–шалайлар* җыелыша башлады [Гыйләҗев, 2002: 51].

Мондый исемнәр телебездә еш кулланыла, ия буларак активлыгы да яхшы аңлашыла. Мондый берәмлекләрне парлы сүз рәтендә карау традициясе яшәп килә, әмма Ф.Г. Галләмов ассызыклаганча, бу күренеш кабатлаулы конструкцияләрнең җентекле өйрәнелмәве белән аңлатыла, без дә әлеге эшебездә галимнең "парлы сүзләр һәрвакыт үзарак синоним яки антоним булып ике мөстәкыйль сүздән ясала" дигән сүзләре белән килешәбез [Галләмов, 2009: 28]. Телебездә шулай ук бер үк компонентның кабатланып килүе нәтиҗәсендә ясалган кушма исемнәр дә бар. Алар да ия вазифасын актив башкаралар:

*Мин–минлек* яхшыга илтми,
Мин өстен дип уйлама.
Үзеңә табынып яшәү
Күңел тарлык санала [Шәмсуаров, 2018: 238].
("Берәүгә")

Алдагы очракны карыйк:

Кояш хәзер көн дә чыкмый...
И кояшсыз калулары.
Ә *җан–җаным* көн дә сыктый...
И гомернең кануннары [Миңнуллин, 2021: 32].
("И гомернең кануннары...")

Биредә күзәтелгән очракны без типик күренеш дип атамас идек. *Җан–җаным* кебек бер компонент исем, икенче компонент аның тартымлы формасы булган сүзләр таралыш алмаган, ләкин стилистик чара буларак автор табышы булып тора. Синтаксик яктан, аңлашылганча, ия буларак карала.

Алдагы очракны карыйк:

Йөрәк турындагы җырларымны,
Тау–тау өеп, утта яндырсам,
*–Барсы–барсы* җилгә очар иде,
Көл өеме генә калдырсам [Юзеев, 2002: 17].
("Йөрәк турындагы җырларымны...")

Бу очракта ия булып аваз составы ягыннан бердәй булган тулы кабатлаулар җөмләдә ия вазифасын башкара, ия алмашлыкның кабатлаулы формасы белән белдерелгән.

Кабатлаулар, җөмләдә ия вазифасын башкарып килгән кабатлаулар еш кына әдәби әсәрләрдә стилистик максатларда кулланылалар. Күзәтүебез буенча, алар җөмлә башында һәм ахырында кабатланып килеп, хисләрнең киеренкелеген тәэмин итә. Мәсәлән:

*Җаным* сызлана, *җаным*! [Ибраһим, 2006: 3].

**Әдәбият**

1. Сәлимов Х.Х. Тел гыйлеме терминнары сүзлеге. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2005. – 144 б.

2. Ковальчук И.Ю. Повтор и его функции в тексте: дис. ... канд. филол. наук. – Пятигорск, 2004. – 149 с.
3. Галлямов Ф.Г. Повторы и однородные члены предложения // Наука, образование, общество. – 2016. – № 1(7). – С. 216–223.
4. Гыйләҗев А. Сайланма әсәрләр: повестьлар. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2002. – 447 б.
5. Шәмсуаров Т.Я. Аклыкка сыену: шигырьләр, багышлаулар. – Казан: Рухият, 2018. – 256 б.
6. Миңнуллин Р.М. Мәхәббәтле күзләрем: шигырьләр / кереш сүз авторы Л. Шәех. – Казан : Татар. кит. нәшр., 2021. – 783 б.
7. Юзеев И. Сайланма әсәрләр. 5 томда, 4 том. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2002. – 592 б.
8. Ибраһим Х. Газиз ярым: Пьесалар. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2006. – 318 б.

## ГАЛИӘСГАР КАМАЛ ИҖАТЫНА ИЯРЕП

Марданов Р.Р.,
Мамадыш районы Урта Кирмән урта гомуми белем мәктәбе укучысы.
Фәнни җитәкче: Марданов Р.А.

Татар театры,татар драматургиясе дигәч тә,күңелдә иң элек Галиәсгар Камал образы җанлана. Без аны реалистик драматургия һәм театр бинасын салырга керешкән беренче ташчы дип беләбез.Әдәбият тарихында шундый хөрмәтле урын алуга кадәр Галиәсгар Камал нинди юл үтте соң?Нинди тәэсирләр аның дөньяга карашын, иҗатының тематикасын билгеләде?

Драматург Галиәсгар Камал белән таныша башлау 6 нчы класс дәреслеге белән бәйле. Дәреслек авторлары:Ганиева Флера Әкрам кызы һәм Гарифуллина Мәдинә Дәүләтҗан кызы.Татар телендә гомуми белем бирү оешмалары өчен чыккан уку әсбабының 70 нче битендә Гәлиәсгар Камал тормыш юлыннан биографик фактлар китерелә.Фактлардан аңлашылганча:ул Казанда тире эшкәртүче хезмәткәр гаиләсендә туа,Арча районы Түбән Масрада мәктәпкә йөрүе, Казанга кайтып,”Госмания”,”Халидия” мәдрәсәләрендә һәм заманының алдынгы дип саналган “Мөхәммәдия”дә, аннан өч сыйныфлы рус классында башлангыч белем алуы хакында әйтелә.Татар әдәбияты театр сәнгате белән кызыксына башлавы, рус театрларында барган спектакльләргә йөрүе, журналистик эшчәнлеге, рус һәм дөнья әдәбиятыннан шактый гына сәхнә әсәрләре тәрҗемә иткәнлеге җиткерелә .Шуннан соң Галисәгар Камал белән танышу Әлфәт Мәгъсүм улы Закирҗанов язган 9 нчы класс өчен чыккан Әдәбият дәреслегендә дәвам иттерелә.Әлеге дәреслектә драматургның истәлекләре белән генә танышабыз. Татар дөньясында танылу алган Галисәгар Камал иҗаты әдәбият дәреслекләрендә бик аз яктыртылган,ди укытучыбыз. Димәк, драматургның иҗаты белән кызыксынган кешегә үз карамагына калдырыла. Укучының кызыксынуы көчле икән башка чыганаклардан эзләнеп

өйрәнергә кала һәм үзалдына сорау куя: “Тагын нинди өлкәләрдә Галисәгар Камал үз көчен сынап карады икән?” Менә шушы кызыксыну мине бу шәхес белән тагын да якыннан танышуга китерде.

1979 нчы елның январенда Галиәсгар Камал тууына 100 ел тулу уңаеннан, драматургның әсәрләреннән тупланган 3 томлык җыентык әзерләнә.Әлеге җыентыкта Галисәгар Камалның күпьяклы һәм талантлы иҗатчы икәнлеге азсызыклана. Әйтик, ул:драматург, тәрҗемәче, ялкынлы публицист, журналист, өлгер трибун–шагыйрь, рәссам–карикатурчы, полиграфия остасы һәм матбугат–нәшрият җитәкчесе, актер, режиссер–боларның һәммәсе буенча аның татар мәдәнияты тарихында үзенчәлекле якты эз бар, болар аны актив иҗатчы, киң белемле һөнәр иясе,олы җанлы гражданин итеп характерлый.

1906 нчы елның 22 декабрендә Казанда беренче тапкыр татарча спектакль куела. Шушы тарихи вакыйга Галиәсгар Камал исеме белән бәйле. Рөхсәт бар,әмма чимал юк. Галиәсгар Камал тиз арада Төрек язучысы Намикъ Кәмалның “Кызганыч бала” пьсасын тәрҗемә итә. «Ул чорда чагыштырмача алгарак киткән бу әдәбият теле аңлаешлы булу аркасында татар яшьләренә бер өлге хезмәтен үтәгән икән, биредә гаҗәпләнерлек нәрсә юк. Булачак драматургның каләмгә тотынуы атаклы төрек язучысы Намикъ Кәмал йогынтысы белән дә бәйләнгән. Г. Камал үзе бу турыда түбәндәгечә яза: «Төркиядән кайткан китаплар арасында, – ди ул, – Намикъ Кәмалның таш басмада казылып басылган «Заваллы чуҗык» дигән драмасы килеп чыга. Нинди зур байлык! Җитмәсә миң инде төрекчәне дә бераз сукалый башлаган. Аны кат-кат укыйм, аңлыйм. Нәкъ шул вакытларда минем үземнең башымда да бер тема йөри. Н. Кәмалның китабы мине кузгатып җибәрә дә, мин үзем уйлап йөргән «Бәхетсез егет» дигән нәрсәмнең беренче редакциясен язып, укытучым Миргаяз Иманаевка күрсәтәм»* *(* Камал Г. Әсәрләр. 2 т., 1951, 266 бит.).*

Татар драматургиясе үсешенә үз өлешен керткән әлеге пьеса нидән гыйбарәт соң? “Кызганыч бала” драмасында геройларның язмышы акчага бәйләнгән. Кызганыч бала – Шәфыйка, этисенең бурычларын түләү өчен,үзен бер карт байга корбан итәргә мәҗбүр була һәм шул кайгыдан авырып һәлак була. 1906 нчы елның 22 декабрендә “Гыйшык бәласе” исемле комедия белән икесе татар театры сәхнәсен ачкан көндә уйнала.Автор әлеге пьессаны өч фасылдан гыйбарәт театр уены, дип күрсәтә. Шул чор татар әдәбиятында киң урын алган проблема – хатын-кыз хокуксызлыгы яктыртыла. 6 нчы класс уку әсбабында бирелгән драматургның биографисендә телгә алынган бу пьесса укучы күңелендә кызыксыну тудырмый калмый.Тагын бер кат басым ясап, укырга теләге булган укучыда!

Г. Камалның иҗаты белән танышканда аның проза әсәрләре дә барлыгы ачыкланды.Галимнәрнең әйтүенчә алар күп түгел. Аның иң беренче проза әсәре – 1900 нче елда язылган «Сабир хәзрәт» хикәясе. Икенче зуррак проза әсәре – 1909 нчы елда язылган «Күгәргән алтыннар» хикәясе.Аның бу хикәясе приключение характерында язылган булса да, автор анда муллаларның һәм

байларның алтынга алданып,саташып йөрүләреннән көлә һәм аларның никадәр ач күзле, комсыз икәнлекләрен күрсәтә. Әгәр 6–9 нчы класс дәреслекләреннән берсенә “Күгәргән алтыннар” хикәясе,”Бәхетсез егет” пьессасы да кертелсә, (Г.Камалның беренче иҗаты да) әлеге әсәрләр укучылар игътибарыннан читкә китмәс иде.

Йомгаклап шуны әйтәсе килә. Г.Камал иҗатын күзәтү барышында миндә шундый бер фикер туды. Әдәбият дәреслекләрендә өйрәнү–уку өчен тәкъдим ителгән “Беренче театр” комедиясе белән “Банкрот” комедиясе арасында “Бәхетсез егет”,“Кызганыч бала” драма әсәрләре һәм “”Күгәргән алтыннар” хикәясе дә тәкъдим ителсә, драматург иҗаты тулы ачылыр,аны борчыган һәм киң җәмәгатьчелеккә чыгарган мәсьәләләрне укучы да күрә алыр иде.Әйтик, тәрибя, әхлак,мәгрифәтчелек карашларын туплаган бер комплекс кебек.

**Әдәбият**


1. Сайланма әсәрләр. Том I:Г.Камал.– Казан:Татар. кит. нәшр.,1978.
2. Татар классик драматургиясе:Галиәсгар Камал. Мирхәйдәр Фәйзи.– Казан:Татарстан Республикасы “Хәтер” нәшрияты,2004.
3. http://gabdullatukay.ru/tukay–environment/galiesgar–kamal/mohemmet–gali–galiesgar–kamal–g–kamalnyn–bashka–eserlere–hem–hezmetlere/?option=com_content&task=view&id=1803&Itemid=138


## ГАБДЕРӘХИМ УТЫЗ–ИМӘНИ ӘЛ–БОЛГАРИ


Маткаримова А.Х.,

Әлмәт шәһәре «13нче урта гомуми белем бирү мәктәбе» укучысы.

Фәнни җитәкче: Гарипова А.Ш.


Г. Утыз Имәни иҗаты бер урын белән тора. Озын гомеренең ике өлеше ике гасырга бер дәрәҗәдә диярлек тигез килгән әдип иҗаты тарихыбыздагы ике чорның каршылыклы сыйфатларын, үзенчәлекләрен берьюлы чагылдыра, аларны чишелмәслек төен рәвешендә бергә укмаштырып бирә. Социаль–экономик структурада туганшушыторгынлыкдиндә үзенең гәүдәләнешен таба.

Дини тәгълиматта гел Аллага гына буйсынып, гадәти көнкүрештәге активлыктан ваз кичү идеясе аркылы чагылды. Әдәби процесста исә ул дөньяви мотивлардан йөз чөерү, оригиналь фикерләрне кагу, элек тудырылган сюжет һәм образларны төрле яклап кабатлау рәвешен алды.

Шагыйрьнең биографиясенә кагылган, XVIII йөзлегә 80 нче елларында аның Урта Азия якларына китеп бару сәбәпләренә тукталган чакта, гадәттә Пугачев хәрәкәте, шул вакыйганың күңелсез нәтиҗәләренә ишарә ителә. Патша хөкүмәте рус булмаган халыклардан бер төркеменең авызларын томалау, икенчеләрен киләчәктә үзенә күмәкче, фикердәш итү юлын сайлады. Ташкалалар: мөселманнарга дин тотуда беркадәре азатлык элементлары бирде, махсус дини оешма–Диния нәзарәтен оештырды (нәзарәт башына татарлардан чыккан, белеме буенча ярты мулла, ярты чиновник, мәгәр функция һәм

бурычлары, иман һәм гамәлләре егылган тәмам җитлеккән шымчы, доносчы мөфтиләрнең билгеләнә килүе шуны раслый). Бу–мәсьәләнең бер ягы.

Мәсьәләнең икенче ягы: Диния нәзарәтен оештыру яңа импульс бирде–буылып торган дини аң, омтылыш 18 йөзнең ахырыннан башлап колачын киңрәк җәйде, тамырларын җибәрде.

18 йөзнең ахырында – 19 гасырның башында иҗтимагый фикеребез мәйданына Г. Утыз Имәни килеп чыгуы әлеге процессның бер чагылышы иде.

“Бохаран Шәрифкә” юл тотып ул:

– Яңа баскычка күтәрелгән иҗтимагый аң эзләнүләренең нәтиҗәсе;

– Татарларга патша хөкүмәте күрсәткән рухи идеологик изүгә протест. Бохарада Г. Утыз Имәни башта “нугай шәкерт” , аннары “нугай хәлфә” булып гомер уздыра. Бу шәһәр аны канәгатьләндерми башлый.

Ул гаиләсе белән Сәмәрканд, Бәях, Кабул, Һират шәһәрләрендә булып чыга, берара суфиларга ияреә. Аның тырышлыгы нәтиҗә бирми–гади кеше надан булып кала. Шулай йөри торгач, хатыны үлә, аны бер кышлакта җирлиләр. Шуннан соң ул Утыз Имәни авылына кайта.

Г. Утыз Имәни гыйлем, белем эзләп Бохарага бару идеясен төбе–тамыры белән кире ача. Шагыйрь уйлавынча, Бохара руханилары азгыннар, уйнашчылар, бозыклык чыганаклары гына. Монда ул мөселман дөньясының танылган бер үзәгенә карата буелган өмет–ышануларны да югалта. Шагыйрь үз ватанына шушы югалтуларга тарыгач кына кайта. Поэма 1795 елга хәтле языла. Туган авылында ул җирсезлек белән очраша. Күптән түгел оештырылган Диния нәзарәтына, аның җитәкчеләренә өмет багкый. Шушы сәбәпләр ачы башкорт якларына барып чыгарга мәҗбүр итә.

Ул анда хәбәрсез югалган башкорт кантаны Локманга угыл булып хөкүмәт дәфтәренә язылырга мәҗбүр итә. Шушы фиктив акт үз ватанында яшәр хокукы бирә. Әмма ул анда да озак тормый, күченеп китә–Чистай, Бөгелмә тарафларындагы татар авылларына таба елыша. Аның болай үзенә урын таба алмавы аның җирле мөселман руханилары белән тыныша белмәгәннән килә. Г. Утыз Имәни җәмәгатьчелекнең әхлак–әдәбе, рух–иманын төзәтү эшенә тотынмак була. Ул үзенең кечкенә мәдрәсәсендә яшьләргә сабак бирә, поэзиягә мөрәҗәгать итә. Аның “Замана бүләкләре” поэмасы барлыкка килә. Бу поэма тыгыз эчтәлеклә мөкәддимә белән башлана. Анда сүз ата–анадан туган, кешеләр арасындагы тирәк каршылык, аңлашылмаучанлык өчен борчылу турында бара. Кешеләр арасындагы каршылыкларны тасвирлар өчен авторга материал җитәрлек була.

Икенче бүлектә ул Ватанга кайту, анда ниләр күрүе хакында хикәя итә. Гади халык белән руханилар арасындагы мөнәсәбәтләрнең шулай иҗтимагый һәм соң антогонистик эчтәлеккә ия булуын тоя башлаган шагыйрь муллаларның чын йөзләрен ача алу дәрәҗәсенә җитә яса.

Аның алдына “Чын мулла ничек булырга тиеш?” дигән сорауга ул өченче бүлектә җавап бирергә тырыша.

4 бүлек–динне савыктырырга мөмкин.

5 бүлек–ислам өчен “ят” галәмәтләргә, гореф–гадәтләргә туктала.

6 бүлек–җиде махсус төркем санала.

Г. Утыз Имәни барыбер өметсезлеккә бирелми. Аның өмете–кеше аңының яхшы якка үзгәрүе.

“Тәңиһ–ел–олкяф дән нәсаих–ел–фикерләрен нәкъләндерүе файдалы әйхар” поэмасында бирелә.

Киңәшләр, сүз гомуле христианлык, руслык хакында түгел, бәлки Гришканың керәле имансызлыгы хакында бара. Шагыйрь фикеренчә, кешеләргә хас начар сыйфатлар: тоткан юлдагы тотрыксызлык, икейөзлек.

Г. Утыз Имәни күтәреп чыккан принциплар: иманда аңлылык, гамәлдә тугърылык, гаделлек.

“Әбйаты төрки фи фазыйләте гыйлем” исемле шигырендә чагылыш тапты. Шагыйрь аңлавынча гыйлем ул–һәр ике дөньяда–гадәти көндәлекле тормышта да, ахирәт җиткәч, кеше өчен бер дәрәҗәдә зарур.

Утыз Имәни фикеренчә, күгереп язылган китап ул, бер урында бикләнеп ятмыйча, кулдан–кулга күчеп йөрергә тиеш. Бары шулай иткәндә генә китап үз бурычын үти.

Туры сүзлелеге, фикердә кыюлыгы һәм күтәреп чыккан мәсьәләнең яңалыга, актуальлеге Гәбдерәхим хәзрәткә шул гөр интеллектуаль татар тормышында зур абруй китерә. Чорының көчле фикер иясе үзенең бу дәрәҗәсен гөмере буена тиешле югарылыкта тота. Авылдашлары, тирә–юньдәге таныш–белешләре арасында ул хосусый милек, шщхси мәнфәгатьтән өстен кеше буларак дан казана, какшамас тугърылылык, саф әхлак символына әверелә.

**Әдәбият**

1. Госманов М. Габдерәхим Утыз Имәни әл Болгари // М.Госманов. Үткәннән – киләчәккә. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1990. – 199–263 б.

2.Шәрипов Ә. Габдерәхим Утыз Имәни // Татар әдәбияты тарихы. – 1 т. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1984. – 428–442 б.

3. Шәрипов Ә. Танылган шагыйрьнең басылмаган әсәрләре // Фән һәм мәктәп. – 2003. – № 11. – 24–28 б.

4. Әхмәтҗанов М. Габдерәхим Утыз Имәни һәм аның дәвере // Мирас. – 2004. – № 10. – 37-41 б.

## МӘГЪРИФӘТЧЕ ИДЕЯЛӘРЕН ДӘВАМ ИТҮЧЕ

Мордовина К.В.,
Бөгелмә шәһәренең18нче төп мәктәп укучысы.
Фәнни җитәкче: Насыбуллина А.Н.

Татар язучылары арасында күпъяклы талантлар бар. Бу җәһәттән Галиәсгар Камал бигрәк тә аерылып тора. Ул – драма әсәрләре, хикәя һәм шигырьләр авторы да, журналист һәм тәрҗемәче дә, театр эшлеклесе һәм рәссам да. 1926 елда аңа рәсми төстә “Татар халык драматургы–әдибе” исеме

бирелә һәм ул – “татар драма әдәбиятының зур хезмәтчесе, атасы һәм татар артистларының якын ярдәмчесе” дип бәяләнә.

Галиәсгар Камал Казанда туа. Аның әтисе Галиәкбәр Камалетдин улы үз кул көче белән гомер итүче ярлы кеше була. Ул вакытта шәкертләрне мәдрәсәләрдә укыту түләүле булган. Галиәсгар Камал, китап сатучыларга ялланып, төрле шәһәрләрдәкитаплар сатып йөри. Мәдрәсәдә ул үзе эшләп алган акчага укый.

Мәдрәсәне тәмамлагач, әтисе мулла булырга бик үгетләсә дә, риза булмый, халыкка аң–белем бирү эшен дәвам итәргә карар итә. Рөхсәт алып, “Мәгариф китапханәсе” ача. Китап бастырып тарату эшенә керешә. Монда ул татар милләтенең иң алдынгы кешеләре белән таныша.

Китап бастыру һәм тарату эше белән генә канәгатьләнмичә, “Азат” газетасына эшкә керә һәм үзе дә яза башлый. Ә бераздан үзе “Азат халык” газетасын чыгара. Монда ул бик күп мәкаләләр бастыра.

Яше зур булмаса да, башка әдипләр каршында ул иглекле зирәк аксакалга әйләнә. Галиәсгар Камал ярдәмгә мохтаҗ әдипләргә ярдәм итә. Алдынгы карашлы кешеләр аны зурлыйлар, хөрмәт итәләр.

Галиәсгар Камал үзен тиз арада үткен телле кыю сатирик итеп таныта. Беренче пьесаларында үзенә кадәрге мәгърифәтчелек әдәбиятының традицияләрен дәвам итә. Драматургның әдәби иҗатындагы беренче тәҗрибәләре булган “Бәхетсез егет” (1нче вариант, 1898), “Өч бәдбәхет” (1900) пьесалары һәм “Сабир хәзрәт, яки Гыйбрәт” (1900, басыла: 1903) хикәясендә үз чоры өчен иҗтимагый әһәмиятле булган, милләт язмышы белән бәйле мәгърифәт һәм әхлак мәсьәләләрен үзәккә куя. Аларның “Бәхетсез егет”тә яңа фикерле Әхмәт, ә икенче пьесада укымышлы, гыйлемнең тормыштагы файдасы турында уйланган һәм бу яктан Мәхмүткә каршы куеп сурәтләнгән Гомәр мисалларында раслана.

“Сабирхәзрәт, яки Гыйбрәт” әсәрендә бозык, азгын, аталык хисләреннән мәхрүм Сабир хәзрәтнең тормышы гыйбрәт итеп сөйләнә. Аңа керсез күңелле, яхшыны яманнан аера белүче, сабыр холыклы, гыйлемле Габдулла мулла каршы куела.

Галиәсгар Камал үткен күзле әдип булган. Үзе яшәгән заманда татарларның төп гаебен күреп алган. Кешеләрне ахмак бәндәләр әрсезлегенә каршы тора алмауда, мескенлектә, куркаклыкта гаепләгән. Заманга хас типик әрсезләрне, куркакларны күреп алган. Аларны көлкегә калдырып сурәтләгән. Шуның белән бергә әдип бу кешеләрнең үзләренә генә хас холыкларын да күргән.Аның типик геройлары да үзләренчә әрсезләр, үзләренчә наданнар һәм үзләренчә мескеннәр.

**Әдәбият**

1. Әдәбият (XX йөз башы һәм 20 нче еллар): Татар урта гомуми белем бирү мәкт. 10нчы с–фы өчен д–лек/ М.Х.Хәсәнов, А.Г.Әхмәдуллин, Ф.Г.Галимуллин. – 3нче басма. – Казан: Мәгариф, 2005. – 399 б.

2. Гыйлаҗев Т.Ш. Татар әдәбияты.XX гасыр башы: Лекцияләр, гамәли дәресләр, тестлар: Югары уку йортлары өчен уку әсбабы/ Т.Ш.Гыйлаҗев. – Казан : Мәгариф, 2007. – 239 б.

3. Яхин А.Г. Әдәбият: Унберьеллык мәктәпнең 6–7 класслары өчен дәреслек–хрестоматия. – Казан: Мәгариф, 1993. – 287 б.

## КӘШЕР АВЫЛЫНДА БЕРЕНЧЕ МӘДРӘСӘЛӘР АЧЫЛУ

Мөбәрәкшина Д.Л.,
Әлмәт районының Яңа Кәшер урта мәктәбе укучысы.
Фәнни җитәкче: Шайхулова А.И.

Укыту тәрбия эше һәр чорда беренче урында торган. Кәшер авылы Бөгелмә өязенә кергән зур авыллардан исәпләнгән. Үзебезнең авылда уку–укыту, аң–белем бирү эше элек–электән алга китә.1762 елда авылда 150–160 чамасы кеше яшәгән ( 1850 нче елның статистикаи мәгълүмәтләре буенча Бөгелмә өязе авылларында бер гаиләдә уртача 6 кеше булган). Авылның яңа оешып килүен, халык тормышының бик ярлы булуын исәпкә алсак, халык нинди генә динле булмасын, әле мәчет салырлык көчләре булмаган.

Архив материалларына караганда Кәшер авылында беренче мәчет 1783 нче елда, икенче мәчет 1798 нче елларда гына төзелгән. Авылдагы ике мәчет тә 1781 нче елда Әби патшаның мөселманнарга мәчетләр төзүне тыя торган элгәре указы бетерелеп, Ырынбурда мөселманнарның Духовное Собраниесе оешкач кына төзеләләр. Оренбург губернясы Сенатының 1749 нчы елгы указы нигезендә Кәшер авылы җирлегендә “типтәрләргә” җир бирелә, менә шушы указдан соң авыл кисәк кенә зураеп үсеп китә. 1795 нче елда икенче мәхәллә оешып, икенче мәчет төзелә. Авылда халык ишәйгән саен балаларны укыту ихтыяҗы туа.

1850нче елда беренче мәдрәсә ачыла, 1885–1888нче елларда авылда 3 мәдрәсә исәпләнә. Балаларны гадәттә 9–10яшькә җиткәч кенә укыта башлаганнар, кыз балаларны аерым, ир балаларны башка өйләрдә укытканнар. Мәдрәсәләрдә хәллерәк кешеләрнең балалары гына укый алган. Мәдрәсәләрнең бөтен расходлары шәкертләрнең ата–аналары җилкәсеннән булган. Утын, керосин ремонт чыгымнары өчен мәхәллә халкы һәр елны мәҗбүри салым түләгәннәр, түләмәгәннәрнең балаларын укырга алмаганнар. Мәдрәсәдә укытучы хәлфәләргә дә аерым эш хакы түләү булмаган, алар үзләре укыткан шәкертләренең ата–аналары җомга, бәйрәм көннәрендә җибәргән 3–5 тиен сәдакадан җыелган акчага яшәгәннәр. Җәен мәдрәсәләрдә укулар туктап торган чорда хәлфәләр надан кыргызлар якларына барып аларга Коръән укып, дини йолалар үтәп акча эшләп кайта торган булганнар. Мәдрәсәгә түләргә хәленнән килмәгәннәр малайларын шулай ук дини белемле, ләкин указы булмаган муллаларда укытканнар. Бу муллалар авылдагы үлем–җитем никах, балага исем кушу кебек эшләрне халыкка үтәп барарга булышканнар. Кәшер кебек зур авылга бу туктаусыз эш булган. Бу муллалар һәр мәхәлләнең үзенекеләр

булганнар, революция чорларында һәм соңрак – Җәмил мулла, Сәләх мулла, Шәриф мулла һәм Гәлим Надыровлар гомергә үз өйләрендә ир балалар укытканнар. Кыз балалар өчен Кәшердә мәдрәсәләр булмаган. Кыз балаларны абыстайлар өйләрендә укытканнар. Кәшер тарихына исемнәре кереп калган абыстайлар Фәтхия Гәрәева, Фаизә Мөхәммәдиева, Фахирә Ханнанова, Бибисара Суфыянова, Шәмсенаһар Насыйбуллина, Икълимә Ахматшина, Мәгыйшә Мостафина, Хәдичә Әхмәтлатыйпова һәм Мөҗфика Гомәрова. Һәркайсы үз мәхәлләләрендә әз–мәз сдака, йорт тирәсендә эшләрен карашканга, утау уташу хисабына үз өйләрендә кызларга дин сабаклары укытканнар. Алга таба укуны булдырырдай яки ата-анасының мөмкинчелеге булган балалар гына дәвам иткәннәр, чөнки авыл халкы ел әйләнәсе хуҗалык эшләре белән мәшгуль, тамак туйдыру мәсьәләсе мөһимрәк булган.

Кәшер укымышлылыгы, мәдрәсәләре белән дан казанмаган. Гали Мансуров чорында ысул–җәдит мәктәбе генә бер балкып алган. Ысул–җәдит мәктәбе һәр елны шәкертләрнең язгы чыгарылыш имтиханнарын түбән оч мәчете каршындагы мәйданда уздыра торган булган. Моны күрер өчен бөтен авыл халкы язгы кырык эшен ташлап җыела торган булган.

**Әдәбият**


1. Х.Султанов «Старшина Ишмөхәммәт Йөзекәевнең Олы Урсала елгасы буендагы Яңа Кәшер авылы», ООО «Городская типография», г.Альметьевск, 2022 г.
2. https://tatfrontu.ru/personi/7 Виртуальный музей ВОВ Республики Татарстан.
3. Туган якны өйрәнү музее материаллары.


## МӘДӘНИ КОД БУЛАРАК МИЛЛИ РИЗЫКЛАР
**(татар һәм кытай ризыклары мисалында)**


Мөхәммәтшина А.Ф.,
Казан федераль университетының 2 курс магистранты.
Фәнни җитәкче: Нурмөхәммәтова Р.С.


Өстәл йолалары кеше көнкүрешенең иң мөһим өлеше, алар безнең көннәргә кадәр яшәгән кешеләрнең тәҗрибәсен чагылдыра һәм тамырлары белән борынгы заманнарга барып тоташа. Бу гореф-гадәтләр табигый, тарихи һәм социаль–икътисади шартлар, күршеләр белән мәдәни алмашу йогынтысы астында формалаша. Шуңа күрә милли аш-су халык тарихының һәм матди мәдәниятенең бер өлеше булып тора.

Милли ашларның үзенчәлекләренә дини гореф–гадәтләр, яшәү рәвешен регламентташтыручы борынгы гореф-гадәтләр йогынты ясаган. Мәсәлән, мөселманнарның күпчелеге дуңгыз ите ашамый, Һиндстанлылар үз рационыннан өлешчә яки тулысынча хайваннардан алынган ризыклардан баш тарталара. Кытайлар сөт продуктларын бөтенләй ашамыйлар. Өзерләнгән

продуктларның тәме продуктларны эшкәртү технологиясе үзенчәлекләренә, төрле җылылык эшкәртү алымнарына, төрле продуктлар комбинацияләренә тәэсир итә.

Җир шарында никадәр милләт булса, гореф-гадәтләр саны да шулкадәр. Бу гадәти күренеш, чөнки һәр халык дөньяның кайсы почмагында булуына карамастан, үз кануннары, үз йолалары, үз тәртипләре белән яши. Әлеге үзенчәлек аш–су өлкәсенә дә карый. Милләтләрнең, халыкларның үзенә генә хас ризыклары, аларны әзерләү рәвеше бар [Марушкина 2014: 3].

Кытайлар белән татарлар күп яктан бер-берсенә туры килеп бетми. Алар, гомумән, төрле территорияләрдә урнашкан, төрле дин, төрле тел гаиләләренә карыйлар, аларны төрле сәяси режим, төрле мәдәният, дөньяга төрле караш аерып тора. Әмма шуңа карамастан төрки телләрдә күп кенә кытай алынмалары очрый.

Бу мәкаләдә ризык төркеменә игътибар итү максаты куелды. Бу мәсьәләгә мөнәсәбәт тә әлеге халыкларда охшаш. Татарларда якыннардан хәлләрен, сәламәтлекләрен сораган вакытта, “Ашадыгызмы әле?” яки “Син бүген ашадыңмы?” дип сорыйбыз. Кытайларның исә инде хәлләрне сорау конструкциясендә үк “ашау” сүзе бар: **“你吃饭了吗?”***(Син ашадыңмы? пьинин –Nǐ chīfàn le ma?*) Сораудан тыш ризыкны калдыруга караш та бер. Татарларда да, кытайларда да аш–суны кадерләргә кирәк, калдырырга ярамый һәм ашап бетерәсе дигән ышану яшәп килә.

Ризыкларның үзенә килгәндә, бу мәдәниятләрдә охшаш атамалы, охшаш кыяфәтле яки охшаш тәмле булган үрнәкләр еш очрый. Мәсәлән, Таҗикстан, Казахстан, Үзбәкстан, Башкортостан, Татарстанда пешерелә торган “манты” Кытай халкының **馒头** га *(пьинин – mántou)* тиң. Бу очракта без моны бертөрле әйтелешле булган ризык итеп кенә түгел, ә кыяфәте, әзерләү ысулы да үзара охшаш булуны күз алдында тотабыз. Кытай теленнән тәрҗемә иткәндә, **馒头**сүзе *“тутырмалы баш”* дигәнне аңлата, ягъни “эчендә нинди дә булса тутырма булган баш формасында ясалган ризык”. Төрки халыкларда да, Кытайда да аларның формасы бер, икесе дә парда пешерелә, әмма эчлеге белән аз гына аерыла. Безнең халыкларда – ит һәм бәрәңгедән булса, кытайларда ул баллы эчлек (персик, кабак, сакура һәм роза кайнатмасы һ.б.) белән дә, тозлы эчлеК (гөмбә, доуфу, кәбестә) белән дә әзерләнергә мөмкин, ә ит һәм бәрәңге беркайчан да кулланылмый. Кытай халкында ит белән бәрәңге гомумән сирәк очрый торган кушылма.

Шулай ук бу халыкларда формасы һәм кулланылышы белән охшаш тагын бер ризык – ул чәк–чәк. Бигрәк тә татарларда һәм башкортларда очрый торган әлеге ризык майда пешерелгән вак камыр кисәкләрен суынгач бал белән катырып ясала. Татар халкындагы бу ризыкның исеменә бәйле берничә аңлатма бар. Беренчесе чык формасына охшаганлыктан, халыкта чәк–чәк дип киткән дип фаразлый. Икенчесе әлеге камыр кисәкләрен майда пешергәндә чыгарган тавыш кебек дип аңлата, өченчесе исә “чәк” сүзе “вак” мәгънәсендә килә ди.

Кытай телендә аның исеме – **油条***(пьинин – yóutiáo)*. Сүзнең өлешләрен аерым алып тәрҗемә иткәндә 油*“май”* һәм 条*“озынча предмет”,* ягъни “майлы озынча предмет” дигәнне аңлата.**油条**шулай ук майда пешерелгән озынчарак формада, ләкин зур булмаган камыр кисәкләре. Ул сап–сары төстә булганчы кыздырыла. Әлбәттә, бу территориядә бал юк, шуңа күрә дә катырылмый, ә аерым ашала. Күп очракта аны төрле тәмләткечләр ярдәмендә баллandыралар, әмма тозлы варианты да еш очрый. **油条** да, чәк-чәк тә чәй эчкәндә десерт буларак тәкъдим ителә.

Җир шарында һәрбер халыкның үз тарихы, үз гореф–гадәтләре, үз йолалары, үз яшәү рәвеше, дөньяга үз карашлары бар. Һәр халыкның кабатланмас яклары күп. Әлеге үзенчәлекләрнең берсе – милли ризыклар. Милли ризык – ул гасырлар дәвамында камилләшеп килгән гореф–гадәтләрнең асылы. Милләтнең һәр кешесе аның серләрен саклап, буыннан–буынга тапшырган. Төрле халыкның ризыклары атмалары, төсе, кыяфәте яки тәме белән бик охшаш булса да, әлбәттә, аларның аермалары да шактый, чөнки ул – һәр халыкның үзенеке (без моны алда күрсәтелгән ризыклар мисалында күрдек). Милләтләрнең аш–сулары үзенчә зәвыклы һәм кабатланмас, шуңа күрә дә аларны кадерләп сакларга, киләчәк буыннарга җиткерергә кирәк.

Нәтиҗә ясап, шуны билгеләп үтәргә кирәк: Кытайның һәм татарларның милли аш–суы бай тарихи традицияләрен дә, илнең табигый–географик күптөрлелеген дә җыйган, мәдәниятнең үзенчәлекле архетипларын чагылдыра һәм актив рәвештә тарала. Милли ризыклар трансляцияләнгән мәдәни кодлар көндәлек культураның мөһим өлеше булып тора. Милләтләрнең аш–сулары үзенчә зәвыклы һәм кабатланмас, шуңа күрә дә аларны кадерләп сакларга, киләчәк буыннарга җиткерергә кирәк.

**Әдәбият**


1. Габдрафикова Л.Р. Татар ашлары тарихына бер сәяхәт // Идел. – 2020. – №7. – Б.19–21.
2. Жоголева Е.Е., Жоголев Д.А. Китайская кухня. – М.: Агропромиздат, 1991. – 191 с.
3. Марушкина Н.С. Концепт «Еда» в контексте диалога культур: автореф. дис. ... канд. культурологии. – Иваново, 2014. — 25 с.
4. Похлебкин В.В. Национальные кухни наших народов. – М.: Легкая и пищевая промышленность, 1983. – 308 с.
5. Факсмер М. Этимологический словарь русского языка (перевод с немецкого и дополнения члена–корреспондента АН СССР О.Н. Трубачева,). – М.: Прогресс, 1987. – 832 с

# ГАЛИӘСГАР КАМАЛНЫҢ ӘДӘБИЯТТА ТОТКАН УРЫНЫ ҺӘМ ИҖАТЫНЫҢ ИДЕЯ-ЭСТЕТИК ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ

Мукимова Г.Ф.,
КФУның Алабуга институты студенты
Фәнни җитәкче: Даутов Г.Ф.

Галиәсгар Камал татар әдәбиятын үстерүдә иң зур практик эш күрсәткән язучыларның берсе буларак билгеле. Әйтергә кирәк, Каюм Насыйрилар тарафыннан башланган «татар телендә язу» лозунгысын иң башлап тормышка ашырырга керешүче һәм инкыйлабка кадәрге чорда шул юлда иң күп эшләүче язучы, һичшиксез, Галиәсгар Камал иде.

Галиәсгар Камалны, бер яктан, татар театрының һәм татар сәхнәсенең атасы дип атасак, икенче яктан, аны татар әдәби проза теленеңдә атасы дип атарга тиеш булабыз. Бу яктан ул татар теле һәм әдәбияты тарихында татар поэзия телен тудыру һәм эшләүдә зур хезмәт күрсәткән  Г. Тукайга караганда да почетлырак урын алып тора дип әйтсәк, ялгыш булмас. Галиәсгар Камалдан 5-6 елга соңрак әдәбият мәйданына чыккан Г. Тукай да әле үзенең беренче шигырьләрен гарәп, фарсы сүзләре белән чуарланган ярым госманлы телендә иҗат итте. Ул да үзенең беренче адымнарыннан ук татарның чын сөйләшү телендә (Галиәсгар Камал фикеренчә «урам телендә») шигырь тудыруга батырчылык итә алмады. Тик соңыннан гына, татар поэзия телен эшләүдә Галиәсгар Камалның методын кулланып, татар поэзия теленең атасы булып китте. Татар әдәби телен эшләүче бу ике    гигант – берсе проза өлкәсендә, икенчесе поэзия өлкәсендә – гомерләренең ахырына кадәр бер-берсе белән ярышып эш алып баралар һәм нәтиҗәдә хәзерге татар әдәби телен барлыкка китерәләрдә [Абдуллин 1968: 9].

Әйтергә кирәк, Галиәсгар Камал татар әдәби проза телен чын халык теленә нигезли. Ул сөйләү телендә булган һәм әдәбиятка керергә мөмкин булган сүзләрнең һәрберсен кертү тенденциясе белән эшитә, ләкин тел мәсьәләсендә ул провинциализмнан ерак тора. Төп Казан сөйләү теленә кергән «әчкеч», «тушы» (шушы) кебек сүзләрне һәм Печән базары татарлары арасында таралган жаргоннарны әдәбиятка гомумән кертми. Ул үзе туып үскән Казан һәм Казан арты сөйләү теле нигезендә саф әдәби тел барлыкка китерә. «Мәскәү өсте», «Мәкәрҗә өсте», «трахтир сырасы» кебек, Казан татар мещанкаларына һәм «Тумачи, тудык, туганым, аппак» («Банкрот» пьесасыннан)  кебек Казан һәм Казан тирәсенәрәк хас булган кайбер сүзләрне кулланса да, ул аларны тик мещанка образларын җанландыру өчен, хәтта, күп вакытта, аларның телләреннән көлү өчен генә куллана. Моңа, әлбәттә, провинциализм дип карап булмый  [Абдуллин 1968: 13].

Ул «былагайлану», «унагайлану» («Хафизалам иркәм» пьесасыннан) кебек кайбер борынгы халык сүзләрен һәм яңа сүзләрне дә әдәбиятка кертә [Абдуллин 1968: 15].

Аның кайсыбер элеккерәк язган әсәрләрендә аз-маз гарәп, фарсы һәм госманлы сүзләре күренгәләсәдә, ләкин ул сүзләрнең күпчелеге шул әсәр язылганда халыкның сөйләү теленә кергән сүзләр генә. Хәтта, аның шигырьләредә саф халык теле нигезендә язылганнар.

Тик аның инкыйлабка кадәр язган публицистик һәм тәнкыйть мәкаләләрендә генә төрекчәлек тәэсире беркадәр сизелә. «Бәхетсез егет»нең икенче басмасына язган сүз башы моңа ачык мисал булып тора. Ул бу әсәрнең икенче басмасының телен беренчесенә караганда бик нык эшләсәдә, икенче басмага сүз башын беренче басмадагы сүз ахыры кебек саф татар телендә язмый, ярым төрек телендә яза. Бу нәрсә аның ул вакытта «Тәрҗеман» гәҗите теле тәэсирендәрәк язылып барган «Йолдыз» гәҗитендә эшли башлавыннан килсә кирәк. Чөнки элегрәк елларда аның «Азат» гәҗите, бигрәктә үз редакциясендә чыккан «Азат халык» гәҗитендә язган мәкаләләрендә әле төрекчәлек тәэсире ул кадәр нык сизелми. Соңрак елларда «Йолдыз» да язган мәкаләләрендә, бигрәктә «Истамбул хатлары»нда, төрекчәлек тәэсире нык сизелә. Ләкин бу нәрсәгә «Йолдыз»ның төрекчәлек һәм «Тәрҗеман»чылык тенденцияләренең Галиәсгар Камалга булган вакытлы мәҗбүри йогынтысы гына дип карарга кирәк. Шуның аркасында Галиәсгар Камал публицистикада үзенең телен беркадәр бозарга мәҗбүр булган. Ә ул чор – аның художество әсәрләрендәге теленең иң нык эшләнгән һәм чын сөйләү теле нигезендә татар әдәби телен барлыкка китерү өстендә эшләгән чоры булып тора [Арсланов 2004: 9].

«Йолдыз» кабаласыннан ычкынгач, ягъни инкыйлабтан соң, ул үзенең публицистика телендә художество әсәрләре теле дәрәҗәсендә итеп сафландыра. Моны аның инкыйлаб башында «Кызыл байрак» һәм «Эш» гәҗитләрендә язган мәкаләләреннән ачык күрергә була. Ул инкыйлабтан соң инде татарның художество әдәбияты телен генә түгел, публицистик әдәбият телендә ныклап эшләргә керешә.

Әлбәттә, Галиәсгар Камал драматургия төренең художестволылыгын эшкәртүгәдә үзеннән зур өлеш кертте. Әлеге төр өчен бигрәктә мөһим булган хәрәкәт берлеге таләбенә ул нык игътибар бирә. Аның пьесаларында сюжет үзенең төзеклеге, җыйнаклыгы һәм тәмамланган бербөтен тәшкил итүе белән аерылып тора («Банкрот», «Беренче театр», «Уйнаш»). Шуның белән бергә драматург сюжет төзүнең башка ысулларын да куллана. Мәсәлән, «Безнең шәһәрнең серләре» комедиясендә нигезгә фабула алынып, һәр пәрдә үзенә аерым бербөтен, «йомры» сюжетлардан тора. Бу төрне бүгенге әдәбият белемендә «тартмалы сюжет» дип атыйлар. Сюжетны болай кору вакыйгаларны эпик киңлектә сурәтләүгә хезмәт итә. Шул уквакытта без Галиәсгар Камал драматургиясендә инде кичәге көндә калган алым-чараларны да күрәбез. Болар – читкә карап әйтү, яисә бер эш-гамәлне тәфсилләп аңлату, афишаларда персонажларга характеристика бирү, ремаркаларны киң алу һ.б. Бу сәнгати алымнарны татар драматургиясенең үсеш баскычындагы бер басма дип карарга кирәк.

Нәтиҗә ясап, әйтергә кирәк, татар әдәбияты гасыр башында зур уңышларга иреште, яңа бер баскычка күтәрелде, дидек. Ул әдәбиятның иң мөһим сыйфатларын үзләштерде, күпчелек иҗат методларын да шушы чорда формалаштырды. Соңгыларының, ягъни төрле иҗат методларының һәм әдәби агымнар-юнәлешләрнең янәшә яшәве татар әдәбиятын башка әдәбиятлардана ерып куя торган үзенчәлек булып тора. Галимнәр татар әдәбиятының нәкъ менә шул елларда тәнкыйди реализм методы нигезендә зур уңышларга ирешүе белән бергә романтизм иҗат методында да күренекле әсәрләр белән баюын расладылар. Алай гына да түгел, соңгы фәнни тикшеренүләр бездә модернистик агымның да көчле булуын, аерым язучылар иҗатында матур нәтиҗәләргә ирешүен күрсәтә. Болар янәшәсендә «пролетар әдәбияты» дип аталган юнәлешнең дә туып-үсеп килүен истән чыгармаска кирәк, һәм алар, бер-берләренә йогынты ясап, әсәрләрнең сәнгатьчә эшләнешен югары һәм бай булуына китерә. Әлбәттә, әлеге юнәлештә эшләү буенча Галиәсгар Камал, гаять киң кырлы талант иясе һәм иҗтимагый яктан актив шәхес буларак, XX йөз башы татар мәдәнияте тарихында күренекле роль уйнады, үзенең иҗаты белән аның милли тәрәкъкыятен билгеләүче аз гына санлы каләм осталарының берсе булды. Бу хосусият аның татар матбугатын барлыкка китерү, җитәкләү, үстерү буенча каһармани эшчәнлегендә дә этрафлы чагылыш тапты дип әйтсәк, ялгыш булмас.

**Әдәбият**


1. Абдуллин И. Г.Камал драмаларының теле. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1968. – 198 б.
2. Гали М. Г.Камал: тормышы, иҗаты. – Казан: Татгосиздат, 1941. – 156 б.
3. Әхмәдуллин А. Татар әдәбияты тарихында Г. Камалның урыны // Галиәсгар Камал : әдип һәм заман : Язучының 125 еллыгына багышланган мәкаләләр җыентыгы / Татарстан ФА Г. Ибраһимов исем. ТӘҺСИ.. – Казан, 2005. – 156 б.
4. Камал Г. Әсәрләр: 3 томда: 3 т.: хикәяләр, мәкаләләр, рецензияләр, истәлекләр. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1981. – 325 б.
5. Камал Г. Сайланма әсәрләр: пьесалар, хикәяләр, истәлекләр. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2004. – 302 б.


## ДИБӘҖӘ КАЮМОВА – ТӨБӘГЕБЕЗНЕҢ КҮРЕНЕКЛЕ ШАГЫЙРӘСЕ ҺӘМ ПРОЗАИГЫ


Насыбуллина А.Р.,
Алабуга шәһәренең 10 нчы күппрофильле лицее укучысы.
Фәнни җитәкче: Әшрәфуллина Р.И.


Алабуга төбәгендә моңлы, илһамлы кешеләр күп яши. Шулар арасында күптәннән Алабуга төбәгендә яшәп, хезмәт юлын халкыбызның аң – белемен күтәрүгә, мәдәниятен үстерүгә багышлаган, армый – талмый милләтебез

мәнфәгатьләрен кайгыртып, иҗат дәрте белән янып яшәгән Дибәҗә Каюмованы белмәгән кеше сирәктер. Аның иҗат җимешләре газета, журнал битләрендә генә түгел, инде берничә китап булып та дөнья күрде.

Кем соң ул Дибәҗә Каюмова? Якташ язучыбыз Дибәҗә Каюмова – зур талант, гап–гади сүзләрне дә әсәренең иң кирәк җирендә кулланып, иң кирәк урынында аларны алмаз ташыдай ялтыратып, кеше күңеленең иң ерак нокталарына илтеп җиткерә белүче, күңелләрнең иң түрендә әле шытып кына яткан иң кирәк хисләрне таба белеп, аларны язгы ташкыннар сыман ургыта белүче олы сүз остасы дип әйтсәк тә була. Шуңа күрә, аның тормышын, иҗатын алга таба да өйрәнергә кирәк дип саныйм.

Дибәҗә Каюм кызы Каюмова 1934 елның 22 ноябрендә Актаныш районының Агыйдел буенда урнашкан тыйнак һәм хезмәтчел халкы булган Тат. Ямалы авылында дөньяга килә. Дибәҗә апаның балачагы авыр сугыш елларына туры килә. «Ул ачлыкта үткән еллар авыр, әмма сабый чаклар ачы сагыну белән сагындыра», – дип яза ул «Унбер кыз, унбер малай» әсәрендә[4; 10] Шул сагыну, ачы юксыну белән сугарылган әсәрендә елларның авырлыгы язылган юллар аша гына тоясың. Дибәҗә апа «дөньяның иң җылы болыннарга–күлләргә бай бер почмагы» – туган авылын тасвирлый, дус, бердәм, уртак фикерле классташларын искә ала, күңел төбендә онытылмаслык булып уелып калган кайбер вакыйгаларны искә төшерә. Алар барысы да тормышчаң, табигый, су буенда самовар чистарту, Сөтлә атавында гөлҗимеш җыюлар, аны кул арбасы белән ташу – болар барысы да сугыш чоры баласының башыннан узган хәлләр.

Ямалыдан Минзәләгә хәтле 55 чакрым юлны, Дибәҗә апа, яттан сөйләп бирә ала иде: кайдан кайда хәтле такыр, кайда чирәм, кайда саз – барысы да аның хәтерендә яхшы сакланган.

Төрлесе булды юлларның
Комлысы да, ташлысы да,
Төрлечә төште йөземә
Кояшның яктысы да.
Төрлесе булды суларның –
Кичеп чыкмаслыклары,
Бик текә биек ярлары –
Күңелдә әле бары.

Зирәклеге, тырышлыгы педагогия училищесында укуны җиңеләйтә. Студент елларында ук җирле матбугатта языша башлый. Шигырьләр һәм көй язу белән мавыга. Училищены бик яхшы билгеләргә тәмамлап, кулына диплом алып, Актаныш районы, Солтангол авылына укытучы булып кайта. Бераз эшләгәннән соң, ул Алабуга педагогия институтына укырга керә һәм, аны тәмамлап, утыз ел буе гаять культуралы, сокланырлык кешеләр белән кулга–кул тотынып мәдәният училищесында эшли. “Алар арасында мин матди яктан түгел, рухи яктан баедым. Артка калмаска, күп укырга, күп эшләргә туры килде. Гомерем буе дөреслек, хаклык эзләдем, хаксызлыклар

күрсәм,рәнҗедем. Каләм алып, ак кәгазьгә үз фикеремне төшерергә омтылуны бик яшьли сизсәм дә, ныклап торып яза башлавым алтмышынчы елларга туры килә. Ул елларда язган кайбер әйберләрем укучыларга таныш, ә берничәсе кәгазе саргаеп, үз вакытын көтеп ята бирә. Актив хезмәт юлында арып–талчыгып, кеше пенсиягә чыга һәм ваемсызлана. Мин менә шул ваемсызлыктан, ялгызлыктан качарга омтылып, күңел төпкелләрен актарып мөмкин кадәр язарга тырышам,”– дип яза ул үзе турында.[4;4]

“Алабуга нуры” газетасы ачылгач, тәрбия, дин, әхлак, милли мәсьәләләргә кагылышлы мәкаләләре дөнья күрә.

Шигырьләре һәм бер– бер артлы хикәяләре нәшер ителә. Укытучы халкының сәгате – минуты бүленгән була. Шулай да ул иҗатка вакыт таба. Шигырьләре матур, шома язылган, бик рәхәт һәм җиңел укыла. Аларны укыганда, тирән кичерешләр белән очрашасың: үзең дә сизмәстән, горурлану, тантана итү, ышану, өметләнү, юксыну, ярату, сагыну һ.б. тойгылар ташкынына кушыласың. Дибәҗә Каюмова шигырьләренең тематикасы да бик бай. “Йөрәк серләрем” дип исемләнгән җыентыкка күз салыйк. Анда теркәлгән шигырьләрнең шактый күп темага ( “И каләм”, “Татар без”, “Туган йортым” һ.б.) бүленеп бирелүе дә шуның ачык мисалы. “Татар без” дигән темага язылган шигырьләрендә шагыйрә туган халкына дан җырлый. Гасырлар буе изелгән, ялкыннарда көйдерелгән, горурлыгын саклап калган, хезмәт сөйгән халкы белән горурлана.

Кайсыдыр бер борынгы шагыйрь «Кешене ярату − бу изге сәнгатьнең үзе» дип язган. Кайсы гына матур әдәбиятны алсаң да, аның тәэсир көче, тәрбия йогынтысы нәкъ менә шул әдипнең тормышына, кешеләргә карата хисләренә бәйле. Дибәҗә апаның да һәр әсәрендә бу олы хис чагылыш таба. Дибәҗә апа Каюмова укучыларны үзенең мавыктыргыч хикәя һәм повестьлары белән дә куандырды.

«Тормышны белеп, геройларны яратып, «җылы каләм» белән яза», − ди «Кыз бала» китабын укучыга тәкъдим итүче язучы Айдар Хәлим. Чынлап та, китапның кайсы гына хикәясен, повестен алма, һәркайсы күңел түренә үтеп керә, ниндидер җылы хисләр уята, уйландыра.

Китапның төп әсәре − «Кыз бала» повесте. Авыр язмыш сынавына дучар булган тыйнак, акыллы Раиләнең үз бәхетен табу юлын тасвирлый Дибәҗә апа. Үзенә генә хас осталык белән, тормышчан ситуацияләр аша бай телен эшкә җигә. Кыз бала, хатын–кыз язмышы, намусы Дибәҗә апаның бүтән әсәрләрендә дә чагылыш тапкан.

«Тәүбә» беренче карашка гадәти тормыш ситуациясен тасвирлый. Ир − анасын кабул итмәгән, үз баласы–анасыннан баш тарта. Әмма тормышка мәхәббәт хисе бу әсәрдә дә өстенлек ала, Әдилә белән Әнвәр соң булса да кавышалар.

«Өзелгән шомырт чәчәкләре» − Алабугада яшәгән, укыган, укыткан, Ватан сугышында гомере вакытсыз киселгән шагыйрь Хабра Рахман турында автобиографик повесть. «Хабра исән булса, татар поэзиясенә күп

нәрсә бирер иде», – дигән Сибгат Хәким. Бу хак. Чөнки бик тә сәләтле, интеллектуаль, кешелекле шагыйрьнең гомере 28 яшендә өзелә. Повестьны язу өчен Дибәҗә апага күп эзләнергә, уйланырга, күп кешеләр белән очрашырга туры килгән.

Автор "Буранлы юллар" повестенда да кеше бәгыренең иң тирән почмагына үтеп керерлек көчле сүзләр таба. Әсәрнең күп геройларыннан берсе – Бибиасма – тормыш юлында күпне күргән хатын.

Дибәҗә апаның иҗатына күзәтү ясаганнан соң, йомгаклап шуны әйтәсем килә: шигырьләрен, әсәрләрен төрле темаларга иҗат иткән. Лирик шигырьләрендә туган якны ратуга, аның белән горурлануга, туган якның матурлыгына соклануга, иген иккән кешеләрнең батырлыкларын җырлауга, хезмәттән ләззәт, тәм табып эшләүгә, шатлык хисләре кичерү, гомумән, авыл кешесенең табигать баласы булуына басым ясый. Шулай ук, сугыш фаҗигасе, сугыш китергән бәла–казалар турында да искәртә. Шагыйрә кешеләр язмышы, илдәге үзгәрешләргә, телгә дә битараф түгел. Аның һәр әсәре, шигыре аша туган илгә, авылга, табигатькә, бер–беребезгә карата, бигрәктә,аналарга карата миһербанлы, кешелекле, изге күңелле, шәфкатьле булып яшәргә өнди. Аларда туган як, җир, авыл; хезмәт; бәйрәмнәр; табигать байлыклары, кошлар, хайваннар, үсемлекләр, экология темалары берләшә . Мондый тематик төрлелек безгә тәсир итеп кенә калмый, туры юлдан барырга ярдәм итә. Әсәрләре аша җиткерелгән төп идея, биргән үгет–нәсыйхәте тәрбияви яктан зур кыйммәткә ия.

Йомгаклап шуны әйтәсебез килә., аның иҗаты белән горурланабыз, алга таба да кызыксынып аның башка әсәрләрен дә тикшерербез дип уйлыйбыз...

**Әдәбият**


1. Гардисламова С. Һәрчак эзлим җылы, якты сүзләр, дәваларга йөрәк ярасын. // Алабуга Нуры. – 2014. – 10 окт.

2. Гыйльметдинова С. Шомырт чәчәкләре, һай, өзелгән. //Алабуга Нуры. – 1997. – 23 окт.

3. Дадина Ш. Агыйдел кызы мин: Язучы, шагыйрә Дибәҗә Каюмовага – 70 яшь // Алабуга Нуры. – 2004. – 24 ноябрь.

4.Каюмова Д. Кыз бала. – Яр Чаллы: Хәерле иртә нәшрияты, 1997. – 160 б.

5.Каюмова Д.К. Буранлы юллар. – Казан: Рухият нәшрияты , 2004. – 145б.

# ТАТАР ХАЛЫК ҖЫРЛАРЫН МӘКТӘПТӘ ЭЛЕКТРОН РЕСУРСЛАР КУЛЛАНЫП ӨЙРӘТҮ

Нәбиуллина А.Р.,
КФУның Адабуга институты студенты.
Фәнни җитәкче: Хәйруллина Ә.С.

Җыр – борынгыдан килеп, халкыбызның уй–хисләрен, теләк–омтылышларын, борчу-кайгыларын үзендә туплаган һәм аларны киләчәк буынга җиткерүдә зур роль уйнаган музыкаль-поэтик жанр. Урта мәктәптә әдәбият дәресләрендә халык җырлары фольклор жанры буларак алтынчы сыйныфта өйрәнелә. Җырларны өйрәнүдә электрон ресурсларга мөрәҗәгать итүнең максатчанлыгы ким дигәндә ике фактор белән аңлатыла. Беренчедән, дәреслек бары җыр текстын тәкъдим итә, әмма укучыларга аны көй, моң буларак ишетү, халык мәдәниятенә якынаю әһәмияткә ия. Моның өчен Интернет–челтәрендә урын алган видео, аудиоязмалар әһәмияткә ия. Мәсәлән, “Татар җыры” сайтында бик күп җырларның аудиоязмаларын тыңларга була [Татар җырлары интернет–ресурс]. Икенчедән, электрон ресурсларны куллану – заман таләбе дә әле ул, белгечләр ассызыклавы буенча, “бүгенге көндә мәгариф өлкәсендә дәүләт сәясәтенең мөһим бурычларының берсе булып белем бирүне мәгълүматлаштыру, цифрлы белем бирү ресурсларын куллану мөмкинлекләрен ачу, укытучыларны электрон, цифрлы ресурслар булдыруга мотивлаштыру булып тора”[Фиофанова интернет–ресурс]. Әйткәнебезчә, җырларны өйрәнүдә әдәбият дәресләрендә мондый ресурсларның кыйммәте тагын да арта.

Татар халык авыз иҗатының бер төре буларак җырларны өйрәнүдә электрон ресурсларны куллануны берничә юнәлештә тормышка ашырырга була. Беренче юнәлеш – өйрәнелә торган халык җырын язмада тыңлау, моның әһәмияте югарырак ассызыкланды.

Икенче юнәлеш – дәреслектәге биремнәрне башкару өчен, интернет–чыганакларга мөрәҗәгать итү. Мәсәлән, түбәндәге бирем алтынчы сыйныфта җыр темасын өйрәнү дәресендә тәкъдим ителә:

–“Татар җыры җырлап кына сугышта исән калган солдат турында З.Хәкимнең “Телсез күке” исемле драмасы бар.Аны карарга тырышыгыз” [Хәсәнова 2017: 8].

Өченче юнәлеш җырга багышланган махсус тапшырулар белән эшне үз эченә ала. Укытучы сыйныфта сәләтле яки темага карата аеруча кызыксыну күрсәткән балаларны барлап, аларның омтылышлары үсеше өчен шартлар тудырырга тиеш. Халык җырларын өйрәнүдә моның өчен “Тәртип” радиосы тапшыруларыннан файдаланырга була [Тәртип радиосы интернет–ресурс]. Бишенче сыйныфта бишек җырлары турында әңгәмә оештырганда, мондый укучы радиодагы “Халык ядкарьләре” тапшыруларының “Бишек җырлары” дигән чыгарылышны тыңлап, чыгыш ясый ала. Алтынчы сыйныфта “Халык җырлары” темасын өйрәнүдә мондый бирем урын ала:

–“Интернеттан җырчы Рәшит Ваһапов турындагы материаллар белән танышыгыз” [Хәсәнова 2017: 7].

Биремне башкару өчен, укучылар “Кабатланмас моңнар” тапшыруының Р.Ваһаповка багышланган чыгарылышын куллана ала.

Нәтиҗә ясыйк: җырларны халык авыз иҗаты жанры буларак өйрәнүдә электрон ресурсларның роле зур. Мәкаләдә аларның кайбер төрләре, кайбер актуаль чыганаклар (“Татар җырлары” сайты, “Тәртип” радиосы һ.б.) аталды. Әлбәттә, иҗади укытучы бу юнәлештә тагын да эзләнү һәм табышларга ия була.

**Әдәбият**


1. Татар җырлары. – URL:https://erlar.ru; мөрәҗәгать итү вакыты: 19.10.2023.
2. Тәртип радиосы. – URL: https://tartip.tatar/news/rubric/list/programmy; мөрәҗәгать итү вакыты: 19.10.2023.
3. Фиофанова К.А. Электронные образовательные ресурсы и сервисы для уроков литературы (проект LITFUN). – URL:https://cyberleninka.ru/article/n/elektronnye–obrazovatelnye–resursy–i–servisy–dlya–urokov–literatury–proekt–litfun; мөрәҗәгать итү вакыты: 19.10.2023.
4. Хәсәнова Ф.Ф., Сафиуллина Г.М., Гарифуллина М.Я. Татар әдәбияты: 6 нчы сыйныф: рус телендә гомуми белем бирү оешмалары өчен уку әсбабы. 2 нче кис. – Казан: Мәгариф – Вакыт, 2017. – 111 б.


## МӘКТӘПТӘ ИҖАДИ ҮСЕШ ТЕХНОЛОГИЯСЕНӘ НИГЕЗЛӘНЕП “ИСЕМ” ТЕМАСЫН ӨЙРӘНҮ


Нәбиуллина А.Р. ,
КФУның Адабуга институты студенты.
Фәнни җитәкче: Хәйруллина Ә.С.


Бүгенге көндә мәктәпләрдә актив кулланыла торган технологияләрнең берсе булып иҗади үсеш технологиясе тора. Укучыларны иҗади үстерү юлларын эзләүгә атаклы педагог В.В. Давыдов мәктәбенең вәкиле булган профессор, психология фәннәре докторы Ә.З. Рәхимов зур өлеш кертә. Аның тырышлыгы белән 1975 нче елда Башкорт дәүләт педагогика институтында педагогик технология лабораториясе ачыла. Бу технология уку–укыту эшчәнлегенең индивидуаль һәм күмәк формалары ситуациясендә укучыларның танып белү сәләтләре формалашу һәм иҗади мөстәкыйльлекләре үсү, нәтиҗәдә иҗади фикер йөртү, үзбелем һәм үзтәрбиягә мотивация үсешенә йөз тота [Иҗади үсеш технологиясе 2004: 49]. Ә.З. Рәхимов иҗади үсеш технологиясе турында болай ди: “Бу – мин уйлап тапкан технология түгел. Миңа башта бик күп халыкларның педагогикасы һәм психологиясе эчендә “йөзәргә” туры килде. Мин һәр методиканың, сөтнең каймагын җыйган кебек, иң нәтиҗәлеләрен генә сайлап алырга тырыштым. Шуңа күрә, иҗади үсеш технологиясен иң яхшы дип

әйтә алам” [Җамалетдинова 2003: 56]. Иҗади үсеш технологиясенә нигезләнгән дәресләрнең структур төзелеше традицион дәрес калыпларыннан аерылып тора. Аның төп этаплары:

- мотивацион–ориентлашу этабы (ун минут);
- башкару этабы (утыз минут);
- рефлексия–бәяләү этабы (биш минут) [Буданова 2005: 29].

Әлеге технологиягә нигезләнгән эшне оештыру үзенчәлекләрен “Исемнәрнең килеш белән төрләнеше” темасын өйрәнү мисалында карап китик. Дәреснең беренче этабы – мотивлаштыру–ориентлаштыру этабында укучыларның “Исемнәрнең берлек һәм күплек сан формалары” темасы буенча өй эшен эшләүләре тикшерелә. Дәреснең башкару этабында дәреслек буенча эш алып барыла. Укучыларга дәреслектәге 39 нчы күнегү буенча эшләргә тәкъдим ителә. Укучылар башлангыч сыйныфларда үтелгән мәгълүматны искә төшереп, дәреслек авторларының таләбе буенча күнегү тексты герое Азатка ярдәмгә килеп, татар телендә нинди килешләр барлыгын әйтергә, исемнең кайсы килеш белән төрләнгәнен ничек белеп булганлыгын әйтергә тиеш булалар [Сәгъдиева 2017: 23].

Әлеге этапта этапта укытучы үзе төзегән биремнәрне дә тәкъдим итә ала. Мәсәлән, ул сюжетлы картиналар белән эш булырга мөмкин. Укучыларга сюжетлы картиналар тәкъдим ителә. Без аларны “Бала.рф” китапханәсеннән алырга тәкъдим итәбез. Укучылар рәсемнәргә карап текст язалар. Грамматик бирем башкаралар (мәсәлән, иялек килешендәге исемнәрне билгеләгез). Бирем өстендә эш интерактив мультфильм карау белән дәвам итә. Мәсәлән, Нур Әхмәдиевнең “Басмада” шигыре буенча эшләнгән мультфильмга нигезләнеп ясалган рәсемнәрне кулланырга була [Интерактив китапханә, интернет–ресурс]. Мондый эшнең уңышлы яклары шунда: сюжетлы рәсемнәр белән эшләү укучыларның иҗади фикерләвен үстерә, логик эзлекле итеп мөстәкыйль текст төзү күнекмәләрен үстерә. Үзләренең текстлары оригиналь текст белән туры килү–килмәве дә укучыларга кызык. Грамматик бирем дәрес темасына ярашлы рәвештә тәкъдим ителә. Ул түбәндәгечә яңгырый ала:

- текстагы исемнәрнең килешләрен билгеләгез;
- төшем килешендәге исемнәрне билгеләгез һ.б.лар.

Дәреснең рефлексия–бәяләү этабында укучылар дәрестә эш дәвамында алган яңалыклар турында сүз алып барыла. Яңа мәгълүмат кычкырып та, төркем эчендә дә, эчтән генә дә кабатлана ала. Укытучы шулай ук дәреснең уңышлы һәм уңышсыз тоелган яклары турында да сораштырырга мөмкин. Әлеге этаптагы тагын бер җаваплы мизгел – укучыларның үзләренең эшчәнлекләрен бәяләүләре. Дәрес дәвамында укучылар һәр башкарган эшләрен бәяләп баралар, бәяләү критерийлары аларга таныш – җавапның дөреслеге, тизлеге, җавап телдән яңгыратылса, сөйләмнең сөйләм культурасы таләпләренә ярашлы рәвештә бирелүе һ.б.лар. Дәрес ахырында исә төп бәя чыгарыла. Укучыларның психологик үзенчәлекләрендә аерма булырга мөмкин. Кемдер дәрестә бирелгән бер дөрес җавабына куанып, үзен югары бәяли, кемдер,

киресенчә, үзенә карата артык таләпчән була ала. Шуңа күрә, мөгаллим искә төшерә: билгене артык түбәнәйтү дә, хаксыз югары билге кую да объективлыкка зарар китерә, белем алу юлында киртә генә булып тора. Укучыларның эшчәнлеге бәяләнгәч, өй эше бирелә.

Нәтиҗә ясап, шуны әйтергә кирәк: иҗади үсеш технологиясе заман мәктәбенә уңышлы үтеп керә, бу өлкәдә шактый ук тәҗрибә дә туплана. Татар теле укытучылары әлеге технологияне кулланып, яңа дәрес эшкәртмәләре төзи һәм методик тәкъдимнәр, шул җөмләдән "Исем" темасын өйрәнү буенча тәкъдимнәр кертә алалар.

**Әдәбият**


1. Буданова Р. Иҗади үсешкә омтылып // Мәгариф. – 2005. – №9. – Б. 29 – 31.
2. Җамалетдинова З. Иҗади үсеш технологиясе // Мәгариф. – 2003. – №8. – Б. 56 – 57.
3. Иҗади үсеш технологиясе. "Түгәрәк өстәл" янында сөйләшү // Мәгариф. – 2004. – №5. – Б. 49 – 50.
4. Интерактив китапханә. – URL: http://www.бала.рф/ipad/library.html?id=101; мөрәҗәгать итү вакыты: 27.10.2023.
5. Сәгъдиева Р.К., Гарәпшина Р.М., Хәйруллина Г.И. Татар теле: рус телендә төп гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен) 6 нчы сыйныф. – Казан: "Мәгариф – Вакыт" нәшр., 2017. – 191 б.


## Г. САБИТОВНЫҢ "ЯРСУЛЫ ЯЗ" ӘСӘРЕНДӘ КҮЧЕРЕЛМӘ МӘГЪНӘГӘ БӘЙЛӘНЕШЛЕ СУРӘТЛӘҮ ЧАРАЛАРЫ.


Нәҗметдинова А.Г.,

Алабуга районының Иске Юраш мәктәбе укучысы.

Фәнни җитәкче: Гайнетдинова К.Ф.


Тел – халыкның яшәү ысулы, гореф – гадәтен, дөньяга карашын, фәлсәфәсен, тарихын, кыскасы, бөтен күңел байлыгын күп гасырлар буена үзенә сеңдереп барып, аны безнең заманнарга китереп җиткергән чиксез зур хәзинә. Шуңа күрә нәфис сүз сәнгате үсешенә үз телен тудыручы, иҗат итүче, үс– терүче, камилләштерүче халык та, ул телнең матурлыгын, культурасын, бай– лыгын фәнни нигездә тикшерүче галимнәр дә, язучылар да даими рәвештә игътибар үзәгендә тота. Шуңа бәйле рәвештә язучыларның образлы телен, индивидуаль стилен өйрәнүгә дә зур әһәмият бирелә.

Сүз сәнгате остасы булу дәрәҗәсенә күтәрелгән язучыларыбыз шактый. Шундыйларның берсе – Габделхәй Сабитов.Г.Сабитовның әсәрләре, бигрәк тә хикәяләре, сәнгатьчә эшләнеше һәм идея – эстетик яктан югары сыйфатлы булулары белән аерылып тора.

Г. Сабитовның язучы буларак иҗат йөзен ачкан һәм аны оста хикәяче, өметле драматург итеп таныткан әсәрләре илленче елларның ахырына һәм алтмышынчы елларга туры килә. Бу чорда ул республика көндәлек матбу–гатында «Туган җир туфрагы», «Агач аяклы кеше», «Өч күңел», «Корбан ашы», «Сәйлүн чәе», «Урман кызы», «Үлемсез Акылгали» кебек, халыкчан матур тел белән, кызыклы, табигый сюжетларга корып язылган хикәяләрен, әкиятләрен бастыра, «Кичерелмәс гөнаһ» исемле драмасы белән профессиональ театр сәхнәсенә менә. 1963–1964 елларда исә хикәяләре һәм әкиятләре тупланган ике җыентыгы дөнья күрә. Бу язучыны мин үзем балалар язучысы буларак хөрмәт итәм.

Әдәби әсәрдә сүз төп төзү материалы булып хезмәт итә. Һәр сүзнең үз төсмере бар сыман. Ул төсмер, беренчедән, сүзне нинди сөйләм төрендә күбрәк кулланылуына, икенчедән, нинди өстәмә мәгънә яки тойгы белдерүенә кайтып кала.Төзү материалларыннан иркен файдалану өчен, язучыдан тел байлыгын бөтен тулылыгында үзләштерү сорала. Бу – әдәбиятның чынбарлыкны яктырту, иңләү мөмкинлеген бик нык киңәйтә. Шул ук вакытта һәрбер язучы төзү материалының югары сыйфатлылыгына омтыла. Аның затлылыгы һәр күренеш өчен сүзнең бердәнберен, иң төгәлен, үтемлесен сайлап алуда күренә.Төзү материалының затлылыгы бөтен әсәрнең сыйфатын, йөзен билгели.

Бу хезмәтемдә мин Г. Сабитовның мәктәп программасына кертелгән (7–сыйныф әдәбияты,78–83 битләр) “Ярсулы яз” әсәрендә күчерелмә мәгънәгә бәйләнешле сурәтләү чараларын өйрәнүне максат итеп куйдым.

Күчерелмә мәгънә – һәрбер милли телдә үзенчәлекле күренеш. Ул – шул тел иясе булган халыкның тормыш – көнкүреш үзенчәлекләренә, аның тарихына, гореф – гадәтләренә һәм, әлбәттә, телнең үсешенә бәйле.

Г. Сабитовның әлеге әсәрендә троплар искиткеч актив кулланылыш тапкан. Шуларның берсе – чагыштыру. Чагыштыру – сүзне күчерелмә мәгънәдә куллануның иң гади һәм иркен кулланыла торган төре. Бу сурәтләү чарасын эченә алган әйтелмә ике кисәктән – чагыштырылган әйберне (күренешне) белдергән сүз һәм чагыштыру өчен файдаланылган әйбер исеменнән – тора. Чагыштыру – әдәбиятта киң таралган алымнарның берсе. Аерым билгеләре буенча әйберләрне һәм күренешләрне бер – берсе белән тиңләштерү, тәңгәл кую һәм аларның охшаш якларын күрсәтү чагыштыру алымының нигезендә ята.

Г.Сабитов әсәрендә чагыштыру *кебек, сыман, шикелле бәйлекләре;әйтер– сең лә* рәвешендәге теркәгеч сүзләр; *–дай, –дәй аффикслары* ярдәмендә белде– реләләр. Әсәрдә кулланылган чагыштыруларны берничә төргә бүлеп карарга мөмкин.

1.Чынбарлыктагы җансыз предметларның, күренешләрнең бер – берсе белән чагыштырылуы. Мәсәлән, *... кояш парта өстен кызган табадай кыздыра,( 7 кл. 78 б.), өй буенда алар тамган урында карлар чәйдә эрегән кебек суланып – саргаеп ята (81 б.),.. ә бигрәк тә әлеге шул уенчыктай җиңел ак читекләре!*

2. Җанлы һәм җансыз күренешләрне чагыштыру. Бу очракта кешеләр һәм аларның холкы, гадәте,эше җансыз әйберләр белән тиңләштерелә. Мәсәлән, ... *Әниләренең әле уң, әле сул ягына чыгып, кызган табага баскандай, каударлананалар, башлары белән төртә–төртә, комсызланып суыралар(81 б.),... бөеренә таянды да,кечкенә генә ап–ак итек читекләре белән юеш кар чәчрәтеп, бөтерчектәй бөтерелеп куйды, кыбырсык.*

3. Бер предмет белән икенче предметны, зат белән затны чагыштыру. Мәсәлән,... *Галләм абый әйткәндәй, ярый, хуп! Бәйрәм ашы–кара каршы булмагае!... Ул койрыклар дисәң, күз ирмәс тизлек белән, бөдрә камчыдай бөтерелеп–уйнаклап тора. Шулкадәр дә тәмле микәнни соң ул ана сөте; ... Шундый озын, шундый куелар (керфекләр),әйтерсең аерым бөртекләр түгел,ә тоташтан кара элпәләр–, (83 б.) кара күбәләк канатлары... ,...хәтта күзләреннән яшьләр чыгып, "кара күбәләкләре" чыкланды.*

4. Хайваннар, кошлар белән чагыштыру. Мәсәлән, *Җиргә төшкән чыпчыкны эләктерергә тырнак чарлап торганда,чынчык очып киткәч, мәче баласы ничек караса, Гамил кулындагы дәфтәргә шулай карап калды Гөлүсә (79 б.), ...нәрсә, җим көткән чебеш кебек, күзләреңне ялтыратып торасың, ...аның кыяфәте дә һаман да әлеге шук мәчене хәтерләтә (79 б),... Тик хәзер чыпчык аулаган чагы түгел, башына әбәк–чәбәк төшкәч, колагын шомартып, муенын җыерган чагы. Борынын дәфтәргә төрткән дә мәсьәлә чишә. (81 б.), ... әйтерсең лә ак бәкәлле колын! (Гөлүсә),...көлеп арыгач, кар йомарлап, Гамилнең башына тондырды да ак бәкәлле колын кебек сикерә–сикерә китеп барды (83б.)*

Күчерелмә мәгънәле сүзләрнең икенче төре – метафоралар. Метафора – ул, предметларның яки күренешләрнең нинди дә булса охшаш якларына нигезләнеп, сүзләрдәге мәгънәне күчерү. Авторлары бер төркем галимнәр (Д.Ф.Заһидуллина, Ә.М. Закирҗанов, Т.Җ.Гыйләҗев, Н.М.Йосыпова) булган "Әдәбият теориясе" китабында аңа түбәндәгечә билгеләмә бирелә: " Күренешләрнең охшашлыгына яки каршылыгына нигезләнгән яшерен чагыштыру".

Ә Фәрит Хатипов үзенең "Әдәбият теориясе" дәреслек – кулланмасында: "Күренеш, гамәл сыйфатларны үз исеме белән әйтмичә, икенче сүз белән белдерү метафора була,"– ди.

Вахит Хаковның фикере югарыда бер төркем язучылар фикере белән тәңгәл килә.

Метафоралар үзләренең җыйнак һәм кыска бирелүләре белән аерылып торалар. Анда чагыштырудагы кебек бәйләгеч чаралар юк. Г. Сабитов әсәрендә бигрәк тә исемнәрнең күчерелмә мәгънәләре еш очрый. Әсәрдә метафораларның төрле формалары актив кулланылышта. Кайберләрен карап китик.

1.Әйберләрнең форма ягыннан охшашлыгына нигезләнгән метафоралар:*әллә нинди булды быелгы яз. Елдагыдан үзгә соңарып – сагындырып килде дә, март ахырларында кинәт ярсынып, изүләрен чишеп җибәрде; ... уяна дөнья, елмаеп, көлеп уяна(78 б.),*

2.Эчке һәм тышкы охшашлыкка нигезләнгән метафоралар: *бармак изәп тышка чакыра, тел күрсәтеп үчекли (кояш), хаталарын Галләм абый чүпләсен диденме әллә?..., күпер төбендә кар яна, ...бер өтерөңне карга чукыган,... күзлек өстеннән сөзеп карады, ...дәфтәр өстендә каләмен уйнатып торды,...Әрсез кояш тәрәзәдән кереп, өй эчен тутырган. Өстәлдәге самовыр, капкачыннан чагылып,түшәмгә үк менеп кунаклаган, ... Әмма бүген кояшы гына түгел, бар дөньясы каныкты малайга (80 б.),...Гамил тәмам бөрешеп калды,...хәтта ике тәрәзә арасында кышның кыш буе хәрәкәтсез яткан күбәләккә дә яз кояшы җан өргән..., Табигать уянганын сизеп,болай гына,йокы аралаш кына талпынуыдыр.*

Әсәрдә шулай ук халык афоризмнарыннан шактый гына мәкаль–әйтемнәр, фразеологизмнар да урын алган. Мәсәлән, *Ә Гөлүсә һавадан тургай санап йөри,.. җитмәсә әле, канга тоз салып такмаклап тора;...ашыккан ашка пешкән, бозлы тозакка төшкә;,...авыз ачып торшан арад;,... көлең күккә оча; ... кешегә чокыр казысаң, үзең төшәрсең; ...бәла аяк астында һ.б.*

Шуай итеп, Г.Сабитов әсәрендә кулланылган троплар әсәр стиленә сәнгатьлелек бирүдә, авторга үз фикерен ачыграк җиткерүдә бик әһәмиятле роль уйныйлар. Алар шулай ук образларны, вакыйгаларны тулырак ачарга ярдәм итәләр. Ул гына түгел, шундый сүрәтләү чараларына бай булган әсәрләрне без, укучыларга укуы да кызыклы. Алар үтемле дә, укучы күңеленә бик тиз барып та җитә, кайберләре күңел сандыгында гомерлеккә сакланып кала. Димәк, укучының сүз байлыгы арта, күңел дөньясы байый.

Шуларның бөтенесен күздә тотып, без татар теле укытучысы Клара Фёдоровна белән 7 – 8 – сыйныф укучылары белән китап укучылар конфе–ренциясе үткәреп карарга булдык. Конференция үткәргәннән соң, бу әсәргә рецензияләр яздырдык, анкеталар үткәрдек. Нәтиҗәдә, 90% укучы әсәрне яратып укыган булып чыкты. Иң кызыгы: алар хикәядәге афоризмнарны хәтерләрендә калдырганнар. Әсәр хәтта мәктәбебездә укучы рус балаларының күңеленә дә хуш килгән. Алар да ярыша – ярыша әсәр турында үз фикерләрен әйттеләр.

Нәтиҗә ясап, шуны әйтәсе килә: әсәрләрдә тел –сурәтләу чаралары күбрәк кулланылган саен, язучылар үзләренең укучыларын арттыра баралар.

**Әдәбият**

1. Абдуллина Д.М. Әдәбият дәреслеге – Казан: Татар. кит. нәшр.,, 2014–78–83б;

2. Галиуллина Г.Р.Татар теле. Лексикология – Казан: Мәгариф,2007–57–60 б;

3. Миңнуллин К.М.Халык афоризмнары – Казан: Мәгариф, 2002–2-9б;

4. Заһидуллина Д.Ф, Закирҗанов Ә.М.Гыйләҗев Т.Ш, Йосыпова Н.М. Әдәбият теориясе, 2004–40-41б;

5. Хаков В. Тел–тарих көзгесе — Казан: Татар. кит. нәшр.,, 2003–93-124 б;

# ГАЛИАСКАР КАМАЛ – ИЗВЕСТНЫЙ ПИСАТЕЛЬ, КЛАССИК, ДРАМАТУРГ, ОБЩЕСТВЕННЫЙ ДЕЯТЕЛЬ

Нуриева Д.Р.,
ученица 8 «Б» класса ОШ «Университетская»,.Научный руководитель:
Сахабиева Г.Х.

Литературно–драматургическая деятельность ГалиаскараКамала началась задолго до того момента, как зародился татарский театр. Именно по этой причине его считают отцом драматургии Татарстана. Он стал автором многих оригинальных пьес, занимался переводом с русского и турецкого языков.

Родился Галиаскар Галиакбарович Камалетдинов в Казани 6 января 1879 года. Жили они достаточно скромно. Детские годы Галиаскара прошли в родной деревушке его матери под названием Нижняя Марса. Подросшего Галиаскара отдали на обучение сразу в казанское медресе «Госмания», потом он продолжил учиться в медресе «Мухаммадия». Русский язык он освоил самостоятельно, ему очень нравилась русская драматургия, театр. Камал связал свою жизнь с литературно–художественной деятельностью.

Творческая биография будущего известного писателя началась в 1898 году с произведения, получившего название «Несчастный юноша».

В 1907–м вышла вторая редакция этого сочинения. В произведении Галиаскар касался социальных вопросов и просветительских идей.

В 1906 году вышел первый номер газеты «Азат» (Свобода), чуть позже начала издаваться газета «Азат халык» (Свободный народ)[2].

В 1908 году появились первые выпускии журнала под названием «Яшен» (Молния). Помощь в выпуске этого издания Камал получил от поэта Габдуллы Тукая.

Еще в юности увлекшись театром, Галиаскар Камал пронес эту любовь к сцене на протяжении всей своей жизни. Он занимался пропагандой театрального дела, принимал непосредственное участие в постановке первого спектакля, который публика смогла оценить в 1906 году.

Спектакли ставились по его произведениям, пропитанным реализмом, актуальными вопросами, поднимающими злободневные темы и раскрывающие характеры его героев настолько реалистично, что они становились узнаваемыми.

На смену юношеским просветительским идеям постепенно пришли совсем другие темы. Писатель высмеивал необразованность, социальные устои и существующий режим. В сатирических комедиях ГалиаскараКамала описывались ситуации, рожденные ненавистным ему миром. Основываясь на реальных случаях, писатель наполнял свои комедии легко узнаваемыми персонажами.

В 1908–м театр представил на суд зрителей и критиков комедию «Первое представление». В 1912–м состоялась премьера спектакля под названием

«Тайны нашего народа». Вслед за ней поставили пьесу «Банкрот», где автор показывает изнанку того времени строя, невозможность честно нажить большие деньги, что бы там не утверждали по этому поводу представители буржуазии[1].

Произведения Камала ставились в татарских театрах, с ними с удовольствием работали режиссеры и актеры тех лет. У писателя появилось множество единомышленников, которые поддерживали его в том, чтобы развивать сценический жанр, как средство воспитания зрителя и возможности познакомить публику с мировой классической литературой.

Галиаскар Камал занялся переводами, и в репертуаре театра постепенно появлялись спектакли по произведениям русских классиков – Островского, Горького, Гоголя.

Писатель вступил в Красноармейскую татарскую группу, отличался активной гражданской позицией. В то время он взял псевдоним – «Аула и компания», под которым выходила его сатирическая проза. Рабочим и крестьянам она пришлась по душе.

В 1921–м вышла еще одна пьеса писателя – «Милая Хафиза». В 1923 году ГалиаскаруКамалу было присвоено звание Героя Труда, а в 1926 году – народного драматурга.

Однако не только литературная и театральная деятельность были основными направлениями в жизни Камала. Писателя увлек рисунок и каллиграфия. Он написал многочисленные изображения на социально–политическую тему. По роду своей деятельности Галиаскару приходилось сотрудничать с типографиями многих издательств, и он пытался модернизировать татарскую каллиграфию. Помимо этого, драматург принимал самое активное участие в подготовке спектаклей в театре, на нем лежала ответственность за художественно–постановочную часть и оформление.

Настоящая дата рождения татарского театра 22 декабря 1906 года. Именно в это время на его сцене прошли два спектакля на татарском языке – «Беда из–за любви» и «Жалкое дитя». Самую большую популярность приобрел спектакль Камала «Банкрот».

Однажды Габдулла Тукай, Ибрагим Кулиев и ГалиаскарКамал рассматривали афиши, только что привезенные из типографии. Тукай заметил, что прежнее название труппы слишком длинное. Было решено придумать что–то покороче. Сравнив постоянно странствующих артистов со звездой, Габдулла предложил: «Сэярлэр». Камал решил обрубить окончание, и получилось ныне всем известное «Саяр». Такой вариант артисты встретили аплодисментами.

В 1926 году театр получил звание академического. В 40–е годы репертуар театра состоит из русской классики и переводных зарубежных пьес. В 1939 году, в честь 60–летия ГалиаскараКамала, театру присваивают его имя.

У ГалиаскараКамала сложилась не только профессиональная карьера, но и личная жизнь. Он женился на дочь богатого казанского купца по имени СадыкХайбуллин.

Влюбленные поженились в 1900 году. В качестве приданного новоиспеченная жена писателя получила шикарный дом на улице Нариманова.

У писателя было два официальных брака. Второй раз он женился на девушке, которую звали Асма. ГалиаскарКамал оставил после себя многочисленных наследников – пять сыновей и одну дочку.

Сердце известного татарского драматурга перестало биться 8 июня 1933 года.

Именем писателя названы улицы в больших городах – Казани, Набережных Челнах, Елабуге. В нашем городе есть и остановка имени ГалиаскараКамала. Татарскому академическому театру в Казани присвоено имя ГалиаскараКамала.

**Литература**

1. Хайбуллина О.А. Галиаскар Камал. –URL: https://kai.ru/web/naucno–tehniceskaa–biblioteka/6–anvara–2019–140–let–so–dna–rozdenia–galiaskara–kamala–prozaika–poeta–dramaturga–perevodcika–obsestvennogo–deatela–izdatela–redaktora?ysclid=lsnhjz7rjl542809878 (дата обращения: 09.02.2024).
2. Сафуанов И. Модернизация классики. Литературная Россия.2015. № 02. https://old.litrossia.ru/2015/02/09316.html (дата обращения: 08.02.2024)

## Г. КАМАЛНЫҢ “БАНКРОТ”ҺӘМ Н. В. ГОГОЛЬНЕҢ “ҮЛЕ ҖАННАР” ӘСӘРЛӘРЕНДӘ ӘХЛАКЫЙ КЫЙММӘТЛӘР

Сәхәбетдинова Ә.Б.,
КФУның Алабуга институты студенты.
Фәнни җитәкче: Габидуллина Ф.И.

Галиәсгар Камал (1879-1933) − татар әдәбияты классигы, танылган драматург, публицист, театр һәм җәмәгать эшлеклесе, Хезмәт Герое, ТАССРның халык драматургы.

Ул милли журналистикага һәм татар профессиональ театрына нигез салучыларның берсе була, сәнгатьтә мәгърифәтчелек традицияләрен дәвам итә.

Г. Камал күп кенә әсәрләр яза, шул исәптән «Беренче театр», «Бүләк өчен», «Банкрот», «Безнең шәһәрнең серләре» комедияләре. Шулай ук ул әдәби тәнкыйть һәм татар публицистикасын үстерү белән шөгыльләнә, Гоголь, Островский, Мольер, Габделхак Хәмид әсәрләрен тәрҗемә итә.

«Банкрот» (1911) − татар драматургиясе классигының иң уңышлы комедияләреннән берсе. Әсәрдә XX йөз башы татар сәүдәгәрләренең комсызлыклары, тискәре гадәтләре фаш ителә.

Комедиянең төп герое Сираҗетдин Туктагаев үзен банкрот дип игълан итәргә, аз гына түләп, бурычтан да котылырга, акчалы да булып калырга уйлый. Ләкин бурыч бирә торган фирманы җайлы гына алдап булмый. Шуңа күрә ул сирәк очрый торган афера уйлап таба. Банктан кырык тугыз мең сум акчаны

алып яшереп куя да, Мәскәүгә китә һәм поезда таланган, акылдан шашкан булып кылана. Фирма вәкилләре үзләре белән врач алып киләләр. Сираҗетдин врач кулына биш йөз сумны шыпырт кына бирә: врач моны сизеп ала һәм Сираҗетдинны коткару юлын таба. Нәтиҗәдә Сираҗетдин 108 мең сум табыш ала[2].

Николай Васильевич Гоголь (1809-1852) − рус әдәбияты классигы, язучы, драматург, публицист, тәнкыйтьче. Гогольнең иң танылган әсәрләре дип «Вечера на хуторе близ Диканьки» җыентыгын, шулай ук «Мертвые души» («Үле җаннар») дигән бөек әсәрне атарга мөмкин.

«Мертвые души» («Үле җаннар», 1835) − рус әдәбияты өчен иронияле прозаның үзенчәлекле эталонына әверелгән уникаль әсәр. Сюжетта үзен алпавыт итеп күрсәтүче Павел Иванович Чичиковның маҗаралары турында хикәяләнә.

Чичиков губернаның «NN шәһәре»нә килә һәм шәһәрдә яшәүче барлык “зур” кешеләрнең ышанычын яуларга тырыша. Герой балларда һәм төшке ашларда көтелгән кунак була. Шәһәрлеләр Чичиковның чын максатларын белмиләр. Аның максаты − үлгән крестьяннарны сатып алу яки түләүсез генә алу, алар җирле алпавытларда ревизия кәгазьләре буенча исән булып саналган, һәм аларны үз исеменә тере итеп рәсмиләштерү, соңыннан опекунлык Советына залог буларак тәкъдим итеп, зур акчалата кредит (ссуда) алу.

Чичиков теләсә нинди юллар белән баерга, югары социаль статуска ирешергә тырыша. Элек ул таможняда хезмәт иткән, ришвәт алыр өчен контрабандистларга товарларны чик аша каршылыксыз күчерергә рөхсәт иткән, әмма иптәше белән талашкач, дусты аның яманлыкларын фаш итә, шуннан соң ялган ачыла, икесе дә тикшерү астында кала. Ярдәмчесе төрмәгә эләгә, ә Чичиков, хәйләкәрлеген кулланып, ришвәт биреп, җәзадан кача , хәтта акчаның бер өлешен яшерә ала[4].

Гогольның Чичиковы да, Камалның Сираҗетдине дә үзләренең алдау һәм хәйләкәрлек осталыкларын акча эшләү өчен кулланалар, аларны матди байлыктан башка бернәрсә дә борчымый. Ике герой да әхлакый ориентирларын һәм рухи кыйммәтләрен югалталар, аларны байлык җыю теләге белән алыштыралар. Алар җәмгыятькә, үз халыкларына файда китерер урынга, буш, максатсыз һәм инфантиль яшәү образы алып баралар.

Әсәрләрдә кешенең акчага, байлыкка омтылуы, акча алдында кол булуы күрсәтелә, байлык өчен хәтта җинаять кылырга да әзер булуы ачыла. Сираҗетдиннәр, Чичиковлар җәмгыятендә бар нәрсәне сатып алып була, кешеләр түбән җанга әйләнгән, һәммә нәрсә күрәләтә алдауга корылган, тормыш законы булып әверелгән. Әдипләр әсәрләрендә, байлыкка табынып, кешеләрнең намус һәм вөҗдан төшенчәләрен югалту мөмкинлеген, җәмгыятьтә икейөзлелек, ялган, сатлыкҗанлык кебек сыйфатлар таралу турында кисәтә.

Г. Камал һәм Н. Гоголь үзләренең әсәрләрендә җәмгыятьнең төрле катламнары вәкилләрен сурәтләгәннәр. Чичиков − гади эшче, Сиражетдин − бай сәүдәгәр, ләкин аларның максатлары бер үк − мөмкин кадәр күбрәк акча

җыю, намуссыз, законсыз юллар белән байлык туплау. Ике герой да судан коры чыгу өчен кешеләрне алдаган каракләр.

Нәтиҗә ясап шуны әйтергә мөмкин: ике әсәрдә дә геройларның үз мәнфәгатьләрен генә кайгыртып яшәүләре, байлык өчен теләсә нинди адымга барырга әзер торулары аларны бер-берсенә якынайта, хәтта төп геройлар кабатлана кебек. Күпмедер дәрәҗәдә Камалның Сираҗетдин образы Гогольнең Чичиковының дәвамы булып тора кебек. Шул рәвешле, әлеге тискәре геройлар ярдәмендә ике драматург та һәр чорда очратырга мөмкин булган типик образлар ярдәмендә җәмгыятьнең әхлакый кыйммәтләргә мөнәсәбәтен сурәтләгән.

Г. Камалның “Банкрот”ы да, Н. В. Гогольнең “Үле җаннар”ы да тәнкыйди ирония һәм җиңел юмор белән язылганга күрә, әсәрләр укучы тарафыннан җиңел кабул ителә, һәр яңа буын укучысына үз нәтиҗәләрен ясарга мөмкинлек бирә.

**Әдәбият**

1. Г. Камал “Банкрот” URL: https://tugan-tel.tatar/adabiyat/dramaturgiya/Galiasgar_Kamal/bankrot.php [Мөрәҗәгать итү вакыты:12.02.2024]

2. Г. Камалның “Банкрот” әсәре турында URL: https://tt.wikipedia.org/wiki/Банкрот_(спектакль) [Мөрәҗәгать итү вакыты:12.02.2024]

3. Гоголь, Николай Васильевич. Мертвые души. [Поэма]. Николай Васильевич Гоголь. — Москва: Издательство АСТ, 2021. — 352с. (Эксклюзив: Русская классика).

4. Н. В. Гоголь “Мертвые души”. Анализ произведения. URL: https://www.nur.kz/family/school/1845688-mertvye-dusi-kratkoe-soderzanie-i-analiz-proizvedenia/ [Мөрәҗәгать итү вакыты:12.02.2024]

## МӘКТӘПТӘ ҺАДИ ТАКТАШНЫҢ “МӘХӘББӘТ ТӘҮБӘСЕ” ПОЭМАСЫН ӨЙРӘНҮ

Сәхәбетдинова Ә.Б.,
КФУның Алабуга институты студенты.
Фәнни җитәкче: Камаева Р.Б.

Такташ - татар шигъриятенең алтын баганаларының берсе. Узып баручы егерменче гасырның давыллы вакыйгалары казанында кайнаган бу олы шагыйребез халык күңелендә мәңгегә урын алды. Җанында Такташ яшәмәгән, кабатланмас бу шәхеснең көчле рухы һәм тирән моңнары белән сихерләнмәгән милләттәшләребез сирәктер дип беләм. Яңа меңьеллыкка без Такташлы булып керә алуыбыз белән бәхетле. Аның күкләргә ут белән язылган шигъри авазы вакытлар узган саен тагын да көчлерәк яңгыраячак әле… (М. Шәймиев).

Һ.Такташның иң әһәмиятле әсәрләренең берсе – «Мәхәббәт тәүбәсе» поэмасы (1927). Анда шагыйрь югары әхлак принципларын чор агымнарына каршы куя. Поэмада комсомолка Зөбәйдә наборщик Мәхмүт турында сөйли. Зөбәйдә Мәхмүтне чын күңелдән ярата. Ә егетнең кызга мөнәсәбәте бик үк җитди түгел. Аны вакытны ләззәтле уздыру өчен генә кирәк дип саный. Зөбәйдә Мәхмүтне ихлас ярата, шуңа күрә егеттәге хисләрнең чынлыгына да шикләнми. Нәтиҗәдә, егет кызны алдый. Кыз балага узгач, туачак җан иясе өчен җаваплылыктан качып, Мәхмүт Зөбәйдә янына бөтенләй килмәс була. Ата буласы кешенең үзен ташлавы кызны борчуга сала. Ләкин, бәхеткә каршы, бала тугач, егеттә үз кылганнарына үкенү хисе уяна, ул Зөбәйдәсе һәм үзенең баласы янына килә. Яшьләр гаилә кора.

Һ. Такташның бу поэмасы мәктәп программасы буенча 10 нчы сыйныфта өйрәнелә. Язучы иҗатын 4 этапка бүлеп өйрәнергә була.

1нче этап. Кереш дәрес: язучының тормыш юлы һәм иҗаты белән танышу дәресе. Әдәбият дәресләрендә язучының тормыш һәм иҗат юлын өйрәнү зур әһәмияткә ия. Бу югары сыйныфларда аеруча мөһим. Язучы биографиясе әдәби-тарихи җирлектә, үз чоры әдәби тормышының бер өлеше кебек бирелә. Аның замандашлары, көрәштәш-дуслары, остазлары һәм эшен дәвам итүчеләр турында сөйләү дә биографиягә ялганып китә.

Язучыларның биографиясен өйрәнү яшь буынга әхлак тәрбиясе бирүгә, шул исәптән аларның әдәбият фәне буенча белемнәрен тирәнәйтүгә, үстерүгә, камилләштерүгә ярдәм итә. Язучы шәхесенең үзенчәлекләрен, холык-фигылен, язмышын, тарихи һәм эстетик карашларын ачыклау аның биографиясен өйрәнү аркылы тормышка ашырыла.

Мондый дәресләр уздырыр алдыннан күп кенә чыганакларга: язучының замандашлары истәлекләренә, хатлар, көндәлекләр, биографик һәм автобиографик төстәге китапларга, фәнни-популяр әдәбиятка мөрәҗәгать итәргә туры килә.

2нче этап. Әсәрне өйрәнүнең нигезе буларак уку. Укуның максаты – текстка салынган мәгълүмат, эчтәлек белән танышу. Һәр әсәрне беренче тапкыр укыганнан соң аннан алган тәэсирләр турында сөйләшергә кирәк. Бу кичерешләр әдәби анализга нигез булырга мөмкин.

Әсәрне кабатлап уку яисә тулы килеш җентекләп яки аерым өлешләрен сайлап укуны оештырырга мөмкин. Уку ике төргә бүленә: өйдә уку, сыйныфта уку. Аларны чиратлашып алып барырга кирәк.

3нче этап. Әдәби әсәрне анализлау дәресе. Мондый дәресләр төрле типларга бүленә: әсәрне анализлау дәресе, поэманы өйрәнү дәресе һ.б., ләкин нигездә бер үк максатларга ирешүне шарт итеп куялар: белем бирү максаты: “Мәхәббәт тәүбәсе” поэмасының эчтәлеген ачу һәм анализлау; күнекмәләр үстерү максаты: сәнгатьле уку күнекмәләрен үстерү, фикерләү сәләтләрен арттыруга ярдәм итү, лирик әсәрне анализлау күнекмәләрен булдыру. Шулак ук бу максатлар белән беррәттән тәрбия бирү максаты булу да мөһим, мәсәлән, укучыларда сафлык, тугрылык, намуслылык сыйфатлары тәрбияләү. Әсәрне

өйрәнү, анализлау дәресләрендә киләсе эш төрләре кулланыла: 1) “Мәххәбәт тәүбәсе” поэмасының эчтәлеген искә төшерү; 2) әсәр язылган чорга характеристика бирү (әсәрнең язылу тарихы, язучының иҗади югарылыгы, чорга хас вакыйгалар күрсәтелә); 3) сүзлек өстендә эш; 4) әсәрнең тематикасы һәм идея эчтәлеген ачыклау (поэманың идея эчтәлеген ачар өчен аның композициясе буенча класста коллектив тикшерү үткәрелә (пейзаж, характеристика, портрет, хикәяләү һ.б.)); 5) лирик геройны билгеләү; 6) тел-стиль чараларына хакртеристика бирү; 7) шигырьнең төзелеше, ритмикасын бәяләү; 8) поэтик образларга характеристика бирү; 9) авторның фикерен ачыклау; 10) әсәрнең әһәмитен билгеләү. Дәресне бераз төрләндерү өчен укучыларга Һади Такташның “Мәхәббәт тәүбәсе” поэмасының аудиоязмасын тыңлатырга була.

Поэтик образларга характеристика үрнәге:

| Төп образлар | Уңай яклары | Тискәре яклары |
|---|---|---|
| Зөбәйдә | | |
| Мәхмүт | | |

4нче этап. Йомгаклау дәресе. Йомгак алган белемнәрне гомумиләштерүдән тыш, укучылдарда әдәби әсәр турында бер бөтен караш булдыруга хезмәт итә. Йомгаклауда төрле ысуллар һәм эш төрләре кулланыла: уку, әңгәмә, иллюстрацияләр карау, истәлекләр, тәнкыйтькә мөрәҗәгать итү, укытучы сөйләве, укучыларның чыгышлары, эзләнү, тикшеренү урын таба.

Йомгак берничә максатка хезмәт итә: 1)өйрәнелгән әсәр буенча нәтиҗәләр чыгару; 2) укучыларның анализ вакытында әсәргә карата туган бәясен тагын бер кат тикшереп карау; 3) әсәргә бәя биреп, аның язучы иҗатында чор әдәбиятында урынын, әһәмиятен билгеләү; 4) укучыларның фикер йөртү, бәя бирүенә ирешү.

Әсәр бүгенге көндә дә зур әһәмияткә ия, поэмада күтәрелгән проблемалар хәзер дә бик актуаль. Мәхмүтнең хатын-кызларга карашын, мораль җаваплылыгын аңламавын тасвирлау аркылы, шагыйрь кайбер яшьләр арасында күренгән эгоистлыкның начарлыгын, тормыш төзү өчен чит нәрсә икәнлеген аңлата. Шагыйрь шулай ук Ана исемен бөек исем итеп саный, гаиләнең ныклыгын, бала тәрбияләүнең җаваплылыгын, аналарга хөрмәт белән карарга кирәклеген искәртә. Һади Такташның бу поэмасы аша укучыларга тапшырасы килгән фикере бүгенге көн яшьләренә кирәкле сабак һәм әсәр мәктәп программасында киләкчәктә дә сакланып калырга тиеш.

**Әдәбият**

1. Һ. Такташның “Мәхәббәт тәүбәсе” поэмасының кыскача эчтәлеге URL:https://multiurok.ru/blog/h-taktashnyn-m-kh-bb-t-t-ub-sie.html [Мөрәҗәгать итү вакыты:12.02.2024]

2. Хатипов Ф.М. Әдәбият теориясе. – Казан: Мәгариф, 2000. – 350 б.

3. Камаева Р. Б. Татар теле һәм әдәбият дәресләрендә яңа педагогик алымнар . − Алабуга: АИ КФУ нәшрияты, 2012. − 136б.

4. Рус телендә урта (тулы) гомуми белем бирү мәктәбендә татар теле һәм әдәбиятыннан үрнәк программалар: 1-11 сыйныйлар/ Төз. авторлар: Ф. Г. Галимуллина, З. Н. Хабибуллина, Х. Г. Фәрдиева. − Казан: "Мәгариф" нәшрияты, 2011. − 239б.

5. Һади Такташның "Мәхәббәт тәүбәсе" поэмасын өйрәнү дәресе үрнәге URL: https://infourok.ru/h-taktash-məhəbbət-təүbəse-5584189.html [Мөрәҗәгать итү вакыты:12.02.2024]

6. Поэтик образларга характеристика үрнәге URL: https://multiurok.ru/index.php/files/h-taktashnyn-m-kh-bb-t-t-ub-sie.html [Мөрәҗәгать итү вакыты:12.02.2024]

.

## МӘКТӘПТӘ Ф.ЯРУЛЛИННЫҢ "ЛАЕКЛЫ КИЯҮ" ӘСӘРЕН ӨЙРӘНҮ

Сундукова А.Ф.,
КФУның Алабуга институты студенты.
Фәнни җитәкче: Камаева Р.Б.

Фәнис Яруллин - киң колачлы язучы. Гади телдә язылган кыска гына хикәяләрендә ул үзен борчыган мәсьәләләрне күтәрә, вакыйгаларны тасвирлый. Көндәлек тормышыбызда еш очрый торган ямьсез күренешләр – гамьсезлек, кешелексезлек өчен борчыла, алардан гыйбрәт алырга өйрәтә.

Хәсәнова Ф.Ф. авторлыгындагы "Мәгариф-Вакыт" нәшриятында чыккан 9 нчы сыйныф татар әдәбияты дәреслегенә Ф.Яруллинның "Лаеклы кияү" экият-хикәясе кертелгән. Ул – сатирик әсәр.

Сатира – көлкенең бер төре. Язучының сурәтләү предметына тискәре мөнәсәбәт белдерүе. Сатира теләсә кайсы жанрны яңарта, актуальлек, заманчалык төсмере бирә. Әдәбият белемендә сатира теориясе аз өйрәнелгән өлкәләрдән санала. Кайбер галимнәр сатираны әдәбиятка килеп кушылган публицистик катлам дип бәяли. Сатира – ул чынбарлыкны образлы итеп кире кагу. Сатирада чиктән тыш арттыру, аллегорик образларга мөрәҗәгать итү, уңай һәм тискәре күренешләрне янәшә куеп сурәтләү урын ала [Хәсәнова 2017: 247].

Әсәр экият элементлары белән башлана һәм тәмамлана. Дәрестә бу хикәя белән эшләү өчен күнегүләр системасы түбәндәгечә булыр.

1.Сүзлек өстендә эш.

Бирем. Бирелгән сүзләрне аңлатмаларын сүзлекләрдән табыгыз, 5 җөмлә төзегез.

Имезлек, шыткан, мәҗлес, гайрәтле, шома тел, гарьлек, көтә-көтә көтек булу.

2. Сүзтезмәләрне кулланып, әсәрнең кыскача эчтәлеген сөйләргә.

Биек түшәмле, иркен балконлы, өч бүлмәле фатир; пианино артына утырткаlinнар, зифа каеннар көнләшкән; кояш тоныкланып кала икән; әнис алмасыдай; кызның әти әниләренең табаннары төште, кияү егетләре, бар дөньяга таралган, беренче класслы очучы, кичәге студент, көлтә-көлтә кәгазьләр тартып чыгара башлады, келәм өстендә мәңге чистармаслык эзләр калдырып, туй күлмәге, күрсәтмәләр бирде.

3.Әсәрдән әкият элементларын табыгыз.

Үрнәк. Аның серле күзләрендә төннәрен йолдызлар төшеп коенганнар, якты йөзеннән ай үзенә нур алган, ә баскан эзләрендә матур-матур гөлләр шыткан. Кызның сылулыгыннан зифа каеннар көнләшкән, озын толымнарына борма сулар кызыккан. Энҗе тешләрен балкытып көлеп җибәрсә, хәтта кояш тоныкланып кала икән.

Бу туйда мин дә булдым: төпсез чүмеч белән дөньяда юк шәраб чөмердем, башсыз кашык белән аш состым. Сыйлары өч кабарга җитмәде, биш кабуда бетмәде.

Алып батырдай гайрәтлеләре дисеңме, ул Шомбайдай хәйләкәрләре дисеңме, ул ак сакаллы карттай акыллылары дисеңме – кемнәр генә юк араларында.

4.Бирелгән өзектән фразеологизмнарны табарга.

Көннәр болыттай агыла торды, чибәр кызның күңелен яуларга теләүчеләр һаман күбәя барды. Иңнәренә алтын погоннар таккан хәрби хезмәткәр дисеңме, төрле илләр гизгән атаклы спортчы дисеңме, рәсемнәре газетаның беренче битләрендә басыла торган атаклы уйлап табучы дисеңме – кемнәр генә юк инде. Әмма кыз хәрби хезмәткәрнең алтын погонына да, атаклы спортчының ялтыравыклы медальләренә дә, уйлап табучының шөһрәтенә дә кызыкмады. «Унбиш ел көтсәм көтәрмен, барыбер үземнекен итәрмен», — дип, көзгедәге үз чагылышы белән сөйләште. Дөньяда һәркемгә үз ише табылачагына ышанып, өметләнеп яши бирде. Ишек шакучылар кими төшкәч тә өметен өзмәде. Чибәрлеге өстенә бик сабыр да иде шул.

Көтә-көтә көтек була язгач, көннәрдән бер көнне өстенә җитмеш җиде ямаулы джинсы костюм, башына туксан тугыз маймыл рәсеме төшкән кепка кигән бер бәндә килеп керде боларга. Керде дә ләмгә баткан ботинкалары белән кыйммәтле келәм өстендә мәңге чистармаслык эзләр калдырып түргә узды,

5. Сорауларга җавап бирегез.

«Лаеклы кияү» әсәренең жанрын билгеләгез. Әсәрдә көлке бармы? Ул нинди көлү? Нәрсәдән көлү?

Әсәрдән сатира элементларын табыгыз.

Кызның иң соңыннан килгән егетне сайлавына сез ничек карыйсыз?

Әсәрдә заманчалык төсмере нәрсәдә күренә?

Әсәрдә уңай күренеш бармы? Нәрсәләр?

«Танышлык» турында сезнең фикерегез ничек? Ул кирәкме? Кайчан кирәк? Ни өчен кирәк?

6. Әсәр эчтәлеге буенча рәсем ясарга

7. Әсәрнең тел-стиль үзенчәлекләрен ачыклау.Таблицаны тутырырга: әсәрдән тиешле сүзләрне, сүзтезмәләрне табып язарга.

| | |
|---|---|
| Лексика | Синонимнар, антонимнар, фразеологизмнар,искергән сүзләр, алынма сүзләр |
| Күчерелмә мәгънәдәге сүзләр | Чагыштыру, метафора, эпитет, метонимия гипербола |
| Синтаксик фигуралар | Гади кабатлау, анафора, эпифора, Эпистрофа,градация, синтаксик параллелизм, антитеза |

8. Төп геройларга характеристика бирергә. Таблицаны тутырырга

| Төп геройлар | Цитата | Характерлы сыйфатлар |
|---|---|---|
| Кыз | Аның серле күзләрендә төннәрен йолдызлар төшеп коенганнар, якты йөзеннән ай үзенә нур алган, ә баскан эзләрендә матур-матур гөлләр шыткан. | Бик матур, сылу |
| 1 нче егет | .... | ... |

Йомгаклау сүзе. Талантлы әдип әсәрләрендә, экияти сюжет файдаланып, бик мөһим әхлак мәсьәләләрен хәл итә, “Лаеклы кияү” әкият-хикәясе нигезендә киләчәк буын хакында борчылу, аларны әхлаклы, кешелекле итеп тәрбияләү, милләтебезнең киләчәген бәхетле итеп күрергә теләү ята.

**Әдәбият**


1. Заһидуллина Д.Ф. Әдәби әсәргә анализ ясау / Д.Ф. Заһидуллина, М.И.Ибраһимов, В.Р. Әминева. – Казан: Мәгариф, 2005. – 111 б
2. Хәсәнова Ф.Ф. Татар әдәбияты; рус телендә төп гомуми белем бирү оешмалары өчен д-лек(татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен) 9нчы с-ф. Ике кисәктә. 2нче кисәк. / Ф.Ф. Хәсәнова, Г.М.Сафиуллина, М.Я.Гарифуллина. – Казан: “Мәгариф – Вакыт” нәшрияты, 2017. – 191 б.
3. Хәкимова С.Г. Фәнис Яруллин: Тормыш юлы һәм иҗаты. – Казан: Мәгариф, 2006. – 167 б.


## ТЕКСТ – ЭТО СРЕДСТВО КОММУНИКАЦИИ


Талипова Г.Р. ,
студентка Елабужского института КФУ.
Научный руководитель: Камаева Р.Б.


Изучение текста началось в языкознании в 40-50-е годы XX века. В русской и зарубежной лингвистике в 60-е и 70-е годы расширилась и углубилась. Полученная для изучения во многих отношениях целостная речь стала называться текстом. В книге М.З. Закиева «Хәзерге татар әдәби теле

(синтаксис)»/ «Современный татарский литературный язык (синтаксис)», изданный в 1974 году, под названием «Синтаксические целые» исследуются смысловые и структурные связи, грамматические связи самостоятельных предложений в тексте. В книге «Синтаксис и пунктуация современного татарского литературного языка», изданный в 1984 году ученый в связи с этими общими проблемами исследует типы татарского текста и проблемы его целостности.

В 1993 году Ф.С. Сафиуллина выпускает книгу «Текст төзелеше» /«Построение текста», в которой на примерах разъясняет многие проблемы текста. В 1992- 1995 годах был издана «Татарская грамматика (синтаксис)» на русском языке. Третий том. И в ней многогранно освещаются проблемы текста в татарской речи. Несмотря на то, что науки теории текста, текстовой лингвистики имеют значительное развитие, до сих пор не дано точного объяснения объекту их изучения – термину «текст».

В «Толковом словаре татарского языка» определение текста следующее: текст это – «написанная (опубликованная) речь, речь, доклад и др.» [ТСТЯ, 1981: 68]. Академик М.З. Закиев дает тексту следующее определение: «текстом называют связную речь, полученную для изучения, организованную по содержанию и структуре» [Закиев, 2005: 341]. В трудах Ф. С. Сафиуллиной, М..З.Закиева «Современный татарский литературный язык» «текст – это смысловая, логическая, коммуникативная, структурно-грамматическая, интонационная составляющая речи»[Сафиуллина 2002: 387].

Это мнение отражено и в “словаре языковых терминов”, составленном Х. Х. Салимовым: “Текст – это самая крупная смысловая, логическая, коммуникативная, структурно-грамматическая, интонационно организованная единица речи, определенная организация самостоятельных предложений» [Салимов, 2001: 69]. Г.В. Колшанский связывает определение текста с «завершением минимального акта общения – информирования и обсуждения между партнерами» [Колшанский, 1985: 10]. Текст для Ю.А. Сорокина – «концепт так называемой текстовой целостности в лингвистической литератур» [Сорокин, 1985: 62]. Феноменальность текста подчеркивается и М.Н.Никоновой: «текст – это и средство коммуникации, и средство хранения и передачи информации, и отражение психической жизни индивида, и продукт определенного исторического периода, и форма существования культуры, и отражение социокультурных традиций» [Никонова, 2008: 22].

Изучение татарского языка как иностранного в настоящее время переживает тяжелый период. Нужно постоянно возвращаться к различным проблемам, в том числе к вопросу системы работы с текстом в обучении татарскому языку как иностранному, использовать опыт методики преподавания других языков, собирать новые подходы, новые задания, апробировать их, применять на практике.

**Литература**

1. Асадуллин А.Ш. Татарский язык в русскоязычной аудитории: учебное пособие/ А.Ш.Асадуллин, Р.А. Юсупов . – Казань: Магариф, 1995. – 206 с.
2. Никонова М.Н. Теория текста: учеб. пособие. – Омск: Изд-во ОмГТУ, 2008. – 240 с.
3. Сәлимов Х.Х. Тел гыйлеме терминнары сүзлеге. –Алабуга: Алабуга techinstitutы нәшрияты. – 2001. – 88 б.

## ПОЛИЛИНГВАЛЬ БЕЛЕМ БИРҮ ШАРТЛАРЫНДА ТӨРЕК ТЕЛЕН ТАТАР ТЕЛЕ НИГЕЗЕНДӘ УКЫТУ

Тимофеева Т.В.,
КФУның Алабуга институты магистранты.
Фәнни җитәкче: Хәйруллина Ә.С.

Хәзерге заманча мәгълүмати җәмгыятьтә барган глобаль үзгәрешләр бер чит тел белү генә җитмәгәнлеген күрсәтте. Бүгенге көндә күптеллелекнең актуальлеге арта бара. Моның белән бәйле рәвештә, берничә чит тел белүче кешене аңлаткан “полиглот” (грек теленнән poly – “күп”һәм glotta – “тел”) термины киң кулланыла [Гураль 2016:10]. Татарстан Республикасының Европа һәм Азия белән халыкара хезмәттәшлеге, туризмның артуы, яңа мәгълүмати технологияләрнең һәм һөнәрләрнең барлыкка килүе ике–өч телдә сөйләшүчебелгечләрне әзерләү кирәклеген билгеләде. Ә бу, үз чиратында, икенче чит тел өйрәнүгә ихтыяҗ артуга китерде.

Бүгенге көндә полилингваль белем бирү дөнья мәгариф киңлегендә мөһим урын алып тора. Ул тел төрлелеген саклауга, милләт, дөнья мәдәнияте кешесен тәрбияләүгә, хәзерге җәмгыятьтә ориентлаша алган, конкурентлыкка сәләтле булган шәхес тәрбияләүгә юнәлдерелгән. Уңышлы полилингваль белем бирүнең иң ачык мисалларының берсе – Татарстан. “Яңарыш” Республика Фонды Россия Федерациясе Мәгариф Министрлыгы һәм Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы белән берлектә 2020–2022 елларда “Адымнар” полилингваль гомуми белем бирү комплексларын булдыру буенча уникаль проектны гамәлгә ашырды. Бу елларда инде шундый алты мәктәп ачылды. Бүгенге көндә республикада алты полилингваль мәктәп төзелгән. Аларның берсе Алабуга шәһәрендә урнашкан[Шаймиев 2021: 1].

Башта полилингваль белем бирү комплексы концепциясе предметларны өч телдә – рус, татар һәм инглиз телләрендә алып баруны күздә тоткан. Хәзерге вакытта мондый мәктәпләрдә икенче чит тел буларак алман, төрек, кытай телләрен өйрәнү мөмкинлеге бирелә.

“Адымнар–Алабуга” да төрек теле түгәрәк эшчәнлегендә өйрәнелә. “Төрек теле”программасы урта мәктәп яшендәге (5 нче сыйныф) укучылар өчен атнага 2 сәгать исәбеннән 68 сәгатькә эшләнелгән. Түгәрәк эше укучыларны өйрәнелә торган телнең мәдәнияте белән таныштыруга, коммуникатив күнекмәләрне формалаштыруга, танып белү сәләтнен үстерүгә юнәлдерелгән.

Төрек телен өйрәнү чагыштырма ысул, ягъни татар телен исәпкә алу принцибы ярдәмендә тормышка ашырыла. Татар һәм төрек телләре алтай телләре гаиләсенә, төрки тел тармагына, әмма төрле төркемчәләргә карый: татар теле – кыпчак төркемчәсенә, ә төрек теле угыз төркемчәсенә. Шулай да аларның охшаш яклары шактый. Бу охшаш якларны билгеләү әлеге төрки телләрне чагыштырып өйрәнү өчен зур әһәмияткә ия.

Белем бирү процессын укучы актив шөгыльләнә алырлык, үз казанышларын бәяли алырлык, белемнәрен практикада тормышка ашырырлыкитеп, укыту нәтиҗәле һәм өзлексез булырлык итеп оштыру бик мөһим. Укытучы укучыны төрле ысуллар һәм бәяләү алымнары белән тәэмин итеп, белем алу процессында үзлегеннән ориентлаша алсын өчен мөмкинлекләр тудырып,анымотивлаштырырга тиеш. Формалаштыручы бәяләү – заманча җәмгыятьнең таләпләренә җавап бирүче бәяләүнең бер төре.Аның асылы үз–үзеңне бәяләү ярдәмендә үзләштерелгән материалның дәрәҗәсен ачыклый, үз–үзеңне камилләштерү юлларын сайлый белүдән, уку нәтиҗәләрен яхшыртуга юнәлдерелгән алдагы эшчәнлекне, үз–үзеңне үстерү перспективаларын һәм стратегияләрен билгели белүдән гыйбарәт[Трегубова 2021: 131].

Бүгенге көндә телләрне өйрәнүдә уңышлы кулланылучы берничә электрон белем бирү кушымтасы бар. LearningApps.org – алган белемнәрне тикшерү һәм ныгыту максатыннан кызыклы күнегүләрне уңайлы һәм җиңел ясарга мөмкинлек бирүче онлайн кушымта [4]. Югарыда әйтелгәнчә, татар теле белән параллель үткәрү төрек телен өйрәнү процессын күпкә җиңеләйтә, туган телгәкарата булган кызыксынуны арттыра. Мәсәлән, “Яшелчәләр” темасына караган сүзләрне өйрәнер алдыннан укучыларга экранда төрек телендәге сүзләрне һәм яшелчә рәсемнәрен чыгарырга мөмкин (1 нче рәсемдә күрсәтелгән). Балалар, татар телендә туплаган тәҗрибәләренә таянып, яшелчәләрнең төрекчә тәрҗемәсен аңларга тырышалар. Укучы, эзлекле рәвештә,чит тел системасын үзләштерүгә таба атлый. Аның татар теленең һәм төрек теленең төп билгеләрен үз эченә алган үз тел системасы барлыкка килә, охшаш тел һәм сөйләм күнекмәләре формалаша.



1 нче рәсем. “Яшелчә исемнәрен тап” уены

Шулай итеп, икенче чит телне өйрәнү укучыларны уңышлы социальләшүгә әзерли, башка мәдәниятләргә карата толерантлы мөнәсәбәт формалаштыруга ярдәм итә, лингвистик күзаллауны киңәйтә. Чит телне өйрәнгәндә татар телен исәпкә алу принцибы укытучыга материалны җиңел аңлатырга, ә укучыларга чит телне өйрәнүнең нечкәлекләрен яхшыракаңларга мөмкинлек бирә. Онлайн кушымталарны куллану, интерактив күнегүләр булдыручит телне дә, туган телне дә өйрәнүгә мотивацияне арттыругауңай йогынты ясый.

**Әдәбият**


1. Гураль С.К. Многоязычие и обучение иностранным языкам: современный контекстпроблемы / С.К. Гураль, Е.В.Конева, О.Г.Поляков // Педагогика. Вопросы теории и практики. – Тамбов: Грамота, 2016. – № 3(03) – С. 9–12.
2. Трегубова Ю.А. Формирующее оценивание образовательных результатов учащихся в современной школе / Ю.А. Трегубова, М.А. Мосина // Пермский педагогический журнал. – 2021. – №12. – С. 130–138.
3. Шаймиев М.Ш. Полилингвальное образование – требование времени // Актуальная педагогика. – 2021. Спецвыпуск. – С. 1–2.
4. LearningApps.org – создание мультимедийных интерактивных упражнений. – URL:https://learningapps.org/impressum.php (мөрәҗәгать итү вакыты: 15.02.2024).


## АРЧА ЯГЫ ХАЛКЫН ХРИСТИАНЛАШТЫРУ СӘЯСӘТЕ


Фәсхетдинов И.Р.,
Арча районы Г.Тукай исемендәге Яңа Кырлай
урта мәктәбе укучысы.
Фәнни җитәкче: Шиһапова Г.Х.


1552 елдан безне 472 ел аерып тора. Шушы еллар эчендә татар халкы үзенең милләтен, телен, мәдәниятен, динен саклап калу өчен көрәшә, һәм бу көрәштә Арча ягы халкының роле бик зур.

“Арча ягы халкын христианлаштыру сәясәте” исемле эзләнү эшемнең максаты – Казан ханлыгы Рус дәүләте тарафыннан яуланып алынганнан соң дәүләтнең мөселманнарга карата дини сәясәтен өйрәнү һәм анализлау, Арча төбәгендә бу сәясәтнең ничек алып барылуын ачыклау.

Шушы максатка ирешү өчен түбәндәге бурычлар куелды: мөселманнарга карата Россия дәүләтенең төп дини сәясәте юнәлешләрен ачыклау; Казан ханлыгы яулап алынганнан соң мөселманнарның дини ирек өчен көрәшен анализлау; миссионерлык эшчәнлеге үсешен өйрәнү; үзебезнең якын–тирә авыл халкының чукындыру сәясәтенә каршы көрәшен чагылдыру.

Казан дәүләтен яулауның беренче көннәреннән үк патша хөкүмәте Урта Идел буйларында яшәгән рус булмаган халыкларны тулысынча христианлаштыру сәясәте алып бара. Бу түбәндәге максатлардан чыгып эшләнә:

- руслаштыру, ягъни җирле халык арасында рус телен, мәдәниятен, гореф–гадәтләрен, православие динен көчләп тагу;
- Урта Идел халыкларының милли берләмлеген какшату;
- йомышлы татарлар арасында Рус дәүләтенә хезмәт иткән катлау барлыкка китерү.

Ул чорда дин әхлак һәм хокук нигезе генә түгел, дәүләт идеологиясен дә тәшкил итә.

Христианлаштыру түбәндәге ысуллар белән тормышка ашырыла: яңа дингә “ иркәләп һәм яратып” кертү; православие динен кабул итүчеләргә өстенлекләр һәм ташламалар куллану. Ә менә XVII– XVIII гасырларда христианлаштыру сәясәте мәҗбүр итү юлын сайлый.

Казан ханлыгының бер өлкәсе буларак, Арча кенәзлеге Мәскәүгә каршы сугышта актив катнаша. Ул Казанга гаскәр, сугыш кирәк–яраклары җибәрә, 1552 елның җәендә кенәзләр (әмирләр) Япанчы һәм Явуш җитәкчелегендә сугыш хәрәкәтләре оештыра. Соңгылары исә Казан янында торган рус гаскәрләренә җитди һөҗүмнәр ясыйлар. Рус гаскәрләре, арчалыларның Казанга ярдәмгә килүен тоткарлау өчен, Арча кырында махсус манаралар корырга булалар. 1552 елның 30 августында дошман, Япанчы һәм Явуш гаскәрләрен алдап, засадага кертә һәм “татарларны кыралар”.

Арча–Казан арасындагы авылларның байлыгы турында А.Курбский шаккатып яза. “Бер авылны да калдырмадык, яндырдык, байлыгын таладык, халкын әсир итеп алдык”, – дип яза ул мактанып.

Казан ханлыгы алынгач та халык дәүләт бетү белән килешми, 1553 елның көзендә азатлык сугышы башлый. Бу сугышлар өзеклекләр белән 1587 елга кадәр дәвам итә. Без ул сугышларны Казан ханлыгы халыкларының Ватан сугышы дип атый алабыз, дәүләтчелекне кайтару өчен татарлар гына түгел, марилар да, удмуртлар да сугышкан.

Христианлаштыру шаукымы Арча ягы халкын да читләтеп узмаган. 1555 елларда күчәеп китеп 1600 елларга Җөри һәм Арча юлындагы 24 татар авылының 19 чукындырылганы билгеле. (Арча хәбәрләре”, 2011 № 9–10).1565 – 1568 елларга караган чыганакта ук инде Чүриле ( хәзерге Иске Чүриле) авылының татарлардан торган халкы керәшеннәр ( урысча “Новокрещен”) дип күрсәтелә. 1602 – 1603 елларда бу “яңа чукынган” авылда 5 йомышлы кеше һәм 13 ясаклы кеше хуҗалыгы исәпләнә. XVII гасыр башында Арча ягының Апаз, Әзәк, Кишмәт, Яңасала, Курса авыллары халкы да “яңа чукынганнар” рәтендә йөргән.

Халык телендә бүген дә түбәндәге риваять яши: “Югары Әзәк һәм Иске Иябаш авыллары арасындагы басуда коры елга, икенче төрле “Кан елгасы “ дип йөртелгән елга бар. Чукындыру отрядлары Әзәк авылына килеп чыгалар һәм

авыл халкын шушы елгага куып кертәләр. Башта тыныч юл белән кызыксындыру хисабына күп нәрсә вәгъдә итәләр, тик халык алданмый. Аннары куркытып, төрле ысуллар кулланалар. Нәтиҗә булмагач, мәҗбүри көчләп–үтереп, кыйнап чукындыруга күчәләр. Әзәк авылы халкы һәм тирә–як авылы кешеләре бик нык каршылык күрсәтә. Ләкин көрәк, сәнәк белән генә коралланган халык бик тиз җиңелә. Кеше кырыла, мәетләр белән тулган елгадан кеше каны ага. Менә өч гасырдан артык инде бу елганы “Кан елгасы” дип атап йөртәләр. Исән калганнар гомерләрен, балаларын саклап калу хисабына чукынырга мәҗбүр булалар.

Иске Иябаш авылы кырындагы урман полосасы янында Казан ханлыгы чорыннан калган зират урыны бар. Бу урынны Изгеләр зираты дип йөртәләр. Анда барлыгы биш кабер ташының ватыклары саклана. Бер ташның куелу вакыты 1528 елларга туры килә. Бәлки бу урында Казан ханлыгы чорына караган бик күп кеше яшәгән 7 мәчетле зур Миһербан авылы булгандыр. Ханлык җимерелгәч, бу авыл туздырылган. А.Курбский да үзенең язмаларында, бу авыл таркалгач, аннан ике Иябаш авылы оешкан, тагын күп кешеләр Әзәк авылларына да күчеп утырганнар, дип язып калдырган.

Иске Иябаш авылы янында көчләп чукындыручыларның бер отрядын кырып бетерәләр. Шуннан соң руслар татарлардан 334 кешене тотып, үзләренә чокыр казытканнар һәм аларны терелэй җиргә күмгәннәр, дип сөйлиләр. Бу урынга урман хуҗалыгы картасында “Туганнар кабере” дип тамга төшерелгән.

Безнең күршедәге Иске Иябаш авылы халкы 1742 елда көчләп чукындырыла, 1871 елларда кире ислам диненә кайта. Әзәк авылының кире ата–баба диненә кайтуы 1870 елларга туры килә. Авылда 83 йортта керәшенлектән яңадан исламга күчкән 195 ир–ат һәм 216 хатын–кыз яшәгән. Түбән Әзәктә 44 йорт булып, мөселманлыкка кайткан 97 ир–ат һәм 101 хатын–кыз яшәгән. 1900 елларда Югары Әзәктә 495, Түбән Әзәктә 325 кеше татар буларак теркәлгән.

Арча төбәгенең бай тарихы, әлеге җирлектә туган һәм буыннан буынга туплана килгән рухи мирасы бар. Болгар, Алтын Урда, бигрәк тә Казан ханлыгы чорында Арча милли дәүләтчелекнең төп терәкләреннән берсе булган. Төбәгебез хәзерге чорда да үзенең лаеклы урынын саклый.

Бу эзләнү эше белән шөгыльләнгәннән соң мин түбәндәге нәтиҗәләргә килдем:

– Арча төбәге элек–электән милли дәүләтчелегебезнең төп терәкләреннән берсе булган;

– Иван Грозный Казанны тар–мар иткәннән соң күп кенә данлыклы шәхесләр Арча ягында сыену урыны тапканнар;

– Арча ягы халкы беренчеләрдән булып 1553–1557 елларда милли – азатлык хәрәкәтен башлап җибәрәләр;

– дини изүгә төрле юллар белән каршылык күрсәтәләр;

– халык күңелендә тарихның бу чоры риваятьләр, легендалар булып бүген дә саклана.

Тарих– кешелек хәтеренең гаҗәеп бер үзенчәлеге ул. Ул үткән чорларның һәрбер мизгелен белә, үзенең караңгы чоңгылларына алып төшә. Тарих– киләчәккә маяк, үткән дәверләр безгә зур сабак. Тарих– изге нәрсә. Нинди канлы, фаҗигале, хәсрәтле булса да, ул– изге. Шуңа күрә беркемнең дә аны онытырга хакы юк...

**Әдәбият**


1. Арча төбәге тарихы. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1996.–256б.

2. Атлас Tartarika. История татар и народов Евразии. Республика Татарстан вчера и сегодня: справочно–энциклопедическое изд.– М.: Дизайн. Информация. Картография, 2006. 888с.

3. Гарипова Ф.Р. Авыллар һәм калалар тарихыннан. Беренче җилд.–К.: ”Матбугат йорты” нәшр., 2001.

4. Документальный сборник “Источники по истории Татарстана (XVI–XVIIIвв.)” – 2я кн. Автор–сост: Алишев С.Х., ИЯЛИ им. Г.Ибрагимова АНТ, 1994.

5. Исхаков Р.Р. Миссионерство и мусульмане Волго–Камья (последняя треть XVIII–начало XX в.)–Казань: Татар. кн. изд–во, 2011.– 222с.

6. Ислаев Ф. Православные миссионеры в Поволжье.

7. Әзәк авылы. //Арча хәбәрләре 2011, № 9–10.

8. Казанский поход. // Арский вестник. 1997, 15 окт.


## ЧУАШСТАН ТАТАРЛАРЫ ТОРМЫШЫНДА ЯҢА ТОРЫН КАБЕР ТАШЛАРЫ


Феткуллова А.К.,
Чувашия Республикасы беренче номерлы
Шыгырдан урта мәктәбе укучысы.
Фәнни җитәкче: Айзатуллова Р.Р.


Һәрбер җирлекнең үз халкы өчен таныш булган һәм билгеле бер исем белән аталган урыннары була. Туган авылым Шыгырданда һәм авылдан ерак түгел генә урнашкан, халык телендә “Кизләү буе”, “Мөслим”,“Цаллук буе” дип аталган урыннары бар.Алар авылның тарихи ядкаре, бик күптәннән үк авыл халкының изге урыннары. Шыгырдан тирәләрендә болгар чоры каберлекләре барлыгын галимнәр раслап тора. Авылдан биш чакрым ераклыкта гына болгар чоры шәһәрчеге урыны да сакланган. Тирә–якта шул ук чор кабер ташлары да шактый. Бик борынгы заманнардан бирле зиратлар серле һәм изге урыннар булып саналганнар.

Чуашстан татарларының республикада дистәдән артык изге урыннары бар. Элек–электән килгән йола буенча, бу урыннарга халык барып, догалар кыла. Әлеге изге урыннарның күбесендә борынгы кабер ташлары да ята. Халык, шул тирәдәге мәхәллә кешеләре аларны карап–тәрбияләп тора.

Чуашстанда борынгыдан калган изгеләштерелгән каберлекләр:

1. Шыгырданда “Мөслим” (Батыр районы).

2. Кыр Бикшиге янында “Наратлар асты” (Батыр районы).
3. Тойси һәм Тимәш авыллары арасында. (Батыр районы)
4. “Тимерле” (Кызыл Чишмә янында, Батыр районы)
5. Шыгырдан белән Тигәш авыллары арасында (Батыр районы)
6. Яңа Торында Бичура һәм мөселманнар каберлеге. (Шомыршы районы)
7. Байтирәк авылында (Шомыршы районы).
8. Табырданда гаскәр башлыгы һәм мөселманнар каберлеге. (Канаш районы)
9. Шербидә (Сюрбеево) кирпеч заводы урынында. (Комсомол районы)
10. Ишан хәзрәт Хәсән күмелгән кабер. (Шорт, Комсомол районы)
11. Таяба янында (Ялчек районы).
12. Ковалида (Урмар районы).
13. “Атлашево һәм Тутаркассида (Чабаксар районы)
14. Чуваш милли музеендагы кабер ташы.

Чабаксардан Сембер шәһәренә илтә торган юл кырында, Чуашстанның көньяк өлешендә, Шомыршы районына керә торган Яңа Торын дип аталган авыл бар. Чуашлар аны Вăрманти Тăрăн, ягъни урмандагы Торын диләр, урысчасы исә Ново Буяново. Авыл зур булмыйча, 110 йортта чуашлар яши.

Бу авыл инде йөзләрчә ел буена тирә–яктагы татарлар өчен мөһим дини урын булып тора. Хикмәт шунда ки, әлеге авыл уртасында, Карлы елгасы ярында борынгы 2 кабер ташы һәм тирәсе тимерчыбык белән әйләндереп алынган зират бар. Берсендәге язуларны укырлык түгел, әмма икенчесендәге язудан тарихны чамалап була. Чуашлар аны мишәр мазары–каберлеге дип атый, ә татарлар исә "болгар бабаларыбыз яуда һәлак булган урын" дип йөри.

Бу каберлек хакында төрле сүзләр йөри. Чуаш авылы уртасындагы зиратта Болгардан куылып килгән сугышчылар һәм өч изге кыз күмелгән дип, сөйләгәннәр картлар. Башка версияләрдә әлеге кабер ташы Бикбулат морза тарафыннан Тинчура улы Бикчурага һиҗри белән 1108 елда куелган. Һиҗри елын миладига әйләндерсәк, 1695 ел була. Халык бу урында сугыш булган дип сөйли. Риваятьләргә караганда, Бичура сугыш кырында һәлак булган. Аның гәүдәсен сугыш кырыннан елга буенча алып килеп, татар авылының каберлегенә күмгәннәр. Татар авылы хәзер юк. Шул тирәләргә Буяноводан һәм Торыннан чуашлар күчеп килеп авыл төзегәннәр. Татар авылының исемен хәтерләүчеләр юк. Бәлки ул авылның исеме Карабай булгандыр. Чөнки татар каберлегеннән ерак түгел Карабай Шомыршы авылы бар. В. Магницкий “Список татарских селений Буинского уезда в “ОАИЭ”, т. 18” дигән хезмәтендә дә Карабай исеме белән татар авылы булуын искәртә. Бу урынны тарихчылар нугай татарлары белән урыс гаскәре бәрелешкән урын булуы ихтимал дип аңлата. Бичураның нинди сугышта һәлак булуы безгә төгәл мәгълүм түгел. Казаннан килгән профессор Һ.Юсупов кабер ташларындагы язуны Бичура

Тинчура улы икәнлеген укып раслый. Чуаш галимнәре кабер ташлары чуашча язылган дип аңлатырга тырыша. Әмма язу саф татар телендә.

Бу урынны җирле татарлар изге урын дип саныйлар һәм ел саен дога кылырга киләләр. Җирле тарихчылар да бу җирләрдә татар–мөселман догасы өзелмәгәнлекне яза. Тарихи чыганакларда 1908 елда Сембердән Г.Кокол дигән тарихчы Яңа Торын зиратындагы кабер ташлары хакында мәгълүмат теркәп калдырган. "Шыгырданнан килгән татарлар тезләнеп гыйбадәт кылып утыралар иде. Алар монда Казан ханлыгы вакытындагы изге затлар – сугышчылар күмелгән дип әйтәләр”, – дип язып куйган ул.

Кайсы көнне тезелеп дога кылуларын ул чакта теркәп калдырмаганнар. Бүгенге көндә Шыгырдан татарлары һәр ел май аеның соңгы көннәрендә шушы чуаш авылына килеп, гыйбадәт уздыра. Яңгыр аз булганелларнымондакилеп, яңгыр намазы да укыйлар.

Авылкартларыһәм карчыкларыннан Яңа Торын турында белгән, ишеткәннәре турында да сораштырдым. “Бала чакта Яңа Торынга әниләр, әбиләр белән җәяү бара торган идек. Халык күп була иде. Әбиләр зиратның аскы ягында, Карлы елгасы ярына төшеп дога кылалар, шунда ашый–эчәләр иде. Кайбер кешеләр кунып калалар иде. Татарлар килгәнне күреп, чуашлар чәйләр кайнатып, йомыркалар пешереп безне сыйлыйлар иде. Әбиләр үзләре белән алып килгән чәйләрен пешереп, чәйләр эчәләр иде”, – дип искә төшерделәр олылар.

Яңа Торын авылы зиратына татарлар электән корылык булганда дога кылырга килә торган булганнар. Зират читендә карап торган чуаш карчыклары да, татарлар килде, димәк яңгыр була дип, ышаныч күрсәтеп калганнар. Ясин, Тәбрәк укылганнан соң, халык белән бергәләп тәүбә кылына. Моннан соң, электән килгән гадәт буенча, зираттан чыгып, яр буенда корбан ашлары ашала. Ә яңгыр теләгенең төп гыйбадәте – истиска намазы шул ук көнне мәчетләрдә укыла. Шыгырдан, Балтай, Байтирәк, Татар Согыты авылы татарлары бу урынга ел да бер аерым көнне килеп торганнар.

Бүгенгесе көндә Яңа Торын тарихи–мәдәни кыйммәткә ия булган урын дип санала.

Нигә бу урынны чуашлар да изге итеп кабул иткәннәр соң? Бу җиргә бәйле күп вакыйгаларны мисал итеп китергә була. Картлар сөйләвенә караганда, зиратның тирә–ягында койма тотылмаган була. Бер тракторчы бу җирне сөрергә тотына. Тимер сабаны моның чытырдап сына. Колхоз икенче сабан китерә, барыбер сөрә алмыйлар. Тракторчысы да вафатбула. Шуннансоңизгеурынныңкадеренаңлыйбашлаганнар. Колхозлашу вакытында, бу урынны сөреп, анда кыяр утыртып караганнар. Әмма ике ел рәттән бозлы яңгыр явып, үсемлекләрне харап иткән. Зират тирәсендә бала–чага мал ашаткан. Балалар шуннан соң авырган. Ул авыру балаларны татарлардан өшкертеп торганнар. Файдаларын да күргәннәр.

Нурислам Көсәинов шушы зиратны карап торучы кеше. Туксанынчы елларда тирә–ягына яңадан койма тоттырган, бүгенгәчә тәртибен карап тора, яз–көз зират җирен җыйдырта. Бу эштә аңа җирле чуашлар ярдәм итә.

"Моңа кадәр этиемнең этисе бу зиратны карап торган. Халык бик күп була иде монда, өчәр көн торалар иде. Монда сугыш вакытында һәлак булган болгар бабайлар күмелгән. Элек чуашлар бу урынга салкынрак карый иде. Хәзер мөнәсәбәт башка. Чөнки алар казалар күргәләделәр. Бер җирле яшь ир зират өстендә печән чапкан, ул үлгән. Аннары әнисе сукырайган. Аңа кадәрдә бу зират белән бәйле шундый вакыйгалар булган, шуңа күрә хәзер бу җирне алар да изге итеп күрә", – ди Нурислам әфәнде.

Безнең бабаларыбыз гаделлек, иминлек, туганлык кебек төшенчәләргә табынып яшәгәннәр, тарихка саклык белән караганнар. Без аларның теләкләрен дәвам итәргә, алар кадерләгәнне кадерләргә, саклаганны сакларга тиешбез. Алар үзләре исән чакта безне тарихыбыз, ата – бабаларыбыз рухы белән бәйләп тоталар. Ә алардан соң без киләчәк буынны шуңа өйрәтергә тиешбез. Галим Тәлгать Галиуллин килер буыннар турында һәркемгә уйланырлык фикерләр әйтә: "Киләчәк буыннар үзләренең тамырларын белергә тиешләр. Башкача булганда, җәмгыятьне маңкортлар, үз тарихын белергә теләмәгән, бер көн белән яшәгән нәселсез адәмнәр явыз саранча болыты шикелле басып китәчәк", – ди ул. Үз иленең, төбәгенең, туган авылының тарихын белү кешегә үзен "Кеше" буларак танырга ярдәм итә. Изгеләрне хөрмәтләү, ихтирам белән телгә алу безнең кешелек сыйфатларын югалтмавыбызны, алдагы буыннар өчен күңелләребезнең тыныч булуын күрсәтә.

Тарих белән бәйләнеш булган, бар һәм киләчәктә дә булачак. Минемчә, һәр буын бу "Изге урын" нарны киләчәк буынга мирас итеп калдырачак.

**Әдәбият:**


1.Салихов П.М. Шыгырдан. – Ульяновск: ОАО «Областная типография «Печатный двор», 2010. – 544.

2.www.azatliq.org/a/28516338.html

3.https://islam21.ru

4.Авыл картлары белән әңгәмә.

5.Журналист Земдиханов Рәфис белән әңгәмә.


## ФИЛОСОФИЯ СМЕРТИ В РАССКАЗАХ АМИРХАНА ЕНИКИ


Хабибуллин Н.И.,

Ученик 11 класса "Лицея Иннополис".

Научный руководитель: Евсеева Л.Р.


*Я каждый день видел смерть, однако в рассказах своих писал о жизни, что она сильнее смерти.*

*А.Еники*

В татарской прозе военных лет (1941–1945 г.г.) высоко художественные, эстетические совершенные, обогащенные символами рассказы Амирхана Еники проложили путь преодоления схематизма социалистического реализма. Путем углубления психологизма и философского подтекста, А. Еники возродил в национальной прозе литературные традиции начала XX века. Трансформация философии смерти в военных рассказах писателя связывает татарскую прозу начала XX века с прозой военных и послевоенных лет. В них канонизируется философия вселенской любви в качестве мировоззренческого идеала.

Татарский народный писатель, публицист, лауреат Государственной премии РТ им. Г. Тукая Амирхан Еники (1909–2000) – выдающийся татарский писатель XX века. Он вошел в историю татарской литературы как неповторимый в своей индивидуальности мастер–психолог, которого отличает глубокое проникновение во внутренний мир героев, подробное описание и анализ различных психологических состояний, внимание к оттенкам переживаний. Вопрос психологизма в творчестве писателя представляется узловой проблемой и приобретает первостепенное значение для углубленного понимания его творческой индивидуальности. А. Еники – создатель убедительных образов, он сумел соединить в своем творчестве глубокий аналитический взгляд на современность и глубокий метафизический план.

Произведения писателя «Бала» («Девочка», 1941), «Ана һәм кыз» («Мать и дочь», 1942), «Бер генә сәгатькә» («Лишь на час», 1944), «Ялгыз каз» («Одинокий гусак», 1944), «Мәк чәчәге» («Мак», 1944) отдельным течением выделялись в общем потоке военной литературы, детально описывающей ужасающие подробности фронтовой и тыловой реальности, примеры жестокого поведения врагов, подвиги трудового народа и военных. Прозаик обращает свой взор на жанровые вариации, развивавшиеся в татарской литературе начала XX века, внося в свой творческий арсенал «прозу открытий» – жанр *нәсер*. Основанная на психологизме «проза открытий» позволяет писателю быть очевидцем человеческих переживаний, их внутреннего развития, трансформации.

Философия бытия, обрамленная в вариативные психологические описания, принимает оттенки национального. Автор, воссоздавая в художественном пространстве произведения переживания реального читателя, связанные с художественным воплощением конфликта оппозиций жизни и смерти, основывается на национальную модель философии бытия.

Одно из наиболее характерных и ярких произведений прозы военных лет – рассказ А. Еники «Бала» («Девочка», 1941). Рассказ начинается с описания дороги. Изначально описанная как «многолюдная» дорога на данный момент повествования пустынна, что может свидетельствовать только об одном – до того определяющего момента, как наследие поколений, зов предков, их жизненный путь начнут резонансировать с моно личностной формой прохождения пути бытия. Позже подробное описание пространства леса может быть расшифровано как выявление собственно сути испытания. Путь

испытаний, в данном случае воплощенный в лесе, «затихшем, словно прислушавшемуся к себе», может трактоваться как момент истины, мгновение, когда человек замер, чтобы внять своему внутреннему «я». Ключевой образ–символ картины – божественный свет – сакрально–художественное воплощение–предтеча наметившихся изменений во внутреннем пространстве личности, который использован в синтезе с хронологом рассвета; угадывается, что в недалеком будущем это состояние неги должно трансформироваться в чувство любви. Высказывается мысль, что сознательная жизнь человека должна начинаться с веры в себя. Веря в себя, человек сможет стать частью и воплощением сакральной сущности бытия. Безучастный пейзаж, отображение внутреннего состояния героя сменяется вожделенным, желанным спокойствием, осознанием гармонии природы и самого себя, к чему так стремился Зариф. Вместе с этим образ смерти теряет свое зловещее значение, она уже не пугает героя, так как жизнь его наполнена смыслом, уверенностью в своей правоте, верой в себя; эта вера, и ответственность за близких уводят его от мыслей о смерти.

Мастерство А. Еники в полной мере проявилось в его деликатном стремлении раскрыть читателю сакральную суть и бытийную ценность философии любви и гармонии. Прозаик пребывает в убеждении, что именно согласованность внутреннего мира человека и его поступков, его чувство ответственности позволят человеку всегда находить правильное решение, свое предназначение в чуждых ему обстоятельствах, и призывает читателя следовать этому пути, принципы которого передаются из поколения в поколение.

В рассказе «Бер генә сәгатькә» (1944) философия вселенской любви канонизируется, показывается вариативность ее функционально–бытовых проявлений. Авторская позиция выражается в признании аксиоматичности утверждений о том, что искренняя любовь способна наполнить мимолетное существование человека на Земле смыслом; сущность любви позволяет человеку жить, а не существовать, освобождая его из рабства низменных чувств; любовь приближает человека к идеальной реальности, создавая гармонию человека с природой, с окружающими, с любимыми, с самим собой.

Татарскому писателю еще в период войны удалось обратиться к читателю с призывом к осознанию и принятию своей ответственности перед смертью. Прозаик пребывает в убеждении, что именно согласованность внутреннего мира человека и его поступков, его чувство ответственности позволят человеку всегда находить правильное решение, свое предназначение в чуждых ему обстоятельствах, и призывает читателя следовать этому пути, принципы которого передаются из поколения в поколение. Мотив страха перед смертью, использованный в произведениях, заострял внимание читателя на непродолжительности жизни, призывал не тратить его на мелочные, низменные, не приносящие пользу действия, поступки. Авторская позиция выражается в признании аксиоматичности утверждений о том, что искренняя

любовь способна наполнить мимолетное существование человека на Земле смыслом.

**Литература**

1. Еники Ә.Н. Әсәрләр: 3 томда / Әмирхан Еники (төз. Г.Р.Гайнуллина). 1 том. – Казан: Татар.кит.нәшр, 2019;

2. Загидуллина Д.Ф. Татарская поэзия и проза рубежа XX – XXI веков: эстетические ориентиры и художественные поиски: монография/ Д.Ф. Загидуллина. – Казань: Татар. кн. Изд–во, 2018;

3. Заһидуллина Д.Ф. XX гасырның икенче яртысы татар әдәбиятын өйрәнү мәсьәләсе/ Әмирхан Еники һәм XX йөз әдәбияты – Казан: РИЦ “Школа”, 2009.

## ЛИЛИЯ ГЫЙБАДУЛЛИНА ШИГЪРИЯТЕНӘ ХАС ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘР

Хабибуллина Л. Р.,
КФУның Алабуга институты студенты.
Фәнни җитәкче: Габидуллина Ф.И.

Лилия Гыйбадуллина иҗаты – хәзерге чор татар поэзиясен бизәп торучы, аның барышын билгеләүдә катнашучы мирас ул. Яшь шагыйрә шигърияте, беренче чиратта, читләтеп әйтү белән аерылып тора. Автор беркайчанда лирик геройның хис-кичерешләре турында туры әйтми, идеяләр яшерен, танып беленә торган образлар белән турыдан-туры бәйле булган мотивлар яисә элгәре иҗат иткән каләм ияләренең текстлары белән аваздаш итеп бирелә.

Еш кына поэтик парадигма татар мифологиясе, халык авыз иҗаты, халык җыры белән диалогта барлыкка килә. Мәсәлән, “Җир караңгы” шигырендә караңгы төн сурәте караңгы күк, караңгыдагы җир, тынгысыз җил, ялгыз ай кебек киң таралыш алган табигать образлары ярдәмендә тергезелә. Шигырь, XX гасыр классик поэзиясе белән интертекстуаль бәйләнеш барлыкка китерүче, пейзаж лирикасы үрнәге буларак кабул ителә. Әмма, текст уртасындагы (икенче строфада), әйтерсең лә, көтмәгәндә ташланган фраза табигать картинасы һәм кеше гомере арасында параллелизм урнаштыра:

Йолдыз чүпләп караңгыдан гомер
кичә... [Гыйбадуллина, 2010: 6].

Караңгыда яктылык эзләгән кебек чынбарлыкка һәм кеше гомеренә бирелгән экзистенциаль бәя, тышкы дөньяның җентекләп, тәфсилләп тергезелгән, башлыча, караңгы төсләр өстенлек иткән сурәтенә кайтырга мәҗбүр итә: “җир караңгыда”, “күк караңгыда”, “төн караңгы”, “тынгысыз җил – төнге угры”. Текстка серлелек бирүче бөтенләй башка мотив – ялгызлык мотивы барлыкка килә. Әлеге мотив чагылышы күп сандагы кабатлаулар белән искәртелеп тора.

Кайвакыт халык авыз иҗаты белән диалог махсус рәвештә стилизация ярдәмендә ассызыклана. Мисал өчен, “Соры томан арада...” шигыре, татар халык җырлары ритмына ия. Алай гына да түгел, автор яхшы танып беленә торган фольклор образларын куллана:

Соры томан арада,
Күк ярлары аллана.
Ә төн, ай-һай, кара ла…
Таң җиле юлда уйный,
Сулыгып йолдыз сулый,
Һәр нурдан кояш ургый,
Иртәнге чыкны урлый[Гыйбадуллина, 2010: 6].

Халык җырындагы төсле үк, текстның беренче өлеше табигать турында сөйли, икенче өлешендә гүя очраклы рәвештә лирик герой һәр көн, һәр төн килә торган танып-белү бәхете турында хәбәр итә, шунлыктан, яшәешнең һәр күренеше – танып-белүнең яңа мизгеле – аңарда елмаю тудыра.

Күп кенә шигырьләрдә иллюзорлык өстенлек итә. Бу сыйфат лирик геройның татар поэзиясе өчен яңа статусы хисабына тәэмин ителә. Лирик герой, яшәешнең идеаль моделе белән үзара бәйле омтылышлары турында сөйли. Әмма, реаль тормышка бәяләмә бирелмәү (ул укучы тарафыннан идеал антиномиясе буларак уйланыла ала), лирик геройны үзенең теләк-ниятләрен гамәлгә ашыруга сәләтсез итә. Мисал өчен, “Эх! Хисләргә җигелеп...” шигырендә лирик герой хисләренә буйсынып буранда урамга чыгарга теләвен җиткерә. Әмма, соңгы юллар (аеруча да *–асы иде бер* кабатланучы формасы) мондый эш-гамәлнең тормышка ашмаслыгын күрсәтә:

Чыгасы иде бер урамга,
Чыдасы иде бер буранга!.. [Гыйбадуллина, 2010: 5].

Әлеге юллар Гамил Афзалның сатирик шигырьләре белән ассоциация тудыра. Икенче строфа Гамил Афзалның лирик героен хәтерләтүче, юаш, басынкы, зур максат-омтылышларына да карамастан беркайчанда “тышка чыгарга” кыюлыгы җитмәгән лирик герой типажын тудыру белән тәмамланган:

Гайбәткә карамый,
Сүзләрне аямый
Чыгасы иде бер урамга
Котырган буранда! [Гыйбадуллина, 2010: 5].

Әгәрдә Гамил Афзал поэзиясендә лирик герой автор иониясе ярдәмендә тудырылган булса һәм совет идеологиясе тарафыннан тудырылган үз чоры кешесе буларак кабул ителсә, Л. Гыйбадуллина шигырьләрендә ул авторның экзистенциаль бәяләмәсен ала. Мәсәлән, “Ә очасы килә...” шигырендә очасы килү теләге кешеләрнең тормышка ашмас хыялы буларак типиклаша. Әлеге мотивны көчәйтеп, шагыйрә икенче төрле укылышка урын калдыра һәм икенче строфаның икенче өлешендә, төрлечә аңланыла алган яңа эчтәлек барлыкка килә:

Ә очасы килә

Каурыйларны
Коя-коя ташлы юлларга…
…Син яварсың, яңгыр,
Тик иртәгә,
Соңга кала күрмә
Еларга… [Гыйбадуллина, 2010: 10].

Лирик геройның турыдан-туры яңгырга мөрәҗәгать итүе, аның соңга калу мөмкинлеге, елау зарурилыгы төрлечә интерпретацияләнә ала.

Лилия Гыйбадуллинаның һәр шигъри текстында диярлек фәлсәфи мотив бар, кайбер әсәрләрдә экзистенциаль эчтәлек өстенлек алып тора. “Чиксезлек турында пышылдап...” шигырендә шагыйрә иллюзионизм фәлсәфәсенә мөрәҗәгать итә. Лирик герой болай дип белдерә:

Тартылам, тайпылам, талпынам…
Җил дә юк, ил дә юк, МИН дә юк…
…Тын урам [Гыйбадуллина, 2010: 33].

Шул рәвешле, барысы да иллюзия һәм хәтта яшәеш үзе дә – симулякр (булмаган чынбарлыкның репрезентациясе, рәсем-сурәте, образы), дип игълан ителә. Шушы ук күренеш белән “Минсезлек” шигырендә дә очрашабыз, биредә “Минсезлек. / Мин синсез калада” [Гыйбадуллина, 2018: 22] юллары иллюзионизм концепциясе белән уеннан гыйбарәт.

Кайбер текстларда нәкъ менә поэтик парадигма – милли мәдәният белән интертекстуаль бәйләнеш – көтелмәгән мотивлар тудыра. Бу планда “Мең чыбыркы ысылдавы җилдә...” шигыре кызыклы. Биредә, автор идеясе буенча хәрабәләр хәлендә булган, татар тарихына бәя бирелә. Менә беренче строфа:

Мең чыбыркы ысылдавы җилдә
Хәрабәләр һәйкәл булган илдә.
Таң атышлый гына кояш бата…
Сибелә генә чәчәк, сибелә җилгә… [Гыйбадуллина, 2018: 20].

Сибелүче чәчәк образы, туган илне сагыну хисе чагылдырылган халык җырына (“Сибелә чәчәк”) ишарә итә. Әлеге образ текстка фәлсәфи һәм этномилли төсмер бирә: татар халкы тарихы (сибелүче чәчәк) сагыш предметы булып тора.

Шул рәвешле, Лилия Гыйбадуллинаның контекстлар белән күпкырлы уены аның шигырьләрен күпләгән мотивларны колачлаучы катлаулы әсәрләргә әверелдерә. Аларны ачыклау укучының әзерлеге дәрәҗәсенә бәйле. Лилия Гыйбадуллина шигырьләре серлелек; иллюзорлык; доминант, өстенлек алып торучы мәгънә-фикернең ешрак яшерен булуы һәм текстара бәйләнешләр дәрәҗәсенә күчүе белән аерылып тора. Аллитерацияләр муллыгы, гомум билгеле образ-символлар, хәтта фразалар белән осталарча уйнау, фәлсәфилек һәм читләтеп әйтү яшь шагыйрә иҗатының характерлы сыйфатлары.

**Әдәбият**

1. Әдәбият белеме: Терминнар һәм төшенчәләр сүзлеге / Төзүчеләре Д.Ф.Заһидуллина, В.Р.Әминева, М.И.Ибраһимов, Н.М.Йосыпова,

Ә.М.Закирҗанов, Т.Ш.Гыйләҗев, Г.Р.Гайнуллина. – Казан: Мәгариф, 2007. – 231 б.

2. Гыйбадуллина Л.Ф. Тынлык кайтавазы: шигырьләр. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2010. – 39 б.

3. Гыйбадуллина Л.Ф. Кайту: шигырьләр. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2018. – 71 б.

**4.** Хатипов Ф.М. Әдәбият теориясе: югары уку йортлары, педагогия училищелары, колледж студентлары өчен кулланма. – Казан: Раннур, 2002. – 352 б.

## ГАЛИӘСГАР КАМАЛ –ТАТАР ТЕАТР СӘНГАТЕНӘ НИГЕЗ САЛУЧЫ

Хәкимова Р.А.,
Алабуга шәһәренең 10 нчы күппрофильле лицей укучысы.
Фәнни җитәкче: Хайбрахманова А.А.

Милли драматургия үсеше һәм театр тарихында Галиәсгар Камал исеме кабатланмас урын алып тора. Тормышында шактый катлаулы вакыйгалар, үзгәрешләр чорын кичергән әдип революциягә кадәр үк талантлы язучы булып танылa. Татар әдәбияты классигы, атаклы драматург, публицист Галиәсгар Галиәкбәр улы Камалетдинов 1879 елның 6 гыйнварында (искечә 1878 елның 25 декабрендә) Казанда үз кул көче белән көн күрүче вак һөнәрче гаиләсендә дөньяга килә. Балачагы әнисенең туган авылы Түбән Масрада бабалары тәрбиясендә уздыра. Алты яшендә авыл мәдрәсәсенә йөри башлый. Аннары, Казанга кайтып, «Госмания», «Халидия» мәдрәсәләрендә укуын дәвам итә. 1893–1900 елларда шул заманның алдынгы карашлы «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә, шул ук вакытта өч класслы рус мәктәбендә башлангыч белем ала.

XIX гасырның соңгы елларында татар телендә беренче пьесалар языла һәм драма әсәрләрен сәхнәгә куярга омтылыш көчәя. Татар мәктәпләрендә, мәдрәсәләрдә укучы Казан яшьләре һәр шимбә саен әдәбият кичәләре уздыра башлыйлар. Анда төрле язучыларның әсәрләрен укыйлар, йорт спектакльләре куялар. Татарча пьесалар аз булганлыктан, йорт спектакльләрен оештыручылар, башлыча, татар тормышына яраклаштырылган тәрҗемә әсәрләрен файдаланалар. Мондый спектакльләр зур булмаган төркем кешеләр өчен уйнала, әмма әкренләп театр сөюче яшьләр һәм профессиональ труппалар үсүгә ярдәм итә.

Г.Камал мәдрәсәдә укыган чакта ук әдәбият, театр сәнгате белән кызыксына, рус спектакльләренә йөри. «Фауст» китабын, Ф.Халидинең «Рәдде бичара кыз»ын бик яратып укый. Үзе дә, иҗат дәрте уянып, 1898 елда «Бәхетсез егет» (I вариант) исемле беренче драмасын яза. Беренче уңышы белән канатланып, төрек язучысы Н.Кәмалнең «Кызганыч бала» драмасын татарчага тәрҗемә итә. Бу елларда үз чорының актуаль мәсьәләсен яктырткан «Өч

бәдбәхет» исемле пьесасын да яза. 1900 елда Казанда бу әсәрләре аерым китаплар булып басылып чыга.

Г.Камалның таланты драматургиядә аеруча тулы ачыла. Беренче песалары булган “Бәхетсез егет” һәм “Өч бәдбәхет” кебек әсәрләрендә үк яшь драматург татар җәмгыятен борчыган мәсьәләләрне күтәреп чыга. Гаиләдә бала тәрбияләүнең мөһим булуын әйтә, кешегә карата ихтирамлы булырга кирәклекне күрсәтә, кешедәге тискәре якларны, тәрбиясезлекне, икейөзлелекне тәнкыйтьли.1905–1907 еллар революциясе елларында сатирик әсәрләр күпләп языла.Драматургиядә тулы бер юнәлеш туып, аның башында Г.Камал тора. Г.Камал үзен комик ситуация, сатирик тип тудыру остасы итеп таныта. ”Банкрот”һәм “Безнең шәһәрнең серләре”, шулай ук бер пәрдәле “Беренче театр” һәм “Бүләк өчен” комедияләре, милли әдәбиятта сатираның үрнәкләре буларак татар драматургиясенең алтын фондына керделәр.

Г.Камал мәдәниятебез тарихына драматургиягә нигез салучыларның берсе буларак кына түгел, бәлки спектакльләрне оештыручы һәм аларда катнашучы буларак та зур өлеш кертә. Билгеле булганча, 1906 елның 22 декабрендә Казанда Яңа клуб бинасында алдынгы яшьләр тарафыннан татар телендә “Гыйшык бәласе” һәм Г.Камалның тәрҗемә әсәре «Кызганыч бала» пьесалары буенча беренче мәртәбә ачык спектакль сәхнәгә куела. Аның инициаторлары Г.Камал һәм Г. Коләхмәтов була. Шушы көн әдипнең якыннан катнашуы һәм практик ярдәме белән оештырылган әлеге ачык спектакль куелу көне татар мәдәнияте тарихына татар профессиональ театрының туу датасы булып санала. Өстәвенә, Г.Камал үз кулы белән афишалар да яза, спектакльне куюда һәм бизәүдә дә актив катнаша – кыскасы, тарихи әһәмияткә ия булган бу вакыйгада төп фигураларның берсенә әверелә. Аның сәхнәдә артист булып уйнавы да мәгълүм. Озак та үтмәстән Габдулла Кариев җитәкчелегендә “Сәйяр” труппасы формалаша һәм профессиональ театрның үзәгенә әверелә. ”Театру сафыннан тәрәкъкый иттерүне үзләренә идеал итеп алган бу труппа артистлыктан башка эш илә шөгыльләнмәгәнгә, табигый инде, эч пошканнан гына театр уйнарга керешкән любительләргә кыяс итәрлек дәрәҗәдән күптән үткән вә үзенә тамашачыны күңелен җәлеп иткәндер,”–дип яза Габдулла Тукай. [Г.Тукай 1977: 44 ]

Г.Камал — татар милли театрын үстерү эшенә зур көч куйган шәхес. Профессиональ театр туу Г.Камалны иҗатка тагын да рухландыра. 1907— 1912 еллар аралыгында үзенең иң көчле, сәнгатьчә иң камил булган әсәрләрен яза. Нигездә, ул драматургиянең ике жанрында иҗат итә. «Бәхетсез егет» (1907, икенче варианты), «Уйнаш» (1910, «Өч бәдбәхет»нең үзгәртелгән варианты), «Дәҗҗал», «Каениш», «Көндәш», «Өйләнәм — ник өйләндем» кебек драмаларында җәмгыятьтәге әхлакый түбәнлек, кешелексезлек проблемалары яктыртыла. «Беренче театр» (1907), «Бүләк өчен» (1908), «Банкрот» (1911), «Безнең шәһәрнең серләре» (1912) исемле комедияләре үз чорының актуаль мәсьәләсен, тормышчан вакыйгаларны сәхнәгә күтәрү белән аерылып тора. Г.Камал театр репертуарын рус һәм дөнья классикларының әсәрләрен татарчага

тәрҗемә итеп тә баета: Н.Кәмал — «Кызганыч бала» (1900), А.Н.Островский — «Яшенле яңгыр» (1914), Мольер — «Саран» (1915), «Ирексездән табиб» (1916), «Скапен хәйләләре» (1924), Н.В.Гоголь — «Ревизор» (1916), Г.Хәмид — «Һинд кызы» (1918), А.Дюма — «Чәчәкле хатын» (1924) һ.б. Бу тәрҗемә пьесалар шул еллардагы театр сәхнәләрендә кат–кат уйнала.

Милли театр репертуарын драма әсәрләре белән баетудан тыш, Г.Камал әдәби тәнкыйть һәм уен сәнгатенә багышланган мәкалә һәм рецензияләре белән дә җитди өлеш кертә. Шул ук вакытта «Сәйяр» труппасында артист һәм режиссер булып та эшли. Татар театры тарихында актерлар династиясен башлап җибәрә: энеләрен һәм сеңлесен сәхнәгә алып килә. Соңрак улы Әнәс тә драматург, сәләтле режиссер һәм артист булып китә.Татар әдәбияты хәзинәсенә зур өлеш кертүе белән Г.Камал зур абруй казана. Аның күпьяклы фидакарь хезмәте югары бәяләнә.1923 елда Г.Камалга иҗат эшенең 25 еллык бәйрәме уңае белән “Хезмәт Батыры”, ә 1926 елда татар театрының 20 еллыгы уңае белән “Татарстан республикасының халык драматургы” дигән мактаулы исемнәр бирелә. Г Камал әсәрләре бүгенге көндә дә драматургның үз исемен йөртүче професссиональ театр репертуарының нигезен тәшкил итә.Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры – илебездәге иң популяр милли театрларның берсе.

**Әдәбият**

1. Ал яулык, зәңгәр шәл: Татар совет әдәбияты: 20–30 нчы еллар драматургиясе.–Казан: Мәгариф, 2005.– 351 б.

2. Әхмадуллин А.Г.Дөреслеккә ирешү юлында.–Казань: Татар. кит. нәшр.. 1993.–256 б.

3. Габдулла Тукай. Әсәрләр дүрт томда. 4нче том– Казан: Тат.кит.нәшр., 1977.– 432 б.

4. Галиәсгар Камал. Сайланма әсәрләр. Өч томда. 3 нче том – Казан: Татарстан китап нәшрияты, 1976.– 416 б.

5.Даутов Р.Н., Нуруллин Н.Б. Совет Татарстаны язучылары: Библиографик белешмә.– Казан: Татар.кит.нәшр., 1986.– 639 б.

## ГАЛИӘСГАР КАМАЛ ҺӘМ АНЫҢ ИҖАДИ МИРАСЫ

Хәкимова И.И.,
Казан шәһәренең
”Казан нефть һәм химия көллияте” укучысы.
Фәнни җитәкчеләре: Габдуллина Г.М.,
Ибрагимова В.Н.

Галиәсгар Камал – татар драма әдәбиятын булдыручы, татар сәхнәсе өчен күп әсәрләр биргән язучы. Шуңа күрә татар театрын Г.Камалдан башка күз алдына китереп булмас иде.

Г. Камал – драматургия остасы, күпкырлы талант иясе. Ул оста драматург кына түгел, ә театр эшлеклесе, журналист, художник, карикатурист та булып эшли. Г. Камал татар милли театрын үстерүгә зур өлеш кертә.

Г. Камалны татар драматургиясендә комедия жанрына нигез салган язучы буларак без беләбез.

Г. Камалның пьесалары татар сәхнәсендә зур урын тота, чөнки алар үз чорының актуаль проблемаларын күтәргән һәм хәзерге вакытта да актуаль булган темаларга язылган. «Бәхетсез егет», «Уйнаш» (1910), «Дәҗҗал», «Кайниш», «Көндәш», «Өйләнәм – ник өйләндем» кебек әсәрләрендә буржуаз җәмгыятьтәге фаҗигале хәлләрне сурәтли. Ә «Беренче театр» (1908), «Бүләк өчен» (1909), «Банкрот» (1911), «Безнең шәһәрнең серләрендә»(1911) шул ук җәмгыятьнең көлкеле якларын сәхнәгә чыгара.

«Беренче театр»да иҗтимагый эшчәнлек өлкәсендәге тискәре күренешләрне күрсәк, «Безнең шәһәрнең серләре»ндә дә шул тема бирелгән. «Бүләк өчен» комедиясендә Хәмидә образы байлык өчен үз улының язмышы белән уйный. «Банкрот»та җиңел юл белән акча табуга омтылган Сираҗи образы бирелә.

Г. Камал әсәрләрендә шул чорда яшәгән гади халыкның авыр тормышы югары сыйныфларның кешелексез, бозык, ялган моралена каршы куелуны ачык аңлыйбыз. Драматургның үзенчәлеге дә нәкъ менә шунда, дип уйлыйм.

Г. Камалның «Банкрот» комедиясендә XX йөз башындагы татар сәүдә бужуазиясенең акча артыннан куу юлындагы кешелексезлеге һәм түбәнлеге тасвирлана.

«Банкрот» язылган чорны яхшы белүчеләрнең истәлекләренә караганда, комедиянең прототибы Казан байларыннан Минһаҗетдин Апакаев дигән сәүдәгәр булган. Ул да шулай акылдан шашкан булып бурыч түләүдән котыла. Ләкин аның котылуы Сираҗетдиннекеннән үзгәрәк була: аны психбольницага салалар, зур взятканы ул шундагы врачларга биреп чыга. Әмма, Г. Камал бу детальләргә игътибар итми. Ул бу образда гомумән байларның алдакчы һәм комсыз кешеләр булуын фаш итә.

Бу тема бүген дә бик актуаль, чөнки банкротлык, кешеләрнең наданлыгы, байлык артыннан куып бару – бүгенге көнгә дә характерлы күренешләр.

Г. Камалның «Банкрот» комедиясе 1911 елда язылган. Акча бәрабәренә намусларын саткан кешеләрдән көлүе белән әсәр бүгенге көнгә дә аваздаш. Чөнки җәмгыятебездә бүген дә мондый кешеләр аз түгел.

Әсәр үз вакытында сәхнәгә күтәрелгәч тә тамашачы тарафыннан яратып кабул ителә. Бүгенге көндә дә Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры сәхнәсеннән төшми. Г. Карәм комедия турында: «Галиәсгар әфәнде бу әсәрендә вакыйганы бик оста тасвир итә белмеш вә моның илә бәрабәр пьесаның әшхасы бик табигый вә көлкеле итеп күрсәтелмештер. Мөхәррир әфәнде үзенең мәһарәте каләмиясе вә истигъдаты табигыясе сәясында боларның һәрберсенә аерым бер хосусият, башка бер әһәмият бирә.Шул сәбәптән, Камал әфәнденең әсәрләре безгә бик якын хис ителә»,– ди.[5.24]

Г. Камал әсәрнең нигезенә үз чорында һәм буржуаз дәүләтләрдә хәзер дә бик нык таралган күренешне – бөлү, банкротлыкка чыгу вакыйгасын алып фаҗига планында түгел, бәлки сатира, мыскыллап көлү юнәлешендә хәл итә. Шул нигездә ул гаҗәп оригиналь, үзенчәлеклек сюжет төзи. Анда байлык туплау өчен теләсә нәрсә эшләргә әзер торучы, башларын юләрлеккә салган сәүдәгәрләрнең мораль яктан череп таралуы тасвирлана.

Пьеса ике пәрдәдән гыйбарәт. Вакыйгалар Казанда, Сираҗетдин Туктагаевның йортында бара һәм Сираҗетдин образы җәмгыятьнең төп асылын гәүдәләндерү өчен алынган иң характерлы тип.

Комедиянең төп герое Сираҗетдин Туктагаев та үзен банкрот дип игълан итәргә, аз гына түләп, бурычтан да котылырга, акчалы да булып калырга уйлый. Ләкин бурыч бирә торган банкны ансат кына алдап булмый. Шуңа күрә ул сирәк очрый торган афера уйлап таба. Банктан кырык тугыз мең сум акчаны алып яшереп куя. Алай гына да түгел, алданрак тагын 120 мең банктан акча алган була. Мәскәүгә китә һәм поезда таланган, шуңа күрә акылдан шашкан булып кылана. Мәскәүдән килгән банк вәкилләре үзләре белән врач алып киләләр. Сираҗетдин врач кулына биш йөз сумны шыпырт кына бирә. Врач моны сизеп ала һәм Сираҗетдинны коткару хәйләсен таба. Нәтиҗәдә Сираҗетдин 108 мең сум табыш ала. Монда Сираҗетдинның гәҗит укып баруын искәрми булмый. Ул яңа килгән гәҗитләрнең берсен дә калдырмый укып бара. Үзенә кирәк мәгълүматны гәҗитләрдән ала. Аларны хәтта аерып җыеп бара. Монда драматург гәҗит укуның, белем алырга омтылуның файдалы якларын күрсәтә. Сираҗетдиннан тыш абыйлары уку–язуны белмиләр.

«Банкрот» әсәрендә бөлү, банкротлыкка чыгу күренеше көлкеле итеп бирелә.

Төп герой Сираҗетдин образы аркылы байларның алдакчы һәм комсыз кешеләр булуын без күрәбез.

Казан бай хатыннарының наданлыгы һәм тупаслыгы, байлар семьясының таркалырга торган булуы, приказчиклар белән хуҗалар арасындагы каршылыклар, докторларның акча өчен ялган күрсәтмәләр биргәнлеге ачык бирелә.

Тормышның актуаль мәсьәләләрен күтәргән, чынбарлыктагы тискәре күренешләр турында уйландырырлык итеп язылган бу әсәр XXI гасырда да зур әһәмияткә ия.

Гомумән, «Банкрот» комедиясен укып, XX йөз башындагы татар сәүдә буржуазиясенең акча артыннан куу юлындагы кешелексезлеген һәм түбәнлеген белдек.

**Әдәбият**

1. Гайнуллин М.Г. Камалның тормыш юлы һәм иҗаты. –Казан, 1978. –19–20 б.

2. Галиәсгар Камал турында истәлекләр// Р.Даутов. –Казан, 1979.

3. Камал Ә. Гүзәл тормыш сәхифәләре. –Казан, 1958. –80 б

4. Татар пьесалары антологиясе// Г. Камал «Банкрот». –Казан,1987. –75–114б.
5. https://kitaphane.tatarstan.ru/tat/kamal/bio1/htm

## ГАЛИАСГАР КАМАЛ – ОСНОВОПОЛОЖНИК ТАТАРСКОГО ТЕАТРАЛЬНОГО ИСКУССТВА

Храмова М.А.,
ученица 9 класса МБОУ «СОШ №13» г.Альметьевска.
Научный руководитель: Устимова Г.Ш.

Галиасгар Камал (1878–1933 г.) — татарский литератор, автор драматургических произведений, общественный деятель и основоположник театрального дела в Татарстане. Он переводил произведения русских классиков и способствовал их постановке на подмостках в родном городе. Первой опубликованной пьесой, вышедшей из–под пера будущего драматурга, стало произведение «Несчастный юноша». Галиасгар написал его в 1898 году, а в 1907–м создал вторую редакцию. 1908 году Г.Камал, совместно с татарским народным поэтом Г. Тукаем, издавал юмористический журнал «Яшен». В этот период он написал пьесы: «Первый спектакль» и «Из–за подарка». Главным лейтмотивом сочинения стали социальные вопросы и просветительские идеи, которые высказывал начинающий автор.

В 1908 году в театре прошла премьера комедии «Первое представление». Она описывала борьбу революционеров против организации национального театра. В образе главного героя выразилось все допотопное, что было ненавистно автору. После создания труппы «Сайяр» он всей душой отдался ее работе.

Активно боровшийся против феодальных пережитков в татарской жизни, Г. Камал, как представитель реалистического театра, своих героев изображает в типичной им обстановке. Он мастерски показывает жизнь татарского купечества и мещанства. Хамза из пьесы «Первый спектакль», думающий, что пристав — это все на свете, и торговец Ахметзян из пьесы «Тайны нашего города» — являются классическими образцами скудоумия, тупости и невежества. Создав яркие образы, Г. Камал оказал неоценимую услугу росту артистических сил татарской сцены. В том же году вышла пьеса «Банкрот», развенчивающая идеи о честном составлении капитала, которые пропагандировали местные представители буржуазии. Драматургические произведения Галиасгара Камала стали показательными для татарских режиссеров и актеров того периода. Его пьесы «Любодей», «Тайны нашего города», «Банкрот», «Даджал», «Родня», «Женюсь, зачем женился?» и др. не сходили и не сходят со сцены. (Он написал более 15 оригинальных больших пьес и перевел более 100 пьес классиков русской и иностранной литературы). Вместе с театральными единомышленниками писатель ратовал за развитие сценического жанра как инструмента воспитания публики и преподнесения

мировой классической литературы. Один из основоположников татарского литературного языка, Г. Камал очень много сделал в смысле очищения татарского языка от тюркизмов, арабизмов, фарсизмов. В этой области он, работая рука об руку с Г. Тукаем, действительно добился огромных успехов.

Драматург попробовал себя в роли переводчика, и на сцене театра начали играть спектакли по пьесам Максима Горького, Александра Островского, Николая Гоголя на татарском языке. Театральный деятель также писал критические очерки и статьи, делился своими идеями о реализме на сцене. Немало потрудившийся и в области публицистики, Г. Камал в первые же годы Великой Октябрьской Социалистической Революции встал на сторону рабочего класса и трудящихся крестьян и весь свой талант, все свои силы отдал революции. В годы гражданской войны Г. Камал усиленно работал в области сатиры и юмора. В последние годы жизни он работал над большими произведениями, которые ему не удалось завершить. В 1920 году ему было присвоено звание народного драматурга Татарии. В 1921 году Галиасгар познакомил публику с пьесой «Милая Хафиза», рассказывающей о положительных сторонах народной революции и изменениях, которые она повлечет в области социальных отношений.

**Литература**

1. Ахмадуллин А. Основоположник татарской драматургии – Горизонты татарской драмы: литературно–критические статьи. Казань, 1983.
2. Гайнуллин М. Галиаскар Камал – Татарская литература XIX в. Казань, 1975.
3. Гайнуллин М. Х. Татарская литература XIX века / АН СССР,Казан.фил.;ИЯЛИ. – Казань: Тат.кн.изд–во, 1975. – 307с.: ил. – Библиогр.:301–305.
4. Залесская Л.И., В. Г. Воздвиженский. – М.: Наука, 1965. – 578 с. – Библиогр.: с. 548–569.– Имен. указ.: с. 570–576.
5. Камал Г. Банкрот: комедия в 3 действиях.– Казань, 1944.– 12.

## ТАТАР ХАЛКЫНЫҢ ГОРЕФ–ГАДӘТЛӘРЕ, ЙОЛАЛАРЫНЫҢ БҮГЕНЧЕ КӨНДӘ ЧАГЫЛЫШЫ

Хуҗина З.А.,Хисмәтова К.Р.,
Алабуга шәһәре 8 нче урта мәктәбе укучылары.
Фәнни җитәкчеләре: Шакирова Л.М.,Тимофиева Л.Г.

Татар халкы үз җирлегендә барлыкка килгән һәм буыннан–буынга күчә торган гореф–гадәтләрен, кешеләрнең яшәү рәвешләрен, үз–үзләрен тоту кагыйдәләрен, карашларын, зәвыкларын сакларга омтылган.

Тормыш–көнкүрештә билгеле бер йолалар үтәү, гореф–гадәтләрне тоту һәм бәйрәмнәр үткәрү барлык милләтләргә дә хас. Ул әлеге милләт

мәдәниятенең мөһим бер өлеше булып исәпләнә. Гореф–гадәтләр борын–борыннан халык тарафыннан үтәлеп килә торган бәйрәмнәрне, йолаларны үз эченә ала. Билгеле бер йолаларның үтәлеп килүе җәмгыятьне дә тотрыклы итә, алардан башка халык тулы кыйммәтле тормыш белән яши алмый.

Халык бәйрәмнәре, йолалары кешене тормыш тәртипләренә һәм таләпләренә күнектерергә ярдәм итә. Эш шунда ки, ул бәйрәмнәрне халыкның олысы–кечесе бергәләп уздыра. Яшь буын бәйрәмдә катнашу тәртибен кечкенәдән үк өйрәнеп үсә. Һәр кеше, табигый рәвештә, үз–үзен тоту гадәтләрен үзләштерә, милли тәрбия ала.

Шулай итеп, милли йолаларыбыз, бәйрәмнәребез милли хисләр формалашуда, милли горурлык тәрбияләүдә әһәмиятле урын тоталар. Халкыбызның гореф–гадәтләре, йола, бәйрәмнәре, әлбәттә инде, буш җирлектә тумаган. Алар арасында елның төрле вакытларына, дини йолаларга, тормыштагы үзгәрешләргә бәйле барлыкка килгәннәре дә бар. Мәсәлән, безнең татар халкында елның төрле вакытлары белән бәйле рәвештә барлыкка килгән Нәүрүз (язны каршылау), Нардуган (кышны каршы алу) бәйрәмнәре ерак гасырлардан күчә–күчә хәзерге көннәргә килеп җиткәннәр. Татар халкы ислам дине белән бәйле бик күп дини бәйрәмнәрне дә олылап үткәрә. Аларның иң зурлары: Ураза гаете һәм Корбан гаете бәйрәмнәре.

Сулар аккан кебек, чорлар, еллар үткән. Татар халкы бик күп тормыш сынаулары үтеп, бүгенге көнгә дә килеп җиткән. Кайчандыр югалуга дучар ителгән милләт туган телен саклап, алга таба атлаган. Гасырлардан–гасырга, буыннан–буынга, әби–бабайдан әти–әнигә, әти–әнидән балага үзләренең борынгы бәйрәмнәрен, гореф–гадәтләрен, йолаларын югалтмыйча тапшырып килгән, һәм алар, күпмедер дәрәҗәдә үзгәреп, югалып бетә язып, безнең көннәргә дә килеп җиткән.

Гасырлар дәвамында халыкның күңеленә сеңгән йола Һәм бәйрәмнәрнең рухы безнең әдәбиятыбызда чагылыш тапкан. Күренекле шәхесләребез К.Тинчурин, Г.Бәширов, Г.Исхакый, Ф.Хөсни һәм башка язучыларыбыз иҗатында халкыбызның гореф–гадәт, йола һәм бәйрәмнәрененең бирелешен күрәбез. Алар милли хисләр формалаштыруга, милли горурлык тәрбияләүгә ярдәм итәләр. Халык бәйрәмнәре, йола, гореф–гадәтләр язучыларыбызның күбрәк авылга багышланган әсәрләрендә сурәтләнә, чөнки авыл халыкның бик борынгыдан килә торган мондый хәзинәләрен үзендә саклаучы дөнья итеп карала.

Татар халкының элек–электән килгән гаилә йолалары да бар. Бу – туй, бала туу белән бәйле, күмү һәм искә алу йолалары. Гаилә йолалары арасында иң катлаулысы – туй йолалары. Туй йолалары дигәндә, без бер туй мәҗлесен генә түгел, ә берсен берсе алыштырып килә торган тулаем бер катлаулы циклны күз алдында тотабыз. Коллективлашу чорларында туй йоласының бик күп чылбырлары өзелгән, юкка чыккан. Шулай да, тормыш күрсәткәнчә, халык йолалары алар бик яшәүчән, традицион йолаларның да борынгы һәм матур үрнәкләре төрле төбәкләрдә һәм матур әдәбиятта сакланып киләләр, кабат

торгызуны, яңартып җибәрүне, игътибарны көтеп яталар. Татар әдәбиятында бу йолаларны Гаяз Исхакый ( "Остазбикә", "Зөләйха"әсәрләре), Гомәр Бәширов ("Туган ягым – яшел бишек"әсәре), Әхмәт Фәйзи ("Тукай"романы), Фатих Хөсни ("Җәяүле кеше сукмагы", "Йөзек кашы" әсәрләре), М.Рәфыйков ("Кәләш " шигыре) һәм башка язучыларның әсәрләрендә халыкның теле һәм рухи байлыкларының бөтен нечкәлекләре, җирле үзенчәлекләре белән баетылып, шул төбәктә яшәүче халыкның җанына якын, кадерле һәм изге итеп тасвирлап бирелгән. Бу йолаларның бүгенге көн туй йолалары белән күпмедер охшаш һәм аермалы булуын да күрәбез, аларны чагыштырабыз.[Баязитова 1995: 47].

Туй йолаларына никах, кияү килү, аны каршылау, кыз алырга килү, килен төшерү, туйда үзара бүләкләшү (бирнә, мәһәр, калым, җанлы мал); туй көннәре; туйдан соңгы йолалар (яшь киленгә су юлы күрсәтү, яшь киленнең эндәшү сүзләре, тел яшерүе һ.б. ) керәләр.

Үткәннәргә әйләнеп карасак, кыз алу, кыз бирү, өйләнешүләр күпчелек очракта димче килү, димләү, кыз килешү, аклашу, ярәшүләр белән башланып китә торган булган.

Ничек булган соң ул кыз димләү, яучы яки башкода булып килү? Димче, яучы итеп авылда дәрәҗәле, ышанычлы, сүзгә оста, үтемле итеп сөйли. Сер саклый торган кешене җибәргәннәр. Кыз димләүнең, ике гаилә арасында булган сөйләшү–килешүләренең үзенең тәртибе булган, әдәп, бер–берсенә ихтирам саклау, хәтер калдырмау, араларны якынайтырга омтылуны чагылдырган төрле серле, тылсымлы йолалар, үткен сүзләр кулланылган.

Кыз ярәшү – борынгыдан килгән матур йолаларның берсе. Ул димче, яучылар килеп, кызны бирергә ризалык алу белән генә бетми, ике якның вәгъдә бүләкләре алмашуы белән дә ныгытыла. Гадәттә, кыз ягыннан, вәгъдә бүләге итеп, кызның үзе чигеп, үз кулы белән сугып яки тегеп әзерләп куйган әйберсе – сөлге–ашъяулык бирелә торган булган.

Никах өйләнешүне, гаилә төзүне шәригатьчә, махсус дога укытып беркетү йоласы. Никах мәҗлесе, никах туе кыз өендә үткәрелә, анда олы кешеләр, картлар, егетнең һәм кызның әти–әниләре, туганнары була. Никах мәҗлесе тыныч, салмак, изгелек һәм бәхет теләү сүзләре белән уздырыла. Анда исерткеч эчемлекләр куелмый, туй ашамлыклары белән бергә, йола ашы итеп бал–май, баллы су–ширбәт куела. Никах йоласын халкыбыз изге итеп саный, тылсымлы көчкә ия итеп ышана.

Туй йолаларының тагын берсе – бу кияү килү, аны каршылау һәм кияү keләте әзерләү булган. Туй килгәч, кияүне кыз янына керткәннәр. Кияү белән кыз очрашкач, кияүнең билбавын чишү, читеген салдыру һәм башка шундый сынау йолалары башкарылган. Кайсы җитезрәк һәм өлгеррәк булса, гаиләдә шул баш булачак саналган [Уразман1992: 27].

Кыз алырга килү, килен төшерү, туйда үзара бүләкләшү, туй көннәре, туй ашамлыклары белән бәйле йолалар бүгенге көннәрдә дә сакланып калган һәм үтәлә дә. Күркәм гаилә йолаларының берсе булган туй йолалары халык өчен әһәмиятле һәм гаилә коруга үтә җаваплы караган, аның ил каршында, җәмгыять

каршында үтәлергә тиешле гадәт һәм әхлак нормалары, йолалары калыплашкан. Йолалар белән бергә, аларга караган бик күп сүзатамалар, гыйбарәләр йола белән бергә үрелеп яшиләр.

Шулай итеп, йолалар халыкның тарихы белән үтә тыгыз бәйләнештә. Телдә диалекталь, ягъни җирле үзенчәлекләр булган кебек, халыкның рухи культурасы да җирле үзенчәлекләр белән баетыла, ул җирле үзенчәлекләр шул төбәктә яшәүче халыкның җанына якын, кадерле һәм изге була.

Минем уйлавымча, гореф–гадәт, йола һәм бәйрәмнәребезнең чагылыш тапкан әдәби әсәрләребез безнең тарихыбызның бер гүзәл әдәби мирасы да.

Мирас...Ул буыннан–буынга күчеп килә торган байлык. Йола, гореф–гадәт һәм бәйрәмнәребез безнең рихи мирасыбыз, байлыгыбыз. Матди байлык ул – фани, бетә торган, вакытлы нәрсә, ә рухи байлык, акыл көче белән хасил булган дөньяга караш, кешеләрнең мөгалләмәсе, гореф–гадәте – мәңгелек. Мирасның иң кадерлесе бербөтен халыкның гомуми җанына сеңеп кала, аның телендә, әдәбиятында, гореф–гадәтендә, буыннан–буынга күчеп килгән йолаларында, бәйрәмнәрендә саклана. Ул мирас буыннан–буынга тарих чылбыры булып үрелеп барсын иде.

Кыскасы, безнең максатыбыз туган телебезне, тарихыбызны, рухи байлыкларыбызны, гореф–гадәтләребезне өйрәнеп, буыннар арасында ныклы бәйләнеш булдыру, бөек милләт булып яшәвебезне дәвам итү [Җәмәлиева2000: 30].

Татарстан халыкларының үзара дус, тату яшәве – бөтендөнья өчен толерантлык үрнәге булып торуын да күрсәтә. Халыклар арасында дуслык бәйләнешләрен ныгытуда бәйрәмнәрнең роле зур, чөнки алар аша халыклар бер–берсенең мәдәниятен, яшәү рәвешен, гореф–гадәте, йолаларын өйрәнә һәм шулар аша бер–берсенә хөрмәт тәрбияли, үз итә, дуслыгын ныгыта.

Бүгенге көндә милли бәйрәмнәребезне, йола, гореф–гадәтләребез яңадан торгызылып, яңартылып, заман төсмерләре биреп үткәрелә башлады. Аларны халык белә, хөрмәт итә икән милләт яши, милләт яшәгәч, тел яши, ягъни тормыш дәвам итә.

**Әдәбият**

1.Баязитова Ф.”Татар халкының бәйрәм һәм көекүреш йолалары”,1995.
2. З.Ә .Җәмәлиева “Татар халкының йолалары һәм бәйрәмнәре”, 2000.
3.Уразман Р. “Татар халкының йолалары һәм бәйрәмнәре”, 1992.

# ФРАЗЕОЛОГИЗМЫ С КОМПОНЕНТОМ «ЗӘҢГӘР/ BLUE» («СИНИЙ») В ТАТАРСКОМ, АНГЛИЙСКОМ ФОЛЬКЛОРЕ

Хусаенова А.С.,
Ученица МБОУ «СОШ№7" г.Набережные Челны.
Научный руководитель: Миннахметова Р.Р.

Фольклор – это процесс и результат творчества народа, сопровождающего его на протяжении всей жизнедеятельности, основа любой национальной культуры, из которой вырастает профессиональное искусство. В фольклорных текстах татарского и английского языков фразеологизмы с цветовым компонентом часто встречаются.

Семантика синего (голубого) цвета наиболее широко представлена во фразеологии английского языка, а в татарском языке фразеологизмы, содержащие синий (голубой) цвет, немногочисленны, что свидетельствует о невысокой продуктивности этого цвета при создании фразеологических единиц татарского языка. Например, синий (голубой) цвет символизирует что-то недостижимое, идеал или мечту: blue rose - (букв. «синяя (голубая) роза») - что-то недостижимое; голубая мечта, зәңгәр хыял - 1) горячее, заветное желание, часто недостижимое; 2) предмет заветных желаний и устремлений. *Зәңгәр бака үз сазын танымас* – синяя лягушка не узнает своего болота [Исәнбәт 1983:160].

Образ синей птицы во фразеологии английского и русского языков ассоциируется со счастьем: blue bird (of happiness), синяя птица - то, что воплощает для кого-либо идеал счастья. Эти обороты вошли в употребление из пьесы М. Метерлинка, сюжет которой заключается в поисках синей птицы как символа «тайны вещей и счастья». Тот, кто ее найдет, приобретет способность все знать и видеть.

Прилагательное «голубой» в сочетании с существительным «кровь» обозначает высокое социальное происхождение и аристократию в английском и русском языках: blue blood (или blooded), голубая кровь (голубой крови гаи голубых кровей) - аристократическое происхождение, аристократ. Фразеологизм «голубая кровь» русского языка является калькой французского фразеологического оборота «le sang bleu», который, в свою очередь, заимствован из испанского языка (образован от фразеологической единицы «la sangre azul»). Первоначально этот оборот обозначал аристократические семьи испанской провинции Кастилья, которые кичились «чистотой своей расы" и не заключали смешанных браков с маврами и другими людьми со смуглой кожей, а так как вены белокожих людей видны отчетливее, их кровь казалась голубой.

True *blue* will never stain/ (букв. истинно *синий* цвет никогда не испачкается) «Старый друг лучше новых двух". Дословно: истинно *синий* цвет никогда не испачкается [Кузьмин 1996: 254].

*Blue* are the hills that are far from us/ букв. *синие* холмы, которые находятся далеко от нас. Там (везде) хорошо (хорошо там), где нас нет [Кузьмин 1996: 258].

Is the devil any better than the deep *blue* sea (букв. разве дьявол лучше глубокого *синего* моря) / Хрен редьки не слаще [Кузьмин 1996: 276].

A blump on the head will still *be blue* whether you do it yourself or it's done to you (букв. шишка на голове все равно останется *синей*, независимо от того, сделаете вы это сами или это сделают с вами.)/ Что в лоб, что по лбу [Кузьмин 1996: 290].

Between the devil and deep *blue sea* (букв. между чёртом и глубоким *синим морем*.)/ Между двух огней. Взят из истории: в начале XVII века у моряков «дьяволом» назвалась доска, прикрепленная к борту судна и служившая опорой для орудий. Иногда моряки вынуждены были выходить на нее, чтобы залатать бреши в корпусе судна. Даже когда море было спокойно, все равно существовала значительная опасность упасть в воду и утонуть. Поэтому нахождение между "дьяволом" и открытым морем было довольно рискованным мероприятием.

Семантика синего (голубого) цвета наиболее развернуто представле на во фразеологии английского и русского языков, где имеется широкий спектр ассоциативных представлений, связанных с этим цветом. В татарском языке обороты, содержащие синий (голубой) цвет, немногочисленны.

**Литература**

1. Исәнбәт Н.С. Татар халык мәкальләре. – 2-нче басма – Казан: Татар.кит.нәшр.,1963, 16 б.
2. Кузьмин С.С., Шадрин Н.Л. Русско-английский словарь пословиц и поговорок: 500 единиц. – Спб.: МИК/ Лань, 1996. – С 126.
3. Татар халык иҗаты: мәкальләр һ. әйтемнәр / СССР ФА Казан фил., Г. Ибраһимов исем. ТӘһТИ; [редкол.: И. Н. Надиров (җит.) һ. б.; томны төз. Х. Ш. Мәхмүтов]. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1987. – 592 б.

## ТАТАР ТЕЛЕ ДӘРЕСЛӘРЕНДӘ ТЕРМИННАРНЫ ӨЙРӘНҮ АЛЫМНАРЫ ҺӘМ ЫСУЛЛАРЫ

Шәйхетдинова К.Р.,
КФУның Алабуга институты студенты.
Фәнни җитәкче: Камаева Р.Б.

Лингвистик терминологияне белү, аңлау – укучыларның орфографик грамоталыклылары формалашуның, төрле стильләрдә язылган әсәрләрне укый һәм анализлый белү күнекмәләренең үсешенең мөһим бер шарты булып тора. Нәтиҗәдә болар Бердәм дәүләт имтиханнарының уңышлы тапшырылуына да зур адым буларак танылалар. Әмма эш нәтиҗәле булсын өчен, терминнар белән

эш эпизодик характерда түгел, ә системалы рәвештә алып барылырга тиеш. Татар теле дәресләрендә терминнар белән еш эшләргә туры килгәнлектән, һәр дәрескә диярлек терминологиягә кагылышлы биремнәрне кертергә мөмкин. Бу эшебездә без моның кайбер юлларын, алымнарын тәкъдим итүне максат итеп куйдык. Игътибарны шуларга юнәлтик:

1) укучыларны урта сыйныфлардан ук терминологик диктантлар яздыру эшенә тарту нәтиҗәле алым булып тора. Алынма сүзләр темасын үткәннән соң, рус һәм рус теле аша европа телләреннән кергән лингвистик һәм әдәби терминнардан файдалану отышлы. Бу очракта рус теле, рус әдәбияты белән дә метапредмет бәйләнешләре барлыкка килә, терминнарның дөрес язылышын күңелдә беркетеп калу балага шул фәннәрдә дә орфографик грамоталылыгын арттырырга ярдәм итәчәк. Мәсәлән, урта сыйныфларда түбәндәге сүзләрдән торган терминологик диктант тәкъдим итәргә мөмкин:

*Пейзаж, конфликт, автор, лирика, юмор, диалог, синтаксис, диалект, интонация, цитата, текст, неологизм, сленг.*

2) укучыларның орфографик грамоталылыгын арттыруда түбәндәге биремнәрдән файдаланырга мөмкин:

Күп нокталар урынына, кирәкле дип тапкан очракларда, төшеп калган хәрефләрне куегыз һәм күчереп языгыз:

*Дас...тан, фигыл..., орфограм ... а, дефис..., рә...еш, а...ергыч, бал...ада, инфинити..., аф...икс, грам...атика.*

3) терминнар белән аңлап эш итүләрен тәэмин итү өчен, таблицаны тутырырга тәкъдим итәргә мөмкин:

Терминнарны таблицаның тиешле графаларына тутырып языгыз: *туры сөйләм, кереш сүз, җөмлә, хәл, эндәш сүз, ия, пунктуация, диалог, хәбәр, синтаксис, тәмамлык, сүзтезмә, аергыч, тиңдәш кисәкләр.*

| Татар теле гыйлеменең бүлеге | Синтаксик берәмлекләр | Җөмләнең баш кисәкләре | Җөмләнең иярчен кисәкләре | Җөмләне картлауландыручы берәмлекләр | Сөйләмне тапшыру ысулы |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | |

4) укучылар терминнарны дидактик уеннар вакытында яхшы истә калдыралар. Мәсәлән, татар теле дәресләрендә "Терминологик лото" уенын оештырырга мөмкин. Укытучы укучыларга номерлар язылган карточкалар тарата, капчыктан мичкәләрне чиратлап тартып ала һәм мичкәнен номерын әйтә. Мичкә номеры белән карточка номеры туры килгән укучы сорауга җавап бирергә тиеш була. Сорауны укучы "әйе" яисә "юк" дип җавап бирерлек итеп тәкъдим итү максатка ярашлы. Дөрес җаваплар презентацион материал ярдәмендә тикшерелә. Эш өчен сорауларны мөгаллим алдан үзе уйлап килергә тиеш. Әйтик, 7 нче сыйныфта "Морфология" бүлеген узганда, түбәндәге сорауларны тәкъдим итәргә мөмкин (сораулар Р.К. Сәгъдиева авторлыгындагы дәреслектәге терминнарга нигезләнеп төзелде):

- Теркәгечләр сүзләрне һәм җөмләләрне үзара бәйлиләр. Дөрес әйтемме? (Әйе);

- Теркәгечләр мөстәкыйль сүз төркеменә карыйлар. Дөрес әйтемме? (Юк);

- Боерык фигыльләр затланышлы фигыльләр булып торалар. Дөрес әйтемме? (Әйе);

- Килсә, эшләсә, тешләсә, уйнаса – шарт фигыльләр. Дөрес әйтемме? (Әйе);

- Шарт фигыльләр зат-сан белән төрләнә. Дөрес әйтемме? (Әйе);

- Да-/дә, -та/-тә теркәгечләре урын-вакыт килеше кушымчалары белән аваздаш. Дөрес әйтемме? (Әйе);

- Модаль сүзләр зат-сан белән төрләнәләр. Дөрес әйтемме? (Юк);

- Укыдым бит, белдем ич, әйттем ләбаса - барлык бу очракларда кисәкчәләр икеләнүне белдерәләр. Дөрес әйтемме? (Юк);

- Кайбер кисәкчәләр мөстәкыйль сүзгә кушылып язылалар. Дөрес әйтемме? (Әйе) [Сәгъдиева 2017: 215]

5) модель төзү алымыннан файдалану да максатка ярашлы. Фигыльләрнең ясалышы, төзелеше балаларда еш кына авырлык тудырганга, бу очракта да укытучы дәрескә җитди әзерлек белән килергә тиеш. Безнең фикеребезчә, дәрестә эшчәнлекле якын килеп укыту өчен актуаль булган модельләштерү методын куллану отышлы була. Укучыларга терминнарны өйрәнү җиңел түгел, алар күбрәк фикер алышу, әңгәмә кору, уен алымнарына корылган дәресләрне үз итәләр. Әмма барлык бу дәрес төрләренең продуктив оештырылуы балаларның терминнарны аңлау, алар белән эш итүне таләп итә.

**Әдәбият**

1.Әхмәтьянов Р.Г. Татар терминологиясенең тарихи чыганаклары. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2003. – 174 б.

2.Сафиуллина Ф. С., Зәкиев, М. З. Хәзерге татар әдәби теле / Ф.С. Сафиуллина, М.З. Зәкиев. – Казан: Мәгариф, 2002. – 407 б

3.Сәгъдиева Р.К. Татар теле: рус телендә төп гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен туган тел буларак өйрәнүчеләр өчен) 7 нче с-ф / Р.К. Сәгъдиева, Г.Ф. Харисова, Л.К.Сабирҗанова, М.Ә.Нуриева. – Казан: Мәгариф – Вакыт, 2017. – 215 б.

## Г.ТУКАЙ ИҖАТЫНДА ЭКОЛОГИЯ

Шәйхетдинова Э.Т.,
“Иннополис лицее”ның 11нче сыйныфы укучысы.
Фәнни җитәкче: Евсеева Л.Р.

Туган туфракка сабый чакта җибәргән тамырлар гына кешене ватанлы итә, хәерле итә, бәхетле итә. Табигать баласы икәнлегеңне тою нәкъ шул чорда башлана.... Нәни Габдулла да кечкенәдән Кырлай табигатенә,урманнарына, малайлар белән бергә ат көткән болыннарына, сихри күккә ашкан төз

чыршыларга гашыйк була. Әтисе Сәгъди абзый бик олы җанлы ,эшлекле татар крестьяны булганга, нәни Габдулланы үзе белән бергә игенчелек эшләренә тарта башлый. Крестьян хезмәте авыр булса да, аның ләззәтен таба ул:көн үзәгендә басудан кайткач, буага төшеп су керүләр, баздан катып алып менеп чишмә суына болгатып эчүләр – кичләрен Кырлай урманнарында җыр, моң – болар барысы да Тукайны шагыйрь иткән иң әһәмиятле шартлар.

Җирнең матурлыгын, һаваның сафлыгын саклау мәсьәләләре бөек шагыйребезне кечкенәдән борчыган. Ул бу турыда уйланган, шул хакта күп кенә әсәр иҗат иткән. Шагыйрь фикеренчә, дөнья матур, шушы матурлыкны күп вакыт кеше үзе бетерә. Аның иҗатында кеше яшәгән бердәнбер урын буларак, Җир күпмегә түзәр икән, дигән хафалану да чагыла. Шулай да Г. Тукайның табигатькә, туган ягына багышланган шигырьләре саф табигатькә дан җырлаудан гыйбарәт. Аның кичерешләре дә табигать белән чагыштырыла.

И күңелнең шаулап аккан чишмәдән сафрак чагы!

И гомернең нурланып үскән яшел яфрак чагы! (“Сагыныр вакытлар”)

Шагыйрьне илһамландыручы да табигать үзе. Туган ягына мәхәббәтне дә Тукай табигатьне сурәтләүдән башлый. Ул эчкән суга зур әһәмият бирә. Кешенең бөтен гомере су белән бәйле. Бер “кечкенә генә инеш” (“Шүрәле”) бөтен авылны саф су белән тәэмин итеп тора.

Г. Тукай үз ягының урманнарына чын күңеленнән гашыйк. Ул яхшы белә: урман саф һава чыганагы да, бетмәс–төкәнмәс байлык та. Аның фикеренчә, урман – саулык, байлык сандыгы. Шагыйрьне һәр кош, чәчәк агач илһамландыра. “Чыршы” шигырен генә алыйк. Авторда ул табигатьнең мәңге яшь булуын дәлилләүче образ буларак бирелә.

Үз төсен үзгәртми саклаучы арада берсе бар:

Көз көне һәм кыш буе саргаймый торган чыршы бар.

“Ай һәм Кояш”, “Яз галәмәтләре”, “Җәй көнендә” шигырьләре шагыйрьне табигатьнең һәр гамәле урынлы булуына соклануын белдерә. “Яратырга ярый” шигырендә исә табигатьнең күп вакытта кешегә дә бәйле булуы искәртелә. Кеше еш кына табигый матурлыкка тап төшерә.

Яратырга ярый дөнья: матур кырлар, матур таулар;

Яратмыйм мин вәләкин һич, сәбәп шул: ибне адәм бар! (“Яратырга ярый”) – дип, шагыйрь кешенең табигый агымга тыкшынуы матур нәтиҗәләргә китермәскә мөмкинлеген искәртергә тели кебек. Әлеге фикерләр “Һәркемнең ашыйсы килә” һәм “Япун хикәясе” шигырьләрендә дә дәвам иттерелә.

Г. Тукай табигатьнең һәр фасылын, һәр мизгелен үзенчә күрә. Аны табигатьтәге үзгәрешләрнең кеше ихтыярыннан тыш булуы шатландыра. “Җир йокысы”, “Яз галәмәтләре”, Буран”, “Яңгыр”, “Яз хәбәре”, “Елның дүрт фасылы” шигырьләрендә автор кабатланмас бизәкләр белән бөтен табигать мизгелләрен күз алдында җанландыра.

Тукайның “Буран” шигыре 1912 елда «Җан азыклары» җыентыгында басылган. Ул Тукайның табигать лирикасында иң күренекле урыннарның берсен алып тора. Тыныч яткан юлны үлгән еланга, буран котыруын бихисап

зур мендәрдән очкан йоннарны куып йөгерешкән җеннәргә охшату табигать стихиясенең хәтәр куәтен төсмерләтә.

Әллә ычкынганмы баудан Каф тау арты җеннәре?

Йә тишелгәнме ходайның бихисап зур мендәре? (“Буран”)

Яз, аныңча – “матур кыз”, “язның алтын фәйтуны”, “гөлләр патшасы”; кыш – аксакал”, аның матурлыгы чиксез – “һәр ягында аллы–гөлле күбәләктән гаскәре” (“Кышка бер сүз”). “Яз җитә”, – дип әйтәсе урынга шагыйрь болай ди:

Күпме февраль, каш җыерсаң һәм ачулансаң да син,

Барыбер, ди, җитте яз һәм рухына кышның ясин.

Яуса да карлар, табигать эшли инде үз эшен;

Тиздән иснәрбез кызыл, ал–гөл чәчәкләрнең исен. (“Яз хәбәре”)

Г.Тукай үз иҗатында табигатьнең “тере почмагына” мәрхәмәт иясе тәрбияләргә тели. Табигатькә ямь өстәүче, аны җанландыручы кошларга зур урын бирә, аларны гөнаһсыз фәрештәләр белән тиңли. “Карлыгач”,”Карга”, “Кошчык”, “Күгәрчен”, “Фатима белән Сандугач” шигырьләре аша шагыйрь балаларны кечкенәдән үк кошларны яратырга, аларга мәрхәмәтле булырга куша. Кошларның табигатькә бик күп файда китерүенә басым ясый, аларның иркендә генә матур итеп сайрый алуын әйтә. “Фатима белән Сандугач” шигырендә читлектәге кош ирек турында:

Белмисеңме син: читен мәхбүслек ул,

Булса да алтын, һаман да читлек ул, – дип әйтә.

“Кошларга” шигырендә исә:

Әллә иркендә торуның кадерен белмимме мин?! – ди.

Ә инде иң кечкенә балаларга язылган “Бала белән Күбәләк” шигыре балага гомерлек үгет–нәсихәт булырлык. Күбәләк баладан:

Бул яхшы, рәнҗетмә

Һәм тимә син миңа! – дип ялвара.

Күбәләкнең бу сүзләре һәркемнең күңелендә калырга тиеш. Шагыйрь шуны тели.

XX гасыр башында промышленность үсә башлый. Казан авыл кешеләрен җыя. Завод–фабрикаларда эшләү өчен кешеләр кирәк. Саф табигать кочагыннан шәһәргә килгән кеше тынчу, пычрак мохиткә эләгә. Бу хәл шагыйрьне борчуга сала. Сәнәгать үсеше табигый матурлыкка зыян китерә.

Ут, төтен, фабрик–завод берлә һаман кайный Казан;

Имгәтеп ташла савын, сау эшчеләр сайлый Казан. (“Казан”)

Г.Тукай табигатьне ярата, аның һәр күренешенә, җан иясенә саклык белән, яратып карый. Кешеләрне дөрес яшәргә чакыра. Бүгенге көн белән генә яшәүнең табигатькә зур зыян салуын искәртә. Бу җәһәттән аның “Толстой сүзе” шигыре бик урынлы.

Кирәк анчак яшәр микъдар ашарга,

Кирәкми тик ашарга дип яшәргә.

Йомгаклап шуны әйтәсем килә: бөек шагыйребез яшәү йортыбыз булган Җир һәм анда яшәүчеләрнең тормышлары өчен борчылган. Ул табигатьнең

кешегә яшәү өчен матди мөмкинлекләр дә, иҗат өчен илһам да бирүен дөрес аңлаган. Экологиянең чикләре бик киң. Тукай бу мәсьәләгә дә төрле яктан якын килә. Әйтелгән фикерләр шагыйрьнең бик күп әсәрләрендә чагылыш тапканын күрдек. “Сагыныр вакытлар” шигыре үзе генә дә әдипнең җирдәге матурлыкның сагында торучы зур Кеше икәнлеге турында сөйли.

Чәчмәгән җир күк – күңелнең һәр гүзәлгә бушлыгы,
Тик кояшны һәм табигатьне сөюдән хушлыгы!

Әдәбият

1. Мин Тукайга киләм. – Казан: Тат.кит.нәшр., 1996;
2. Нуруллин И. Тукай. – Казан: Тат.кит.нәшр., 1979;
3. Рәсүлова З. Тукай эзләреннән.– Казан: Тат.кит.нәшр., 1985;
4. Сайланма әсәрләр. Шагыйрь турында истәлекләр.– Казан: ”Хәтер”, 2002.

## Г.КАМАЛНЫҢ “БЕРЕНЧЕ ТЕАТР” ДРАМАСЫНДА ЮМОРНЫ ОСТА КУЛЛАНУЫ

Шәйхиева И.,
“Г.Тукай исемендәге Арча педагогия көллияте”студенты.
Фәнни җитәкче: Шаһиева Д.Г

Татар язучылары арасында күпьяклы талантлар бар. Без әдәбият дәресендә өйрәнгән язучылардан берсе – Г. Камал иҗаты бигрәк тә аерылып тора. Ул – татар әдәби мирасына зур өлеш керткән драматург. Аның әсәрләре – һәрберсе милләт, ил язмышына, телебезгә битараф булмаган оста каләм иясе белән язылган хәзинәләребез.

Теманың актуальлеге шунда: авторның драмаларын укыганнан соң, бүгенге көндә дә үз тормышларын гына кайгыртып, уйламаганда, көлкеле ситуацияләргә калган кешеләрне очратырга мөмкин.

Г.Камал иҗатының күп тармаклы булуы тагын бер яңа өлкәдә–театр сәнгатендә тулы ачыла. Аның роле иң әүвәл драматург буларак бәяләнә. Әхлакый мәсьәләләргә драматург бигрәк тә комедияләрен багышлый, бу мәсьәләләрне көлү аша, сатира ярдәмендә хәл итә.Аның иң яхшы әсәрләре дә комедия жанрына карый. Язучы үзенең әсәрләренә үзе өчен генә кайгыртып, башкаларны кимсетеп караучылардан; бүтәннәр исәбенә, үзенә яхшы тормыш корырга ният иткәннәрдән мыскыллап көлә, аларны тәнкыйтьли.

Комедияләре белән ул үз чорында яшәп килгән иске гадәт–йолаларның тискәре якларын фаш итә. Һәртөрле яңалыкны аңламаган һәм аңларга теләмәгән, байлык артыннан куып, кешелек сыйфатларын җуйган кешеләрне көлү объекты итеп ала. “Беренче театр” комедиясендә Г.Камал сәхнә сәнгате туып кына килгәндә, аны кемнең ничек кабул итүен тасвирлый. Берәүләр, театрга баруны, анда уйнап күрсәтелгән гыйбрәтле хәлләрне карарга омтыла. Икенчеләр исә, бу эш гөнаһ, ярамаган, бозык эшкә саный.Аларның шундый капма–каршы карашлары арасында калганнарга да җиңел түгел.

.Иске фикерле Хәмзә карт шәһәрдә театр куярга теләүләрен белгәч, үз ишләре белән аны булдырмас өчен тырышып йөри. Ә баксаң, шул арада аның үз өй эчендәгеләр барысы да театрга киткәннәр икән!

Автор бу драмасында юморны ничек тудырган соң? Әсәрне укый башлаганда ук, без Вәли белән Биби арасында килеп чыккан конфликттан көлкеле ситуация барлыкка килүен күзәтәбез.

*Биби. Тыңлыйм ич!*

*Вәли. Тыңласаң, шул: менә без хәзер театрга китәбез...*

*Биби. Кая?*

*Вәли. Театрга!*

*Биби. Нәрсә төятергә?*

*Вәли. Мин сиңа төятергә димим, театрга дим, аңладыңмы, театрга дим!* [Камал, б.32].

Бу җөмләләрдә Бибинең надан икәнлеген автор *театрга–төятергә* дигән охшаш яңгырашлы сүзләр белән оста гына укучыны көләргә мәҗбүр итә. Гафифә, театрга әзерләнгәндә, егермеләп күлмәкне төсләре, материяләре һәм тегелү формалары белән санап чыгуга карамастан, театрга киеп барырлык килешле күлмәк таба алмавын Г.Камал бу образга да оста гына итеп кызыклы җөмләләр уйлап таба алган. Мәсәлән, Гафифә болай ди: *"үзең дә ичмасам бер кеше төсле чибәр күлмәк алып биргәнең дә юк. Бер җиргә бара башладың исә,киеп барырлык һичбер күлмәгем юк"*–дип иренә үпкәли.

Хәбибрахман белән Факиһәнең дә театрга әзерләнүләре көлке тудыра. Хәбибрахман ир кеше булса да, театрга барырга курка һәм нинди генә хәлләр уйлап чыгармый. Аның театрга бармас өчен диван артына качуы да, күседән куркуы да тамашачыны көләргә мәҗбүр итәләр.Мәсәлән,

*Хәбибрахман. Бармыйм дигәч, бармыйм инде! Иң әүвәл мин аның, ул театрның кайда икәнен белмим.*

*Факиһә. Бу булды бер!*

*Хәбибрахман. Икенчеләй, кайдан керәсен, ничек керәсен белмим.*

*Факиһә. Ике, өч.*

*Хәбибрахман. Анда кергәч тә, нинди урынга утырырга?*

*Факиһә. Шуның белән була дүрт! Зинһар, ичмаса инде, эчеңдәге бар серләреңне сөйләп бетереп, кешене көлдермә; кеше ишетсә, «моның белгән нәрсәсе бар микән?» ди башларлар. Кеше җаен тапканны, без генә табарбыз әле.*

*Хәбибрахман. Кирәкми, бармыйбыз; мин куркам* [Камал,б.41].

Бу өзекләрдә автор , инде үзе картайган, ләкин һаман да этисенә буйсынып яши, аның һәрбер сүзен тыңлый торган Хәбибрахманнан көлә.

*Факиһә. Әйтә белдеңме соң?*

*Биби. Ник белмәскә, белдем.*

*Факиһә. Күп телеңә салынма. Яхшы тыңла. Әгәр дә эткәй сораса «кая киттеләр?» дип, «кодаларга киттеләр» диген.*

*Биби. Ярый, ярый, аңладым: «Икесе дә шунда киттеләр», диярмен*

[Камал, б.51].

Монда автор Биби белән Факиһә арасындагы конфликтлы ситуацияне көлкеле хәл ярдәмендә күрсәтергә тели.

Алга таба да без аның бу драмасында көлке белән язылган җөмләләрне күп очратабыз. Димәк, Г.Камал төрле вакыйгаларны оста гына сатира ярдәмендә хәл итә алган . Шуна күрә дә аны комедия остасы дип йөртәләр.

Галиәсгар Камалның исемен һәр кеше истә тота. Чөнки бүген татар сәхнә сәнгатенең әйдәп баручысы булган Татар дәүләт академия театры да Галиәсгар Камал исемен йөртә. Без моның белән горурланабыз.

**Әдәбият**

1. Галиәсгар Камал турында истәлекләр. Төзүчесе Рәис Даутов. Казан , Татар. кит. нәшр., 2003.

2. Камал, Г.Г. Әсәрләр: 3 томда / Галиәсгар Камал.–Казан : Татар.кит.нәшр., 2010.

## ГАБДУЛЛА ТУКАЙ ИҖАТЫНДА ӘХЛАК ТӘРБИЯСЕ.

Шәкүрова К.А.,
Алабуга шәһәре 10 нчы күппрофильле лицее укучысы.
Фәнни җитәкче: Минһаҗева Р.М.

Ишеттем мин кичә : берәү җырлый.
Чын безнеңчә матур, милли көй;
Башка килә уйлар төрле–төрле–
Әллә нинди зарлы, моңлы көй,
– дип язды татар халкының бөек шагыйре Г.Тукай.

Бөек халыкның бер улы буларак , Тукайны милләт мәсьәләсе борчыган.Ул телебезне саклап калу өчен көрәшкән.Тукай үзенең гомерен, тормышын, яшәешен милләт язмышы белән бәйләгән.Билгеле, милләт мәсьәләсе, тел язмышы бүгенге көндә дә иң зур проблемаларның берсе. Г. Тукай үзенең “Туган тел” шигырендә ана теленең бала тәрбияләүдә тоткан урынын бөтен җитдилеге белән ачып бирә. Телебез юкка чыгу алдында торганда аның туган телгә мөнәсәбәте аеруча әһәмиятле. Сөекле Тукаебыз да заманында телебезне хөрмәтләп, яратып: “И туган тел, и матур тел, әткәм–әнкәмнең теле! Дөньяда күп нәрсә белдем син туган тел аркылы”,–дип язган.Газиз туган телебез турында моннан да матуррак итеп әйтеп буламы соң инде. Шагыйрьнең милләтне артка сөйрәүчеләрне , наданнарны шәпләп тәнкыйтьли торган үткен каләме була.Г.Тукай милләтнең белемле, алдынгы карашлы, әхлаклы булуын тели. Дәресләрдә “Эшкә өндәү”,”Туган авыл”, “Бәхетле бала”, “Кошларга”, “Карлыгач”, “Бала белән күбәләк”, “Кызыклы шәкерт”, “Сабыйга”,”Таз” шигырьләрен яратып укыйбыз. Шагыйрь балаларны эш сөяргә, белем алырга, яхшы укырга, хайваннарны, кошларны сакларга,табигать матурлыгын күрә белергә, кылган гамәлләрең өчен җавап

бирә белергә чакыра. “Әдәп төбе – матур гадәт”, ди халык. Кешедә формалашкан гадәтләр һәм әхлакый кыйммәтләр тәрбия нәтиҗәсе. Ә тәрбия, шәхеснең камилләшүе туктаусыз процесс. Кечкенә бала өлкәннәр арасында урнашкан җылы мөгамәләне, матур мөнәсәбәтләрне беренче мәртәбә гаиләдә күрә. Әдәп, әхлакый сыйфатларның яралгылары да гаиләдә салына. Г. Тукай үзенең шигырьләре белән сабыйларны катлаулы җәмгыять тормышына алып керә. Ул аларны уңай һәм тискәре хәлләр, уңай һәм тискәре геройлар белән йөзгә–йөз очраштыра. Күңелле хәлләр, уңай геройлар укучыда шатлык, куаныч хисләре уята. Ә ямьсез, күңелсез хәлләр, тискәре геройлар, аларның кылган гамәлләре, киресенчә, нәфрәт уята. Балаларда уңай геройларга охшау теләге искиткеч көчле. Г. Тукай шигырьләренең тәрбияви асылы да шунда. Ул әдәп, әхлак тәрбияләү проблемаларына кагылышлы изге теләкләрен балаларның рухи дөньясына, күңеленә җиткерү өчен нинди үтемле юллар сайлаган. Матур гадәтләр, әдәплелек, шәфкатьлелек “Бәхетле бала” шигырендә бик әйбәт чагылыш тапкан:

“Бәхетле шул баладыр, кайсы дәресенә күңел бирсә,
Мөгаллимне олуг күрсә, белергә кшканны белсә,
Сабакка калмаса соңга, борылмый барса уңга–сулга,
Уенга салмаса ихлас–менә бәхете аның шунда.
Кешеләргә итеп шәфкать, үзеннән зурга юл бирсә,
Бәхетсезләрне кимсетми, егылганнарга кул бирсә”.

“Доносчы колагына хор белән әйттеләр” шигыре тискәре гадәтләрнең кешене бизәмәве, хурлыкка алып баруы турында.

Әхлаксызлык, мәрхәмәтсезлек кебек тискәре сыйфатлар түбәндәге шигырьләрдә тәнкыйтьләнә:

“Бик югартын күз салырга башладык әхлакка без,
Кер күңелдә күплегеннән бармыйбыз ак якка без.
Тик хәзер йөз сумны урлап килгүче угры кеби,
Күз салабызчын сүз әйтердән элек як–якка без.
Берсүз әйтергә саранлансак гакыллы ярлыга,
Гөл кеби сүзләр чәчәбез акчалы ахмакка без”.( Г. Тукай “Әхлаксызлык”)
“Ә, шулаймы? Акча барда бар да дус шул, бар да яр;
Акча исе чыкмый торса, бар да яныңнан таяр”.(“Теләнче”)

Әдәбиятыбызның чишмә башы булган Тукай иҗаты тулысы белән милләт язмышына багышланган дисәк тә хата булмас, чөнки ул – халык улы, аны халык үстергән. Г.Тукай әдәби тәнкыйтьче, публицист, әдип буларак, туган халкының язмышын уртаклашкан, куанычына сөенгән, фаҗигасенә тетрәнеп җырлаган. Тукай Казанга зур өметләр белән килә, Казанда мәгърифәт нуры күрергә өметләнә, милли моңнар ишетергә тели.Ул татар милләтенең мәгърифәт юлыннан китүенә, ирек алачагына ышана иде. Өметләре акланмый, һәм шагыйрь бу турыда ачыктан–ачык әйтә:

Кайчан соң, и факыйрь милләт, бәһарең!

Кайчан китәр кичең, килер кәһарең?– дип , халкы өчен якты көннәр килүен тели. Г.Тукай күрсәткәнчә, халык үзенең бәхетен тату, дус булып, бер максатка бердәм барганда гына таба ала.20 яшьлек шагыйрь татарның таркаулыгын зур кимчелек итеп күрсәтә.“Шүрәле” поэмасы да бик үзенчәлекле. Шүрәле – халкыбыз әкиятләрендә сөйләнә торган мифик образ. Әсәрнең мәгънәсе тирән, туган илгә, туган якка мәхәббәт хисләре белән тулы. Шагыйрь туган җирнең газизлеге, Кырлай авылы, урманының матурлыгы турында сөйли.

Ачыла алдында тарихтан театр пәрдәсе,

Аһ,–дисең, без ник болай соң?

Без дә Хакның бәндәсе.

Бу сүзләр белән шагыйрь безне йокыдан уятып җибәрә.Әйебезнең дә башка милләтләр кебек яхшы яшәргә хакыбыз бар. ”Без ник болай соң? дигән сорау борынгы тарихыбызга кагыла, бабайларыбыз көчле дәүләт булып яшәгәннәр, даннарга ия булганнар.Урманның чиксезлеге шагыйрьнең хәтеренә борынгы бабаларыбызны искә төшерә.Аларның куәте белән үзе яшәгән чордагы татарлар белән чагыштырып карый да, Тукайның йөрәге әрни.Шагыйрь күңелендә туган илен ярату хисе тормыш гаделсезлеге тудырган хәсрәт хисе белән берләшә.”Шүрәле” поэмасына шул күзлектән чыгып анализ ясарга мөмкин.Былтыр, Шүрәле–халык, милләт.2 катлам вәкиле сурәтләнгән.1 нче катлам вәкилләре – Шүрәлеләр, мескен, изелгән, буйсынган, беркатлы, ышанучан гади халык, урман сарыгы. 2 нче катлам вәкилләре – Былтыр образында–батыр, хәйләкәр. Башы эшли.Аның төп кимчелеге – үз мәнфәгатьләрен генә кайгырту.Тукай татар халкының бетеп баруын аңлата.Татарның кыю йөрәкле батыр уллары үз мәнфәгатьләрен генә кайгыртып яшиләр, шуңа күрә татар милләте алга бара алмый.20 нче гасыр башында халык бик кечкенә булып яши.1908 нче елда талантлы шагыйрьнең каләменнән чыккан “Су анасы” әсәрендә әхлак тәрбиясе күтәрелә.”Татар милләтенең алга китә алмавының төп сәбәбе – милләт аналарының балага дөрес тәрбия бирмәвендә,малайның урлавына күз йомуында” дигән фикер үткәрелә , шагыйрь балаларга әхлакый тәрбия бирергә чакыра.Г.Тукай үзенең язмышын, бәхетен һәм бәхетсезлеген татар милләте язмышы белән бәйли.Милләтебезне алга киткән башка халыклар рәтендә күрү– Тукайның бар теләге.Бар уем кичен–көндезен сезнең хакта, милләтем;Саулыгың– минем саулык, авыруым–минем авыруым,– ди ул.Г.Тукай– халкыбызның таянычы, горурлыгы, йөз аклыгы, якты һәм мәңге балкып торачак кояшы ул. Җидееллык иҗат гомерендә татар халык шагыйре дәрәҗәсенә күтәрелгән Тукай әнә шулай милләт җанына мәңгелеккә береккән затлы шәхес булды.Тукай рухы яшәгәндә,Тукай моңнары чыңлаганда, Тукай сүзе җанда кайтаваз алганда, татар милләтенең ерак киләчәккә ниятләгән сәфәре ышанычлы да, якты да, күркәм дә булыр.

**Әдәбият**

1. Заһидуллина Д.Ф.Мәктәптә татар әдәбиятын укыту методикасы.–Казан:Мәгариф,2004.–367 б.

2. Нуруллин И. Моңлы саз чыңнары: Документаль роман. – Казан: Татарстан китап нәшрияты, 2000.–272 б.

3. Тукай Г. Сайланма әсәрләр. Шагыйрь турында истәлекләр.– Казан: Татарстан Республикасы «Хәтер» нәшрияты, 2002.–511 б.

## МӘКТӘПТӘ ТАТАР ӘДӘБИЯТЫ ДӘРЕСЛӘРЕНДӘ ТӘНКЫЙДИ МАТЕРИАЛЛАРНЫ КУЛЛАНУ

Шәрифуллина А.И.,
КФУның Алабуга институты магистранты.
Фәнни җитәкче: Хәйруллина Ә.С.

Соңгы елларда мәктәп укучыларының әдәби текстны аңлау сәләтен формалаштыру, шулай ук әдәби әсәрне аңлатуда катнашкан әдәби тәнкыйть материалларын киңәйтү мөмкинлеге күтәрелде, бу мәкаләләр һәм аңлатмалар еш кына тәнкыйтьчеләр һәм әдәбият галимнәре тарафыннан текстны аңлату өчен бер вариант булып торалар. Контраст, төрле фикерләр бәхәссез, “канонизацияләнгән” хакыйкатьләрне ассимиляцияләү мәгариф өлкәсендә күбрәк тәрбияви максатлардан бирелә. Әдәби тәнкыйть материалы катнашканда, бәяләүләр һәм карашлар бәрелеше котылгысыз. Еш кына тәнкыйтьче үзе укучысын “котырта”, кайвакыт тәнкыйтьче белдерелгән карарларга төзәтмәләр кертә.

Тәнкыйди язмаларны әдәбият дәресләрендә куллану татар әдәбиятын укыту методикасы фәненең эчтәлеген баету, яңарту эшендә зур ярдәмлек булып тора. Шул ук вакытта, сәнгать әсәрен критик материалны тирәнтен өйрәнмичә өйрәнү мөмкин түгел; ул мәктәп укучыларының әдәби белеме өчен мөһим булган дәрес этапларын чишүгә ярдәм итә, беренче чиратта, сәнгать әсәрен аңлау эшен тирәнәйтә. Тәнкыйтьчеләрнең, язучыларның мәкаләләре, язмалары мәктәп укучыларына әдәби текстны анализлау өчен үрнәк булып методик яктан хезмәт итәләр. Башта укытучы җитәкчелегендә, аннары мөстәкыйль рәвештә тәнкыйть мәкаләсе белән танышу, тезисларын яки рефератларын туплап, укучылар әсәрне анализлау юлын үзләштерәләр: аның социаль–фәлсәфи һәм эстетик позицияләрен аңлау; бу әсәрдә куелган актуаль проблемаларны эзләү һәм чишү; критик текстта авторның өземтәләрен цитаталар һәм текст материалы белән берләштерү ысулларына ия булалар. Болар барысы да укучыга өйрәнелә торган матур әдәбият әсәренә анализ ясау аша, үз фикерен, карашын формалаштырырга булыша. Бу эш укучыга әсәрнең образлар системасының төрле аңлатмалары белән тирәнтен танышырга, үзенең тәнкыйди фикерен булдырырга мөмкинлек бирә. Югары сыйныфларда, сәнгать әсәрләрен өйрәнү белән беррәттән, укучылар аерым әдәби–тәнкыйть мәкаләләре һәм язмалары, шулай ук бу әсәрләрне аңлату һәм анализлауга багышланган әдәби әсәрләрнең кечкенә кисәкләре белән танышалар. Бүгенге көндә әдәби белем бирү проблемаларының берсе – әдәби тәнкыйтьне өйрәнү тора.

Хәзерге вакытта, мәктәптә татар әдәбияты дәресләрендә әдәби тәнкыйтьне укыту, кабул итү һәм ассимиляцияләү формаларын махсус максатчан өйрәнү кирәк [Хатипов, 2000: 38]..

Тәнкыйть мәкаләләре тарихи һәм әдәби контекстны реконструкцияләү өчен уникаль мөмкинлек бирә. Тискәре һәм бәхәсле мәкаләләргә мөрәҗәгать итү дәрестә проблемалы ситуация булдыра. Тәнкыйтьчеләр белдергән әдәби әсәргә төрле карашларны иң нәтиҗәле чагыштыру. Әдәби–тәнкыйть текстын өйрәнү кешегә әдәби әсәрне аңлатуның үзенчәлекләрен аңларга мөмкинлек бирә.

Әдәби–тәнкыйть фикере әсәрләренә тәнкыйть мәкаләләре генә түгел, ә хатлар, очерклар, бәяләмә һәм хөкемнәр кертелгән рецензияләр, тәкгъзияләр дә керә. Мәктәптә әдәби тәнкыйтьне өйрәнү зарурлыгы, укучыларга белем һәм тәрбия бирүдә аның мөһимлеген беренчеләрдән булып В.П. Острогорский күтәрә.

Танылган методистлар әдәбият дәресләрендә әдәби тәнкыйть язмаларын өйрәнүнең әһәмиятлелеген ассызыклап, “әдәбият тәнкыйте ярдәмендә художестволы әсәрне җанлы, кызыклы һәм җитди өйрәнү мөмкин” (Ц.Балталон), аларның “тәнкыйди фикерләүләрен”, “тәнкыйтьчеләрнең капма–каршы фаразларын аңлау сәләтен” үстерү, “әдәби әсәрне шәхси аңлауны белдерү” (В.В. Голубков) аша укучыларда тәнкыйтьчеләрнең җитди өйрәнүләренә кызыксыну уятырга кирәк дип саныйлар [Проблемы преподования..., 1985: 120].

Әдәби тәнкыйть мәкаләләрен өйрәнү мәктәп укучыларының әдәби белем дәрәҗәсен күтәрә, әдәби тәнкыйть төшенчәсен әдәби иҗатның бер төре итеп кабул итүләрен формалаштыра, аның максаты –укучыларга сәнгать әсәрләрен аңлату, шулай ук тормыш күренешләре белән дә таныштыру. Татар әдәби тәнкыйте – ул мәдәни күренеш. Табигате буенча теоретик белемнәр һәм сәнгать иҗаты арасында универсаль арадашчы булу, татар әдәби тәнкыйтен өч төрле көчнең үзенчәлегенә әйләнде: сәнгать, фән (фәлсәфә, эстетика), чынбарлыкның үзе – абсолют эстетик чынбарлык. XX гасыр башында татар тәнкыйте үзенчәлекле урын били, ул чор культурасында әдәбиятның үзе кебек үк мөһим роле һәм дәрәҗәсе белән чагыштырыла. Татар әдәби тәнкыйте әдәбиятны гына түгел, ә әдәбият чагылдырган һәм аңлаткан теманы да – тормыш, мәдәниятның социаль чагылышы булып тора. Татар тәнкыйте бер үк вакытта эстетика, этика һәм социология кебек фәннәрне дә үз эченә берләштерә.

Мәктәп укыту практикасында әдәбиятның императив схемасы кайвакыт әле дә булса дәвам итә, бу укучыларның сәнгатьчә тойгыларына каршы килә. Шедеврларга карата салкын хөрмәт яшәвеәсәрне индивидуаль кабул итү хисенә комачаулый. “Мәдәни классицизм” куркыныч, чөнки чын мәхәббәт аның темасына тәнкыйть карашын читләтеп үтми. Эстетик кыйммәтләрне үстерү кызыксыну белән, мәҗбүриятсез алып барылырга тиеш. Бу мөмкинлек программа әсәрләрен төрлечә аңлату, өйрәнелгән язучы шәхесенең төрле

яклары белән танышу аша тормышка ашырылаТәнкыйть, барлык мәктәп курслары кебек, шәхси аңлауга мохтаҗ.

Шулай да, мәктәп курсында татар әдәбияты дәресләрендә тәнкыйди язмаларны кулланганда, вакытлы матбугат басмаларына мөрәҗәгать итү кирәк. Мәсәлән, XX йөз башы татар әдәбиятын укыткан чакта, шул чор башында дөнья күргән “Аң” журналы басмасында басылган тәнкыйди язмаларны куллану мөмкин. Бу әдәбият дәресләрендә аерым иҗатчыларның дәреслекләрдә бирелгән һәм популяр булган әсәрләрен укытудан тыш, бу язучының иҗатына кагылышлы журналда басылган тәнкыйди мәкаләләрне дә тәкъдим итеп була. Шул рәвешле без язучының иҗат лабораториясен яхшырак күзаллау мөмкинчелеге алабыз. Үсештәге иҗатчының иҗат үрнәкләре һәм аларга карата шул чорның тәнкыйть фикере белән танышу аша, аның кайсы елларда нинди фикер яклы булуын, нинди стильгә ия булуын күзәтәбез.

Бу мәктәптә әдәби тәнкыйть мәкаләләрен өйрәнүнең мөмкин ысуллары. Укытучының бурычы – бу өйрәнүне иҗади итү; бу мәкаләләрне анализларга өйрәтү генә түгел, ә укучыларның әдәбиятка бөтен сораулар һәм биремнәр белән кызыксыну уяту мөһим, аннары тәнкыйть мәкаләләрен уку бурычка түгел, ә укучыларга ихтыяҗ булып китәчәк. Тәнкыйть мәкаләләрен карау мәктәп укучыларының сәнгатьчә тәмен үстерә, аларның мәдәни офыкларын киңәйтә, әхлакый идеаллар үсешенә ярдәм итә. Тәнкыйть белемнең объекты гына түгел, ә белем коралына әйләнергә, текстны фәнни анализлау күнекмәләрен формалаштыру, критик фикер йөртү тәрбияләүгә булышлык итәргә тиеш.

Шулай итеп, сыйныфта һәм мөстәкыйль өй эше процессында методик яктан дөрес оештырылган тәнкыйди язмалар белән эш мәктәп укучыларының әдәби белемен, аларның рухи, сәнгать һәм эстетик үсешен, сөйләм эшчәнлеген яхшырта ала.

**Әдәбият**

1. Проблемы преподавания литературы в средней школе: пособие для учителя / под ред. Т.Ф. Курдюмовой. – М. : Просвещение, 1985. – 192 с.

2. Хатипов Ф.М. Әдәбият теориясе. Югары уку йортлары, педогогия училищелары, колледж студентлары өчен кулланма. – Казан: Мәгариф. – 2000. – 351 б.

## ДӨРЕС КИЕНӘ БЕЛҮ – ГҮЗӘЛ КҮРКӘМ ХОЛЫКНЫҢ БЕР БИЗӘГЕДЕР...

Шарифуллина З.А.,
«Адымнар – Алабуга» күптелле белем бирү комплексының
10 нчы сыйныф укучысы.
Фәнни җитәкчеләр: Данилова З.С., Комиссарова Ф.Г.

Югары зәвыкны ничек тәрбияләргә мөмкин? Без дөрес һәм зәвык белән киенә беләбезме? Без кигән киемнәр сәламәтлегебезгә зыян китермиме?

Кеше кайчан матур була, гүзәллек сукмакларын ничек бәхет юлына тоташтырырга? Безнең темабыз, караган мәсьәләләребез бүгенге көндә аеруча актуаль. Сонгы елларда без, яшьләр, Ауропа модасына яраклашып, тышкы кыяфәтебезгә игьтибар итми башладык. Мода сүзенә билгеләмә биреп китик, (мода– фр. *mode*, лат. modus – *үлчәү, образ, алым, кагыйдә*) –билгеле бер иҗтимагый даирәдәге берәр нәрсәгә карата билгеләнгән таләп өстенлеге. Билгеле бер замандагы таләпка тура килгән кием өлгесе, тәртип, этикет, яшәү рәвеше, сәнгать, күңел ачу һ.б. Мода төшенчәсе ышанычсыз, тиз тузучан билгелелекне аңлата. Яңа мода артыннан куу – моданың аерылгысыз сыйфаты. Берәр күренеш яки берәр әйбер заманында модалы булган булса, ул үзенең модалы булуын югалта һәм иске модалы булып исәпләнә. Моданы алга этәрүче ике көч бар. Беренчесе–матурлык тойгысына иярү,икенчесе – җәмгыятьтә көлкегә калу, өлкән буын кешеләренең сүзләренә колак салмау. Әгәр шулай дәвам итсәк, безне, киләчәк буынны нәрсә көтәр?

Иң авыр заманнарда да халкыбыз кием–салым, аяк киеме, бизәнү әйберләренең матурлыгына игътибарын киметмәгән. Кием–салымга тәнне каплау, җылыту чарасы итеп кенә түгел, матурлык чыганагы итеп тә караган, алар килешле, уңайлы, күркәм булырга тиеш дип уйлаган.Төрле төсләр кулланып, аларны гаять оста чиратлаштырып иҗат ителгән милли киемнәр, аяк киемнәре, бизәнү әйберләре – үзе бер сәнгать. Алар төрле яклап уйлап иҗат ителгәннәр, аларның матурлыгына гына түгел, сәламәтлеккә йогынтысына да әһәмият бирелгән. Кыскасы,киенү, бизәнү халкыбыз яшәешендә зур сәнгать дәрәҗәсенә күтәрелгән.

Күренекле әдибебез Риза Фәхреддин беренчеләрдән булып, хатын–кызның киенү әдәбе, ягъни мода турында бик мөһим проблема күтәреп чыкты.” Мода сөйләмәгез, мода ишетмәгез, мода белән гамәл кылмагыз, мода белән белеш булмагыз! Мода исерткеч вә яки отыш уенының бер төре булып, аңа дучар булган кеше, үзе һәлак булмый торып, аннан аерыла алмас. Киемлек алган вакытыгызда, әйберләрнең хаклары белән гомерләрне бәрабәр китереп хисап итегез вә кайсысы арзан булса –шуны ихтыяр итегез! Һәрникадәр мөбах, ягъни ярый торган зиннәтләрдә зарар булмаса да, киемнәрегезгә хушбуй түгеп йөрмәгез, бәлки тәнегезне, киемегезне пакь йөртергә гадәтләнегез! Кием кию турысында үзегезгә иш булмаган кешеләргә саескан кебек иярмәгез! Киемнәрегез белән мактанмагыз! Киемнәрне камиллек санамагыз. Башкаларның киемнәренә мәсхәрә күзе белән карамагыз, халык алдында киемнәрегезгә карап тормагыз, күңеле кибәк белән тулы кешенең тышы ефәк булуында бер мәгънә дә юк икәнлеген һичбер вакыт онытмагыз! Бик кыскан вә иркен киемнәрне кимичә, бәлки башны кызудан, аякларны салкыннан саклар рәвештә булган киемнәрне ихтыяр итегез ,– дип бу мәсьәләне бик үткен куя.

Бу проблема элек тә һәм бүгенге көндә дә үзенең әһәмиятен югалтмаган, һәркемне уйландыра. Мин Ислам диненең бу мәсьәләгә ничек караганлыгын белү өчен Коръән китабына мөрәҗәгать иттем. Коръәндәге «Әгъраф» сүрәсенең 26нчы аятендә: “Ий Адәм балалары! Без сезгә киемнәр

яраттык, ул киемнәр гаурәтләрегезне каплар, янә мал яраттык һәм дә тәкъвалык киемен бирдек, ул тәкъвалык – саклану киеме хәерледер, ошбу зекер ителгән нәрсәләр Аллаһы Тәгаләнең галәмәтләре, шаять кешеләр вәгазьләнерләр", – диелә [Коръән 2003:153] . Динебездә киенүгә зур игътибар бирелә һәм иң беренче шарт – гаурәт күренмәскә тиеш. Ир кешенең гаурәте кендегеннән алып тез астына хәтле, ә хатын–кызның, асылда, бөтен тәне гаурәт, аның йөзе һәм куллары гына ачык була ала. Икенче шарт – кием үтә күренмәле булырга һәм тәнгә сыланып торырга тиеш түгел. Өченчесе – киемне кем алдындадыр мактану, тәкәбберләнү максатыннан кияргә кирәкми. Пәйгамбәребезнең (с.г.в.) бер хәдисендә дә: "Исраф итүдән һәм масаю, тәкәбберләнүдән саклану шарты белән ашагыз, эчегез, һәм киенегез", – диелә.

Мода дигән әйбер дә бар бит, аңа иярүгә дин ничек карый? Мин бу сорау белән Алабуга мәчете хәзрәтенә мөрәҗәгать иттем. Модага ияреп, шәригать кысаларыннан чыга икән, бу – тыела. Киенү әдәпләре үтәлсә, бер зыяны да юк, дип белдерде Рөстәм хәзрәт.

Киенү әдәбе һәр чор әдәбиятында да чагылыш тапкан. Язучылар битараф калмаганнар. Үз әсәрләрендә героиняларын зәвыклы итеп сурәтләгәннәр. Бик күп роман, повесть, хикәяләрне мисал итеп китерергә мөмкин. М. Акъгетнең

"Хисаметдин менла" романында Хәнифә туташны алыйк. Автор Хәнифәнең дә портретына игътибарны юнәлтә.Кызның тышкы кыяфәте белән бергә милли киемнәренә дә игътибар бирелә. Кием һәм бизәнгечләргә килгәндә, иңендәге шәлгә игътибар ителә. Бу шәл – яшь кыз булу билгесе саналса, икенче яктан сәламәтлекне саклау билгесе итеп фаразлый алабыз.Фатих Әмирханның

"Хәят" повестенда Хәят–искиткеч гүзәл кыз.Автор аның гүзәллеген идеаллаштырып биргән. Бүгенге көн таләпләренә туры китереп киенә, ләкин үзенең татар икәнен чагылдырган детальләрдән баш тартмый. Мәсәлән, декольте күлмәк белән бергә милли калфагын да кия. "Аның быел тектергән ал ефәк декольте күлмәге инде җиткән кызлар кия торган модаларның иң соңгысы белән тегелгән. Бу калфак, ефәк көлтәсенә чолганган гөл чәчәге (роза) шикелле, көлеп тора иде.Ал кием безнең Хәятка бик килешә: ул аның эчендә ал фәрештә шикелле була"– дип сурәтли әдип.

Йомгаклап шуны әйтергә була,бик борынгы заманнарда кешеләр, тәннәрен салкыннан, җылыдан, тузаннан, җилдән саклау өчен, кием уйлап тапканнар. Димәк, беренчедән, кием ул – тәнне саклау чарасы.Икенчедән, кием үзенең хуҗасы турында мәгълүмат бирә. Ул хуҗасының зәвыгын һәм эчке культурасын күрсәтә.Өченчедән, кием–кешене бизәү чарасы. Ләкин һәрвакыт шуны истә тотарга кирәк, һәр кием чиста, пөхтә һәм урынлы булырга тиеш.

Мин үзем дөрес киенергә тырышам: спорт белән шөгыльләнгәндә спорт киемен киям,бакчада эшләгәндә эш киеме,кунакка барганда бәйрәмчә киенергә тырышам. Мәктәпкә мин мәктәп формасында йөрим. Минемчә, әгәр укучылар формадан йөрсәләр, аларда бер–берсеннән көнләшү хисе булмый;алар үз мәктәпләре белән горурланалар; дәресләрдә җитди эш белән шөгыльләнәләр;зәвык белән киенергә өйрәнәләр.

Агач күрке – яфрак, адәм күрке – чүпрәк, дип әйтәләр халыкта. Ләкин минем уйлавымча, кеше тышкы яктан матур булып күренсә дә ул начар, тәрбиясез булырга да мөмкин бит. Ул чагында аның чын матурлыгын ничек аерып була соң? Минемчә, аның белән аралашып, эшенә, кыланышларына, теге яки бу очракта үз–үзен тотышына карап белергә була. Бу хакта түбәндәге мәкальләр сөйли: ”Кием кешене бизәсә дә, гүзәл итмәс”, ”Киемгә карап каршы алалар, акылга карап озаталар”. Мин еш кына бөек рус язучысы А.П. Чеховның афоризмга әйләнгән шундый сүзләрен искә төшерәм; «Кешенең бөтен нәрсәсе дә матур булырга тиеш: киеме дә, йөзе дә, күңеле дә, фикере дә». Мондый билгеләмә белән язучы, барыннан да элек, түбәндәге кешене күз алдында тота. Акыллы, үз–үзенә таләпчән, югары культуралы, зәвык белән киенүчән, хезмәт яратучан кеше генә үзен хөрмәткә лаек дип исәпли. Мин бу фикер белән тулысынча килешәм һәм шундый кеше булырга омтылам!

**Әдәбият**


1. Әмирхан Ф.Сайланма әсәрләр.– Казан: Татар. кит.нәшр., 2003.– 393б.
2. Хайдаров Ф.С. Коръән.– Казан “Раннур” нәшр., 2003.–1200 б.
3.Фәхретдин Р.Ф. Балаларга үгет– нәсыйхәт. – Казан: “Дом печати” нәшрияты. – 2001.– 192 б.


## ГАЛИӘСГАР КАМАЛ – ТАТАР ТЕАТР СӘНГАТЕНӘ НИГЕЗ САЛУЧЫ


Юнусова З.Н.,
Алабуга шәһәре “Университет” гомум белем бирү мәктәбенең
10А сыйныфы укучысы.
Фәнни җитәкче: Сахабиева Г. Х.


Г.Камал – милли журналистикага һәм татар профессиональ театрына нигез салучыларның берсе.

1880 елларда – «Госмания» һәм «Халидия», 1890 елларда «Мөхәммәдия» мәдрәсәләрендә укый, бер үк вакытта өчьеллык рус мәктәбендә башлангыч белем ала.

Улын мулла итеп күрергә теләгән атасының ихтыярына каршы килеп, Г.Камал үзен халыкны агарту эшенә багышлый. 1901 елда ул китап бастыру һәм тарату эше буенча «Мәгариф көтебханәсе» дигән җәмгыять оештыра һәм 1905 елга кадәр аның белән җитәкчелек итә.

Алдагы елларда Г.Камалның комедиограф буларак та таланты ачыла. Ул милли драматургияне һәм театр сәнгатен «Беренче театр» (1908), «Бүләк өчен» (1909), «Банкрот» (1911), «Безнең шәһәрнең серләре» (1911) комедияләре белән баета. Аларда Камал XX йөз башы татар җәмгыяте тормышын сатира күзлегеннән чыгып гәүләндерә, аталар һәм балалар, ир белән хатын, гаилә–көнкүреш мөнәсәбәтләре проблемаларын күтәреп чыга; патриархаль рухта

тәрбияләнгән милли сәүдәгәр–мещаннар мохите вәкилләренең истә калырлык образларын иҗат итә.

Иҗат тематикасының төп юнәлеше – патриархаль тәртипләрнең җимерелүен, яңа мөнәсәбәтләр, карашлар тууны, искелек белән яңалык арасындагы каршылыкларны, күрәшне яктырту.

Г.Камал пьесаларында персонажлар «җәмәгать» һәм «мәдәният» эшләре белән мәшгуль (Фатих, Насыйр, Гариф, Кәрим – «Безнең шәһәрнең серләре»), һәр яңалыкка каршы (Хәмзә бай – «Беренче театр»), үзләренең комсыз теләкләрен һәм ихтыяҗларын бар нәрсәдән дә өстен куялар (Хәмидә – «Бүләк өчен»), кешеләр арасындагы эшлекле мөнәсәбәт һәм әдәп кагыйдәләрен бозалар (Сираҗетдин – «Банкрот»). Г.Тукай югары бәяләгән «Безнең шәһәрнең серләре» пьесасында шәһәрдә яшәүче татар халкының барлык катлаулары да (зыялылар, руханилар, чиновниклар, хезмәтчеләр һәм башкалар) гәүдәләнеш таба.

Г.Камал комедияләре конфликтларның үткенлеге, вакыйгаларның хәрәкәтчәнлеге, бай эчтәлекле булуы белән аерылып тора; аларда геройларның рухи дөньясы оста яктыртыла, милли йолалар, гореф–гадәтләр, көнкүреш детальләре (йорт җиһазлары, аларның урыны, чисталык, тәртип; милли аш бүлмәсе һәм башкалар) ачык сурәтләнә. Автор үзен диалог остасы буларак та күрсәтә, аның комедияләренең теле халык юморына бай.

Г.Камалның поэтик иҗаты татарның иҗтимагый тормышында 1905–1907 елгы Революция чорында барлыкка килгән уй–фикер һәм халәтләрне чагылдыра. Ул милләтнең ихтыяҗлары, ирекккә омтылуы, өмет–хыяллар белән яшәве хакында, милли мәгариф, мәдәният һәм фән үсеше турында яза («Азатлык», «Өндәү», 1905; «Безнең кирәк», «И, мөселман, йокламагыл!», 1906 һәм башкалар).

Г.Камал публицистика өлкәсендә дә күп темаларны яктырта:

1905 елгы Дәүләт думасы һәм манифестка мөнәсәбәт («3 нче ноябрь манифесты ни бирә?»; «Дума, дума, дума», 1906; «Депутатлар озату», 1907 һәм башкалар), татар иҗтимагый тормышы мәсьәләләре («Кем гаепле?», 1905; «Искелек сакчыларына ачык хат», 1906; «Ачларга ярдәм эшләре», 1907; «Иван Николаевич Харитонов», 1909; «Кыз сату», 1912 һ.б.).

Хикәяләрендә Г.Камал бушка, юкка вакыт сарыф итүне тәнкыйтьли, халыкка һәм җәмгыятькә файдалы эшләр башкарырга чакыра («Сабир хәзрәт яки гыйбрәт», 1903; «Күгәргән алтыннар», 1909).

Г.Камал татар әдәбияты һәм театры үсешен игътибар белән күзәтә, күп санда әдәби–тәнкыйть мәкаләләре һәм рецензияләр бастырып чыгара («Татарча театр», «Габдулла Тукаев шигырьләр», 1907; «Ачлык кушты», 1908; «Яңа әсәрләр», 1909; «Саран» пьесасы хакында», 1915 һәм башкалар).

Ул, революцион эчтәлекне традицион поэтик формаларда сурәтләп, гражданнар сугышы елларында илдә һәм республикада барган вакыйгаларны яктырта («Декламацияләр», 1921). Г.Камалның 1917 елдан соңгы иҗаты сәнгатьчәлеге ягыннан Октябрьгә кадәрге чор иҗатыннан шактый калыша.

Алга таба аның драматургиясендә җәмгыятьне социалистик үзгәртеп кору идеяләре яңгыраш таба. Совет органнары хезмәткәрләре һәм алар тарафдарлары уңай геройларга әверелә, ә үзгәрешләргә каршы булучылар көлкегә алына («Хафизәләм иркәм» комедиясе, 1922; «Өч тормыш» драмасы, 1930 һәм башкалар).

1906 елда Казанда татар телендә халык алдында беренче тапкыр театраль тамашалар белән чыгыш ясый башлый.

1920 елга кадәр ширкәтчелек принципларында оешкан хосусый антреприза сыйфатында эшли. 1920 елда ТАССР Мәгариф халык комисариаты карары нигезендә элекке «Сәйяр», «Нур», «Ширкәт» һәм башка труппа актерлары катнашында Беренче татар дәүләт драма труппасы оеша.

1921 елда труппа Беренче татар дәүләт театры дип үзгәртелә һәм үрнәк театрлар исәбенә кертелә. Аңа элекке Сәүдәгәрләр клубы (хәзер Островский урамындагы Яшь тамашачылар театры (ТЮЗ)) бинасы бирелә.

1922 елның 8 ноябрендә, бинаны үзгәртеп корганнан соң, театрны ачу тантанасы уза (Ф.Бурнашның «Җирсезләр» пьесасы буенча спектакль күрсәтелә).

1926 елга кадәр театр төрле исемнәрдә чыгыш ясый: «Кызыл Октябрь исемендәге Беренче татар дәүләт драма театры», «Октябрь революциясе исемендәге татар театры». 1926 елда, нигез салынуына 20 ел тулу уңаеннан, ТАССР Халык Комиссарлары Советы карары белән академия театры исеме бирелә. 1939 елдан хәзерге исемдә.

1920 еллар театрның стационар репертуарын формалаштыру, даими труппа төзү чоры була. Театр белән чор таләпләрен нечкә тоемлаучы драматург, актер, режиссер К.Тинчурин җитәкчелек итә. Театр тирәсендә яшь авторлар (М.Фәйзи, Ф.Бурнаш, Г.Ибраһимов, Ш.Усманов, Һ.Такташ, М.Гафури, Ә.Рахманкулов) төркеме оеша.

Сезон дәвамында гел бер үк тамашачы өчен бер урында эшләү зарурлыгы яңадан–яңа сәнгатьчә сурәтләү формалары һәм чаралары табуны, үзенчәлекле сәхнәләштерү культурасын үзләштерүне таләп итә; режиссура тагын да әһәмиятлерәк була башлый.

К.Тинчурин белән беррәттән актерлар М.Мутин, Ш.Шамильский, К.Шамил, М.Мәһдиев, З.Солтанов та режиссерлык эше белән шөгыльләнә башлыйлар. Сәхнәгә кую эшенә рус режиссерлары Л.В.Развозжаев, Ю.В.Соболев, А.М.Кречетов; татар режиссерлары Г.Девишев, Г.Исмәгыйлев, С.Булатов, соңрак Мәскәүдә махсус профессиональ белем алган Ш.Сарымсаков тартыла.

Бер үк вакытта актерлар әзерләү мәсьәләсе дә хәл ителә. 1922 елда З.Солтанов башлангычында Татар театр техникумы оеша (1923 елның 1 гыйнварында рәсми рәвештә ачыла), белем бирергә татар һәм рус театрлары актерлары чакырып алына. Техникумны тәмамлаган кайбер актерлар (Р.Ишморат, Х.Сәлимҗанов, К.Тумашева) режиссерлык белгечлеге дә алып чыга.

1920–1930 елларда совет театрында реалистик һәм формалистик юнәлешләр тарафдарлары арасында көчәеп киткән бәхәсләр татар театрын да читләтеп үтми. Т.Гыйззәтнең «Наёмщик», В.М.Киршонның «Рельслар гөрелдәгәндә» («Рельсы гудят», икесе дә 1928 елда), Н.Галимовның «Казан өчен көрәш» (1929), Г.Минскийның «ОДВА» (1931) пьесалары буенча С.Вәлиев–Сульваның сәхнә алымнары һәм эффектларыннан мул файдаланып куйган спектакльләре төрле караш уята.

К.Тинчурин исә «Җир уллары трагедиясе» (Һ.Такташ), «Бай кызы» (Ш.Усманов), «Яшь йөрәкләр» (Ф.Бурнаш; барысы да 1922 елда), шулай ук үзе язган «Беренче чәчәкләр» (1921), «Соңгы сәлам» (1922), «Сүнгән йолдызлар», «Казан сөлгесе», «Американ» (барысы да 1924 елда), «Зәңгәр шәл», «Җилкәнсезләр» (икесе дә 1926 елда) әсәрләре буенча куйган спектакльләрдә реалистик ысулга таяна.

Бөек Ватан сугышы елларында театр сәнгате илне фашист баскыннарыннан саклау мәнфәгатьләренә буйсындырыла. Репертуарда төп урынны тамашачыда патриотик хисләр уятучы пьесалар ала. Бу елларда дөнья күргән аеруча игътибарга лаек спектакльләр: Ш.Сарымсаков куйган «Таймасовлар» (Т.Гыйззәт, 1941), «Тукай» (Ә.Фәйзи, 1942), «Рус кешеләре» («Русские люди», К.М.Симонов, 1942); «Идегәй» (Н.Исәнбәт, 1941; режиссер Е.Г.Амантов), «Мәрьям» (Н.Исәнбәт, 1943; режиссер Ш.Шамильский), «Миңлекамал» (М.Әмир, 1944; режиссер Х.Уразиков). Аларда сугыш вакыйгалары белән беррәттән ул еллардагы авыл тормышы да гәүдәләнә.

Театр актерлары һәм режиссерлары концерт бригадалары составында хәрәкәттәге армия сугышчылары каршында чыгышлар ясыйлар, госпитальләрдә һәм эвакуация пунктларында шефлык эшендә актив катнашалар.

1940 елларның икенче яртысыннан театр сәхнәсендә конфликтсыз драматургия тамыр җәя, бу иҗат атмосферасына, актерлар һәм режиссерларның осталык дәрәҗәләренә тискәре йогынты ясый. Ул елларда сәнгати кыйммәте түбән, төссез спектакльләр янында җитештерү мәнфәгатьләре арткы планга күчкән, беренче урында үзенең уй–хисләре, күңел кичерешләре белән шәхес торган «Тормыш җыры» (М.Әмир, 1947; режиссер К.Тумашева), «Зифа» (Н.Исәнбәт, 1954; режиссер Х.Уразиков), «Беренче мәхәббәт» (Х.Вахит, 1960; режиссер Р.Бикчәнтәев) спектакльләре театр дөньясында якты күренеш була.

2002 елдан театрның сәнгать җитәкчесе итеп Ф.Бикчәнтәев билгеләнә. Искәндәр Хәйруллин, Р.Бариев, Л.Хәмитова, М.Габдуллин, Л.Рәхимова, Н.Хәйруллина, Ф.Сафин, М.Шәйхетдинова, Ф.Җиһанша кебек яшь, сәләтле актерлар тырышлыгына таянып, ул нечкә психологизм белән сугарылган, поэтик метафораларга һәм импровизациягә бай спектакльләр иҗат итә. Ул куйган «Хушыгыз!», «Җанкисәккәем» (Т.Миңнуллин; 1993, 1995), «Җирән чичән белән Карачәч сылу», «Гөлҗамал» (Н.Исәнбәт; 1999; 2007), «Кара чикмән» («Черная бурка», Г.Хугаев; 2002), «Телсез күке» (З.Хәким, 2004) спектакльләре халык мәхәббәтен казана.

Болардан тыш театр сәхнәсендә «Зәңгәр шәл» (К.Тинчурин), «Яшь йөрәкләр» (Ф.Бурнаш), «Банкрот» (Г.Камал), «Курчак туе» (Р.Хәмид), «Мулла», «Гөргөри кияүләре» (Т.Миңнуллин), «Хан кызы Турандык» («Принцесса Турандот», К.Гоцци), «Мәхәббәт FM», «Әрем исе» (И.Зәйниев), «Искән җилләр көенә» (З.Хәким), «41 нең арбалы хатыннары» (З.Зәйнуллин), «Ут күршеләр» (С.Юзеев), «Сөясеңме, сөймисеңме?» (Ф.Бүләков), «Үлеп яратты» (Р.Зәйдулла), «Минем исемем Кызыл» («Меня зовут Красный», О.Памук), «Ричард III» (У.Шекспир), «Хуҗа Насретдин» (Н.Исәнбәт), «Һавалы биюләр» (С.Юзеев), «Исәнме, улым» (Б.Абдураззоков), «Дон Жуан» (Ж.–Б.Мольер), «Әлли–бәлли–бәү» («Әниләр һәм бәбиләр» пьесасы үрнәгендә, Т.Миңнуллин), «Көтәм сине...» (И.Зәйниев) һәм башка спектакльләр зур уңыш белән бара.

Театр чит илләрдә, Татарстан Республикасы һәм РФ шәһәрләре һәм районнары буйлап гастрольләрдә йөри.

Россия һәм халыкара театр фестивальләрендә катнаша, берничә тапкыр Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгының «Тантана» бүләге лауреаты («Иң яхшы хатын–кыз роле» номинациясендә – Д.Нуруллина, 2015; «Иң яхшы ир–ат роле» номинациясендә – Р.Бариев, 2016; «Ел вакыйгасы» номинациясендә – «Хуҗа Насретдин» спектакле, Н.Исәнбәт әсәре буенча, 2015) була.

2018 елда театр труппасында – Татарстан Республикасы һәм РФнең халык артистлары А.Гайнуллина, Н.Ихсанова, Р.Таҗетдинов, Ә.Шакиров, Р.Шәрәфиев; РФнең атказанган һәм Татарстан Республикасының халык артистлары И.Әхмәтҗанов, Н.Дунаев, Н.Гәрәева, Р.Мотыйгуллина, Д.Нуруллина, А.Хафизов, Илдар Хәйруллин; Татарстан Республикасының халык артистлары Ф.Әкбәрова, И.Баһманов, И.Габдрахманов, А.Галиева, Х.Җәләлов, З.Зарипова, Н.Ибраһимова, Ф.Сафина, Р.Төхфәтуллин, Л.Хәмитова, Искәндәр Хәйруллин, Ә.Хисмәтов, Р.Юкачева һәм башкалар.

Театрның баш режиссеры – Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе Ф.Р.Бикчәнтәев (2002 елдан), баш рәссамы – Татарстан Республикасының халык рәссамы С.Г.Скоморохов, директорлары – Татарстан Республикасының һәм РФнең атказанган мәдәният хезмәткәре Ш.З.Закиров (1985–2012); И.И.Якупов (2012 елдан).

## Әдәбият

1. Камал Г. Әсәрләр. 1 том – Казан: Татар. кит. нәшр., 1978.–34б.
2. Помада мәсьәләсе// Йолдыз. – 1908.–19 март.
3. Социалистик Татарстан.– 1955.– 29 гыйнвар.
4. Хисматуллин Х. Галиәсгар Камал. – Казан : Татар. кит. нәшр., 1978.– 196б.

# ГАЛИӘСГАР КАМАЛНЫҢ ТОРМЫШ ЮЛЫ ҺӘМ ИҖАТЫ

Юнысова Э.Ф.,
КФУның Алабуга институты студенты.
Фәнни җитәкче: Даутов Г.Ф.

Татар халкының мактанычы булган каләм ияләре арасында Галиәсгар Камал лаеклы урынны алып тора. Казандагы һәм Татарстандагы иң зур, иң данлы татар театры аның исемен йөртә. Әлеге театрның тууы, үсүе, танылуы талантлы драматург, актёр, режиссёр Галиәсгар Камал исеме белән турыдан–туры бәйле. Шуңа өстәп, олы әдипнең тәрҗемәче, шагыйрь, рәссам–карикатурчы булуын да әйтеп үтми мөмкин түгел.

Галиәсгар Камал (Галиәсгар Галиәкбәр улы Камалетдинов) 1879 елның 6 гыйнварында (искечә 1878 елның 25 декабрендә) Казан шәһәренең һөнәрче–мехчы гаиләсендә дөньяга килә. Аның атасы Галиәкбәр, 12 яшьләрендә Казан шәһәренә килеп, бер байда һөнәргә өйрәнгән була һәм шунда яшәп кала. Аны *“камчатчы Галиәкбәр”* дип йөрткәннәр. Галиәкбәр абзыйның тормышы җиңелләрдән булмаган: аңа еш кына бер фатирдан икенче фатирга күчеп яшәргә туры килгән, шуңа күрә дә, Галиәсгар Камал үзенең балачак елларын Арча районында, анасының туган авылы Масрада, әби–бабалары тәрбиясендә уздырган. Мәктәпкә дә беренче мәртәбә нәкъ шушы авылда барган. Күпмедер вакыттан соң, ул янәдән Казанга кайтарылып, укуын шунда дәвам иткән. 1894 елда Галиәсгар Камал Казан шәһәренең алдынгы мәдрәсәләреннән булган *“Мөхәммәдия*”дә укый башлый. Биредә ул гарәп–фарсы телләрен өйрәнә. Шул ук вакытта, өч сыйныфтан торган башлангыч мәктәпкә йөреп, рус телен дә үзләштерә [Арсланов 2008: 5]. Шулай ук, шушы елларда ул театр сәнгате һәм матур әдәбият белән кызыксына башлый: рус театры, курчак театрына йөри. *1898 елда “Бәхетсез егет”* дип аталган тәүге драмасын иҗат итә. Озак та үтми, *1900 елда* икенче иҗат җимеше булган *“Өч бәдбәхет”* исемле әсәре дә иҗат ителә.

1900 елда, Галиәсгар Камал мәдрәсәне тәмамлап, үз тормыш юлын билгеләргә тиеш була. Атасы аның мулла булуын тели, ләкин ул үзе аның белән килешми. 1901 елда, Галиәсгар Камал мәгърифәт тарату, халыкны агарту эшенә булышлык итү максаты белән, *“Мәгариф көтебханәсе”* китап бастыру һәм сату ширкәте оештыра һәм шуның белән җитәкчелек итә. Әлеге берләшмә язучыларның әдәби салоны хезмәтен үти башлый.

1906 – 1915 елларда Галиәсгар Камалның драматургия өлкәсендәге иҗади уңышлары, татар театры сәнгатен тудыру юлындагы иҗтимагый һәм гамәли эшчәнлеге аеруча игътибарга лаек. Әйтергә кирәк, *1906 елның 22 декабрендә «Гыйшык бәласе»* (төрекчәдән Г.Кәрам тәрҗемәсе) һәм *«Кызганыч бала» (Нәмык Кәмал әсәре, Г.Камал тәрҗемәсе) пьесалары* буенча Казанда беренче мәртәбә ачык спектакль уйнала. Профессиональ милли театр барлыкка килү Галиәсгар Камалның иҗади дәртен бермә–бер арттырып җибәрә. 1907 – 1912 еллар арасында ул үзенең иң көчле, сәнгатьчә иң камил сәхнә әсәрләрен иҗат

итә. 1905 – 1915 еллар арасында әдип «*Казан мөхбире», «Азат», «Азат халык», «Әлислах» һәм бигрәк тә «Йолдыз»* гәҗит битләрендә татар иҗтимагый тормышының һәм әдәби хәрәкәтенең, театр сәнгатенең төрле мәсьәләләренә багышланган йөзләрчә публицистик, әдәби тәнкыйть мәкаләләре, яңа чыккан китапларга, сәхнәдә уйналган яңа спектакль премьераларына рецензияләр бастыра. Аларда да драматург, сәхнә әсәрләрендәге кебек үк, үткен күзле сәясәтче, тынгысыз тәнкыйтьче һәм туган халкының мәнфәгатьләрен яклаучы, милли мәдәният үсешен кайгыртучы ватандар шәхес булып күз алдына килеп баса [Гыйләҗев 2005: 154].

Галиәсгар Камал Русиядән 1912 елның ноябрь урталарында китеп, 1913 елның гыйнвар ахырларына кадәр Истанбул шәһәрендә яши һәм Төркиядәге сугыш чоры вазгыяте, халкының тормышы–көнкүреше, сугышка мөнәсәбәте, хөкүмәт даирәләренең эчке һәм тышкы сәясәте, төрле сәяси фиркалар арасындагы көрәш һәм башкалар турында *«Йолдыз»* гәҗитенә озын–озын мәкаләләр язып тора (барлыгы унбишләп мәкалә, шулардан күпчелеге – *«Йолдыз»*да, берничәсе Оренбургтагы *«Вакыт»* гәҗитендә басылган) [Мәһдиев 1987: 68].

1914 – 1917 еллар дәвамында Галиәсгар Камал гәҗиттәге журналистлык эшеннән тыш рус һәм дөнья әдәбиятыннан татар теленә шактый күп сәхнә әсәрләре тәрҗемә итә.

1923 елда әдәби эшчәнлегенең егерме биш еллык бәйрәме уңае белән аңа *«Хезмәт батыры»* дигән, ә 1926 елда, татар профессиональ театрының егерме еллыгында, *«Татарстанның халык драматургы»* дигән шәрәфле исемнәр бирелә.

1939 елдан исә татарның төп театры – Татар академия театры да драматургның абруйлы исемен йөртә башлый.

Галиәсгар Камал 1933 елның 16 июнендә 54 яшендә Казан шәһәрендә вафат була.

Нәтиҗә ясап, түбәндәгене әйтергә кирәк, Галиәсгар Камал үзен аеруча комедия остасы итеп танытты. Галиәсгар Камал иҗаты – татар драматургиясендә тәнкыйди реализмның, бәхәссез, зур казанышы булып тора. Әлбәттә, Галиәсгар Камал үзенең кыска гына гомере эчендә бик күп һәм нәтиҗәле эшләр башкарган. Аның иҗат җимешләрендә бирелгән типлар хәзерге көн өчен дә үзләренең актуальлеген югалтмаган, реаль, җанлы кешеләр.

**Әдәбият**

1.Камал Г. Әсәрләр: 3 томда: 3 т.: хикәяләр, мәкаләләр, рецензияләр, истәлекләр. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1981. – 325 б.

2. Камал Г. Сайланма әсәрләр: пьесалар, хикәяләр, истәлекләр. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2004. – 302 б.

# ТАТАР ПОЭЗИЯСЕНДӘГЕ ЧАГЫШТЫРУНЫ БЕЛДЕРҮЧЕ ТӨЗЕЛМӘЛӘРНЕ ТЕМАТИК ЯКТАН ТӨРКЕМЛӘП АНАЛИЗЛАУ

Ягудина Р.Р.
КФУның Алабуга институты студенты.
Фәнни җитәкче: Хәйруллина Ә.С.

Галимнәр “әдәби әсәр текстындагы чагыштыруларны анализлаганда әдәбият белемендә ешрак, асылы булып чагыштырулар өчен нигез булган образларны тасвирлаудан гыйбарәт семантик типология кулланалар” [Камышова 2006: 11]. Шуны истә тотып, чыгарылыш квалификация эшен язу дәвамында татар поэзиясендә чагыштыруны белдерүче төзелмәләрнең семантик төркемнәре дә тикшерелде. Мондый эш шигырьләрдә кулланылган чагыштырулар аша татарларның дөнья картинасын, яшәү рәвешен, шагыйрьләрнең иҗади осталык дәрәҗәсен, аларның дөньяга карашын һ.б.ларны ачыкларга мөмкинлек бирә. Эшебездә чагыштыруларның берничәсенә тукталып китик:

“Антропоморфлар” тематик төркеме. Мондый чагыштыруларда, галимнәр фикеренчә, охшашлык эталоны булып кеше һәм аның сыйфатларына атама булган исем һәм сыйфатлар алына [Богрова, 2012: 13]. Әлеге төркемгә без туганлык терминологиясе (ана), гендер (кыз, егет), һөнәр (сынчы) һ.б.лар буенча атауны керттек. Кайбер мисалларны карап үтик. Күзәтүләребез күрсәткәнчә, еш кына чагыштыруларда өлкән, олыгайган кеше образы очрый. Ешрак ул карт, карчык лексемалары аша репрезентацияләнә. Мәсәлән:

Үҗәтләнеп, җирне күләгәләп,
Кычытканнар үсә балчыкта.
Тып–тын гына сулып ята кое,
Күз яшьләре кипкән *карчыктай* [Низами 2005: 65].
(“Ташландык кое”)

Тиберченеп ала нәни колын.
“Без картайдык инде, син яшә...”
Гомер иткән *ил картлары сыман*
Тын утарда атлар сөйләшә [Низами 2005: 48].
(“Әрәмәдә – сәер кош авазы...”)

Боларга капма–каршы рәвештә чагыштыру эталоны булып кеше тормышының сабыйлык, үсмерлек, җитлегү онтологик этаплары торган очраклар да күзәтелде:

О, сугышлар булган заманында!
Ә музейда дөнья тып–тыныч...
Бишектәге *сабый сыман* ята
Яшен булып очкан бу кылыч [Низами 2005: 26].
(“Музейда”)

Сулык–сулык тибә гөрләвекләр,
Сызып кына аккан гомердәй.

Язлар саен мин мәхәббәт көтәм
Уналтысы тулган *үсмердәй*! [Низами 2005: 66].

(“Язлар килә”)

Сал җилкәмә яшел кулларыңны,
Саумы, дустым – яшьтәш миләшем!
Дөнья күргән *ир–егетләр сыман,*
Бер утырыйк әле сөйләшеп [Низами 2005: 58].

(“Туган авылда очрашу”)

Әлеге төркемдә без, шулай ук, кешенең социаль эшчәнлеге белән бәйле булган чагыштыруларны да тикшердек. Алар күпсанлы булулары белән аерылып тора. Бигрәк тә мәгърифәт, сәнгать дөньясы белән бәйләнешле чагыштырулар очрады. Мондый чагыштыруларның еш очравы халкыбызда электән булган гыйлемгә, матурлыкка омтылышның һаман да исән булуы белән бәйле, дип уйлыйбыз. Теркәлгән кайбер очракларга күз төшереп үтик:

Җиле качкан, өрми этләре дә,
Уйга баткан чагы дөньяның.
Топольләргә хәтле тынып калган,
*Карт философ кебек* уйланып [Низами 2005: 32].

(“Кич”)

Татар халык мәкаль–әйтемнәрен туплап бастыруга зур өлеш керткән күренекле фольклорчы Нәкый Исәнбәткә багышланган “Һәйкәл” шигырендә Рашат Низами галимне сынчыга тиңли:

Халыкның бәгырь түреннән
Җыеп сүзне, фикерне, –
Халыкка һәйкәл салды ул
*Оста сынчы шикелле* [Низами 2005: 73].

(“Һәйкәл”)

Туганлык терминологиясенең чагыштыруны белдерүче төзелмәләр составында килүе сирәк очрады, кулланылган очракта да шагыйрьләр ешрак, ана, әнкәй кебек терминнарга мөрәҗәгать итәләр:

Аяклар нык тупасланган –
Чәнчемидер аны камыл.
Сүзсез калган *ана кебек*
Каршы ала сине авыл... [Низами 2005: 29].

(“Күктәге ак болыт сыман...”)

Табигать бит *әнкәй сыман* икән:
Үзе кырыс, үзе юмарт та, –
Көтә безне урман чикләвеге,
Балга баткан яшел умарта [Низами 2005: 148].

(“Үзем белән сөйләшү”)

Аерым очракларда, шигырьләрдә дию, шәйтан, шүрәле кебек образлар нигезендә төзелгән чагыштырулар очрый. Дию, шәйтан – мифологик образлар, ә шүрәле исә – әкият герое. Безгә аларның кыяфәтләре, тышкы сурәтләре

рәссам фантазиясенә бәйле рәвештә туган рәсемнәр аша гына таныш. Алар кеше аңында, хыялында, халык авыз иҗатында актив яши. Кечкенәдән үк һәркем бу образлар катнашындагы әкиятләрне тыңлап үсә. Кемнәрдер алардан курка, кемнәрдер аларны куркыту чарасы буларак куллана. Әлеге дини–мифологик затлар сурәтлелек тудыру максатыннан поэзиядә дә үз урыннарын тапканнар. Авторлар алар ярдәмендә үзләренең геройларының тышкы кыяфәтләрен чагыштыралар, әлеге дини–әкияти җан ияләренә хас начар сыйфатларны кеше образларына күчерәләр. Шул рәвешле, укучы күңелендә гадәти булмаган, бер үк вакытта шомлы, бер үк вакытта кызыклы ассоциатив картина тудыралар. Мисал өчен:

Тормак ярый: бертуктамый ялганласаң,
Тугъры сүзле инсаннарга ялганмасаң,
Вөҗданыңнан *шәйтан төсле* тыр–тыр качып,
Үзен алдап, башкалардан алданмасаң [Тукай, 1 т., 2011: 137].
("“Дөньяда торыймны?” дип киңәшләшкән дустыма")

Нәтиҗә ясап, шуны әйтергә кирәк: татар поэзиясендә чагыштыруны белдерүче төзелмәләр күбрәк “антропоморфлар” (туганлык терминологиясе, һөнәр һ.б. атамалар), “күренекле шәхесләр, мифологик персонажлар”, “соматизмнар”, “фитонимнар”, “хайваннар”, “кошлар”, “табигать стихияләре”, (шул исәптән географик объект атамалары), “артефактлар”га нигезләнгән тематик төркемнәргә карыйлар.

**Әдәбият**


1. Низами Р. Тормыш трамвае: Шигырьләр, поэма. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2005. – 238 б.
2. Тукай Г. Әсәрләр: 6 томда 1 т.: шигъри әсәрләр (1904 – 1908) / төз., текст., иск. һәм аңл. әзерл. Р.М. Кадыйров, З.Г. Мөхәммәтшин; кереш сүз авт. Н.Ш. Хисамов, З.З. Рәмиев – Казан: Татар. кит. нәшр., 2011. – 407 б.
3. Тукай Г.М. Әсәрләр: 6 томда. 2 т.: шигъри әсәрләр (1909 – 1913) / төз., текст., иск. һәм аңл. әзерл. З.Р. Шәйхелисламов, Г.А. Хөснетдинова, Э.М. Галимҗанова, З.З. Рәмиев. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2011. – 384 б.
4. Тукай Г. Сагыныр вакытлар: балалар өчен шигырьләр, шигъри әкиятләр, автобиографик повесть = Незабываемое время: стихотворения для детей, сказки в стихах, автобиографическая повесть / төз. Л.Ә. Гыйззәтуллина. – 2 нче басма. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2016. – 207 б.
5. Камышова А.Е. Сравнения и его функции в структуре прозаического текста (на материале прозы В. Брюсова): автореферат дис. … канд. филол. наук. – СПб., 2006. – 21 с.

# “БЕРЕНЧЕ ТЕАТР” КОМЕДИЯСЕНЕҢ СЮЖЕТ–КОМПОЗИЦИЯСЕ

Янгирова С.Ф.,
Бөгелмә районының Кодаш төп мәктәбе укучысы.
Фәнни җитәкче: Янгирова Л.Ф.

“Беренче театр” комедиясенең композициясе бик камил. “Композиция – (латинча: төзү, тәртипкә китерү) – әдәби әсәрдә образларны бер–берсенә бәйләү, вакыйгаларны төп максатка ярашлы итеп урнаштыру, әсәрнең барлык элементларын сәнгатьчә оештыру” [1:72]. Драма әсәрләренең төзелеше башка жанрлардан аерыла. Әсәрне төзү сюжет төзүдән башлана. “Беренче театр” комедиясенең сюжетына җыйнаклык һәм бөтенлек хас. Сюжет (фр. предмет) – эпик, драма, лиро–эпик әсәрләрдә вакыйга–хәлләр яки кеше холкы–характерының үсү–үзгәрү тарихы [2:185]. Бер пәрдәдән торган комедия экспозиция элементыннан башланып китә һәм шунда ук театрга бару вакыйгасы белән бәйләнгән төенләнеш барлыкка килә: театр куелуга каршы торган Хәмзә бай белән яңалык яклы Вәли, Факиһә арасындагы каршылык оеша. Комик хәл–ситуацияләрдә, вакыйгаларда катнашкан каһарманнар хакында мәгълүмат әсәрдә бүленеп, таратылып бирелгән. Вәли–Гафифә, Факиһә–Хәбибрахман, Фатихларның театрга китүләре вакыйгалар үстерелешен тәэмин итәләр. Театрны булдырмау артыннан йөреп, арып–талчыгып өенә кайткан Хәмзә бай өендә, балаларының театрга китүен белгәннән соң булган хәл – вакыйгалар сюжет сызыгының кульминацион ноктасын барлыкка китерә. Хәмзә байның көлкеле хәлен күрсәткән чишелеш белән комедия тәмамлана.

“Беренче театр” пьесасының сюжеты бер конфликт тирәсендә оешкан концентрик һәм тиз үсә торган динамик сюжет төренә карый.

“Беренче театр” комедиясендә тел катламына тискәре, комик геройларның көлкеле халәтен ачу вазифасы йөкләнә.

Г.Камалда телне гаҗәеп нечкә сиземләү сыйфаты бар. Сүзнең берничә мәгънәгә ия булуы, омофония, омография, фразеологик әйтелмә составындагы берәр сүзнең төп мәгънәдә кулланылуы һәм башка лексик–семантик, фонетик күренешләргә, чараларга нигезләнгән телнең гаять нечкә үзлекләре аның иҗатында комик эффект тудыру, дошманыннан үтергеч көлү, персонажлар көрәшенә җанлылык кертү өчен файдаланылган.

Драматург каламбур һәм сүз уйнатуга еш кына мөрәҗәгать итә. Омонимнар–каламбур өчен иң кулай материал, чөнки контекстта мәгънәләрнең күтелмәгәндәге бәрелеше каламбурга үзенә бер төрле үткенлек бирә.

Гафифә: Нинди күлмәгемне киим икән, *асылмы*, йонмы?

Вәли: (*үз–үзенә*). *Асыласың* килсә, *асылын* инде [3:66].

Өлешчә омонимиягә тигезләнгән бу каламбур геройның билгеле моменттагы хәлен, персонажлар арасындагы мөнәсәбәтне ачыграк күрсәтә.

Халык телендә комик эффект тудыру өчен алынма сүзләрне теге яки бу максатларда юри, аңлы рәвештә бозу алымы еш кулланыла:

Вәли: Тыңласаң, шул: менә бер хәзер *театрга* китәбез...

Биби: Кая?

Вәли: *Театрга!*

Биби: Нәрсә *төятергә?*

Вәли: Баш төятергә.

Биби: Нинди баш?

Вәли: Атаң башы! Мин сиңа *төятергә* димим, *театрга* дим, аңладыңмы, *театрга* дим! [3:63].

Бусы – мәсьәләнең бер ягы. Икенчедән, Биби театр сүзен беренче тапкыр ишетә һәм аны төятергә сүзе белән бутый. Гафифәнең озак җыенуына ачуы чыккан Вәлине Бибинең бу соравы чыгарыннан чыгара, ул Биби соравына тупас җавап бирә. Ә Биби баш төятергә әйтелмәсен туры мәгънәдә ала.

Гафифә: Мин аны беркөннәрне Гарифәләргә җибәрдем. “Абыстай: “Гарифәнең алдырган *кислотасы* юк микән, бик күңелләрем болганып тора. Үзебездә судысы бар – барын да, ирләр өйдә вакытта *кислота* алдырырга онытылган”, – дип әйтте, дип сора”, – дигән идем, барган да: “Абыстай *киез каталарын* биреп тосыннар ла”, – дип сорап миңа *кислота* урынына *киез ката* күтәреп кайткан... [3:65].

Телдә якын әйтелешле, ләкин төрле мәгънәдәге сүзләрне якынайту, бәрелештерүгә нигезләп комик эффект тудыру очраклары да бар. Мәсәлән:

Хәмзә: Бар әле [...] Коръән укый торган шәкертне чакырып чыксыннар. “Абзый *чәч* алырга чакыра”, – дисеннәр.

Биби: Нинди *мәче* алырга?

Хәмзә**:** Һәй аңгыра, җебегән нәрсә! Мин сиңа *мәче* алырга дидеммени! *Чәч* алырга дим! Чәч *(Үз чәчен тарткалап).* Менә, менә шушыны алырга, дим! [3:75].

Хәмзә бай сүзләрен аңламаганга салышкан Биби *чәч* сүзен *мәче* дип ишеткән була. Бу сүзләр авааздаш түгел, ләкин автор комик эффект өчен бу ике сүзне *ә, ч* авазлары уртаклыгына нигезләп якынайта.

*Хисмәт* һәм *кисмәк* сүзләренең яңгырашындагы охшашлык Хәмзә байны тагын да кыен хәлгә куя:

Хәмзә: Җыен аңгыра безгә җыелган. Беркөн Хәбибрахманга: “Бар, агач базарына *Хисмәткә* бар да, аны тизрәк монда алып кайт”, – дип җибәргән идем, барган да бер зур *кисмәк* алып кайткан... [3:75].

Тел–стиль чараларының катлаулы комплексыннан торган һәм сатирик–юмористик эффект бирүдә мөһим алымнарның берсе – сүз уйнату.

Каламбур һәм сүз уйнату матур әдәбиятта еш кына персонажларның бер–берләрен аңлый алмавына, аңлашылмаучанлыкка корылган комик ситуация тудыру өчен дә файдаланыла:

Биби: Абзый, Миңлебай абзыйга әйткән идем: “*Коръән укый торган шәкертне* алып чык”, – дип, – “Нинди шәкерт ул, мәдрәсәдәге шәкертләр алар бар да Коръән укыйлар, анда әфтияк укучы юк”, – ди.

Хәмзә: (*аяк тибеп*) Һай, ахмаклар! Әрәм тамаклар! Бар, тизрәк чыгып әйт, *мәчеттә Коръән укый торган шәкертне, Гайфулланы* чакырып чыксын!

Биби: Икесен дә чакырсынмы?

Хәмзә: Нинди икесен дә?!

Биби: *Коръән укучыны* да, *Гайфулланы* да.

Хәмзә: Үләм инде, мин сезнең белән, җәфаланып үләм! Аңгыра! Соң шул *Коръән укучы шәкерт* белән *Гайфулла* икесе дә бер ләбаса инде! [3:76].

“Яхшы укыганы өчен Гайфуллага мәчеттә Коръән уку эше йөкләнгән. Шуңа күрә аңа исеме белән эндәшү урынына, *Коръән укучы шәкерт* кенә диләр. Бу әйтелмә исә, үзенең конкрет мәгънәсен (“китап уку”) югалтып, кушаматка әйләнгән. Миңлебай исә, аны төп мәгънәсендә аңлаганга салышып, фразеологик әйтелмәне тарката. Моның нәтиҗәсе буларак комик эффект туа. Хәмзә бай әйтелмәне *мәчет* сүзе белән конкретлашырырга мәҗбүр була. Ул Гайфулла исемен аерымланган тәмамлык ролендә ала. Бибинең моны тиңдәш тәмамлыклар дип аңлап, кайтарып соравы комик эффектны тагын да көчәйтә.

Шулай итеп каламбур һәм сүз уйнату Г.Камалның сатира–юмор арсеналында иң көчле тел–сурәтләү чараларыннан берсе булып тора.

Драма теле кыска, ләкин аның эчтәлеккә бай булуы таләп ителә. Андагы һәр сүз персонажны, вакыйганы, конфликтны ачуга хезмәт итә. Бу яктан персонажлар сөйләме һәм ремаркалар игътибарга лаек.

Драматургның көлкеле хәлләр тудыруда яратып кулланылган алымнары – монологлар һәм персонажның халыкка карап әйтүләре, үзалдына сөйләнүләре. Г.Камал комедияләрендә еш кына *халыкка карап* ремаркасы кулланыла. Бу да көлке тудыруда әһәмиятле алым булып санала. Монологлар геройның эчке дөньясын, уй–фикерләрен ачып бирүгә хезмәт итә.

Персонажларның теле игътибарга лаек. Алар сөйләмендә тиргәү лексикасы зур урын алып тора. Мәсәлән, Хәмзә бай, Хәмидә сөйләмнәрендә *аңгыра, ахмак, надан* кебек сүзләр еш кулланыла. Бу төр лексика персонажлар теленә шактый көчле экспрессив–стилистик төсмерләр, беренче чиратта, тупаслык, түбәнсетү, фамильярлык төсмерләре кертә һәм шуның белән бергә әсәрнең сатирик көчен арттыра.

Персонажлар телендә халкыбыз җәүһәрләре – мәкаль–әйтемнәр, фразеологик әйтелмәләр еш кулланылган.

Мәсәлән, *уҗым бозавы* фразеологик әйтелмәсе бик юаш, төшеп калган, аны–моны аера белми торган кешегә карата әйтелә. Ул, үзенең туры мәгънәсен югалтып бары тик күчерелмә мәгънәдә генә йөри һәм Факиһә телендә аңгыра, куркак Хәбибрахманны тиргәү, аннан ачы итеп көлү өчен кулланыла: “Әле һаман *уҗым бозавы* киенеп чыга алмаган икән” [3:72].

Автор Хәбибрахманның аңгыралыгын аның эш–хәрәкәтләре аркылы күрсәтеп тә көлке тудыра.

Г.Камалның сатира–юмор арсеналында иң көчле тел–сурәтләү чараларыннан берсе булган каламбур һәм сүз уйнату – авторның үз туган теленең бөтен нечкәлекләрен белүен һәм оста файдалануын күрсәтүче мисал.

**Әдәбият**

1. Әдәбият белеме сүзлеге / Төз. – ред. А.Г.Әхмәдуллин. – Казан: Татар кит. нәшр., 1990. – 239 б.

2. Әдәбият белеме: Терминнар һәм төшенчәләр сүзлеге /Д.Ф.Заһидуллина [һ.б.] – Казан: Мәгариф,2007. – 230 б.

3. Камал Г. Әсәрләр: 3 томда Т.1/ Г.Камал. – Казан: Татар.кит.нәшр., 1978. – 367б.

## ЭЧТӘЛЕК


1. **Абакаева А.В**. “**Татар әдәбиятының актуаль мәсьәләләре”** (Алабуга шәһәре 8 нче урта мәктәбенең укучысы. Фәнни җитәкчесе: Гайсина Г.Г.). 3

**2. Айзатуллина Д.А**. “**Галиәсгар Камал – татар сәнгатенә нигез салучы”** (Әлмәт шәһәре 17нче урта мәктәбенең 9 нчы сыйныф укучысы. Фәнни җитәкче: Ибрагимова Г.А**).** 5

**3. Арсланова А.Ф**. “**Экологик тәрбия бирүнең педагогик нигезләре”** (КФУның Алабуга институты студенты. Фәнни җитәкче Камаева Р.Б.). 6

**4. Богаутдинова Д.А. “Полилингваль белем бирү шартларында татар теле һәм әдәбиятын укыту”** (Арча шәһәре, “Г.Тукай исемендәге Арча педагогия көллияте” студенты. Фәнни җитәкче: Гыйләҗева А.Ф.). 9

5. **Борһанова Л.И.** “**Фольклор текстларында кабатлаулар”** (КФУның Алабуга институты студенты. Фәнни җитәкче Камаева Р.Б.). 11

6. **Вәлиева В.**В. **“Хәзерге хикәя жанры үзенчәлекләре”** (КФУның Алабуга институты студенты. Фәнни җитәкче Габидуллина Ф.И.). 14

**7. Газимова Р.И.** “**Театр – яктылыкка, нурга илтә, кире юлга җибәрми, уңга илтә...”** (Алабуга шәһәренең 8 урта мәктәп укучысы) Фәнни җитәкче: Якупова Ф.М.). 16

8. **Гайнуллина З.Ш.** “**Пионерия – остазларыбыз биографисе”** (Алабуга районы Иске Юраш мәктәбенең 7сыйныф укучысы. Фәнни җитәкче: Гайнетдинова К.Ф.). 19

**9. Галишина И.Л**. “**Г.Камалның “Беренче театр” комедиясен өйрәнү дәресендә укучыларның танып–белү активлыгын үстерү юллары”** (КФУның Алабуга институты студенты. Фәнни җитәкче Камаева Р.Б.). 22

**10. Гаптракипова Д.М. “Кәрим Тинчуриның “Сүнгән йолдызлар” драмасына анализ”** (Әлмәт шәһәренең «Адымнар – Әлмәт» күптелле гимназиясе»нең 9 “Б” сыйныфы укучысы. Фәнни җитәкче: Тамасова Я.И.). 25

11. **Гарифуллина Т.Р**. "**Татар телендә эндәш сүзләр һәм аларның грамматик үзенчәлекләре”** (КФУның Алабуга институты студенты. Фәнни җитәкче: Хәйруллина Ә.С.). 27

**12. Гильмутдинова Ф.Ф, “Рәвеш” темасын өйрәтү дәресендә күрсәтмәлелекнең роле** (КФУның Алабуга институты студенты Фәнни җитәкче Камаева Р.Б.). 29

**13. Гилмуллина АЛ. "Галиасгар Камал һәм театр”** (Алабуга шәһәренең 10 нчы күппрофильле лицей укучысы. Фәнни җитәкче: Гилмуллина Л.С.). 31

**14. Гилязов А. Л. “А.Хәлим хикәяләрендә әдәби деталь функцияләре”** (КФУның Алабуга институты студенты. Фәнни җитәкче Габидуллина Ф.И.). 33

**15. Гиматова А.Р. “Театр нурга илтә...”** (Алабуга шәһәренең 10 нчы күппрофильле лицей укучысы. Фәнни җитәкче: Усманова Р.Н.). 35

16. **Гимранова Э.Ф. “10 сыйныфта “Тел һәм сөйләм” темасын өйрәнү”** (КФУның Алабуга институты студенты. Фәнни җитәкче Камаева Р.Б.). 37

**17. Григорьева Е.Н. “Мәктәптә укучылар эшчәнлеген бәяләү системасы”** (КФУның Алабуга институты студенты. Фәнни җитәкче: Камаева Р.Б.). 40

**18. Гурьева К.С**. **“Галиәсгар Камал иҗатының төрлелеге”** (Мамадыш шәһәренең Кызыл Тау урта белем бирү мәктәбе укучысы. Фәнни җитәкче: Антонова Д.А). 43

**19. Гыйльметдинов А.С. “Мәгърифәтле һәм мәдәниятле булу – һәр халыкның мәңгелек хыялы”** (Алабуга шәһәренең 8 урта мәктәп укучысы. Фәнни җитәкче: Якупова Ф.М. ). 45

20. **Гыйльметдинова.Ф.Ф. “Татар телендә рәвешнең лексик-семантик асылы”** (КФУның Алабуга институты студенты. Фәнни җитәкче: Ә.С.Хәйруллина). 48

**21. Закирова А.И**. **“Туган тел ул – бездән соң да яшәр өчен туган тел”** (Алабуга муниципаль районы “Иске Юраш урта мәктәбе”нең 10 нчы сыйныф укучысы. Фәнни җитәкче: Юнусова Л.М.**).** 50

22. **Захарова А. Д. “Ф. Яруллин поэмаларында әхлакый кыйммәтләр”** (КФУ ның Алабуга институты студенты. Фәнни җитәкче: Габидуллина Ф.И. 53

23. **Зиганшина А. Р**. **“Татар телен өйрәнүнең актуаль мәсьәләләре”** (Алабуга шәһәренең 6 нчы урта мәктәп укучысы. Фәнни җитәкче: Гайсина Р.С.). 57

**24. Ибрагимова М.И. “Тема войны в татарской прозе начала XX века”** (Студентка ЕИ КФУ. Научный руководитель: Даутов Г.Ф.) 60

**25. Исмәгыйлова Г.Р. “Г.Камалның “Бүләк өчен” әсәрен мәктәптә өйрәнү”** (КФУның Алабуга институты студенты. Фәнни җитәкче: Камаева Р.Б.). 62

**26. Казионова О.С. “Галиәсгар Камал һәм аның иҗади мирасы”** (Алабуга шәһәренең 10 нчы күппрофильле лицей укучысы. Фәнни җитәкче: Кантуганова Г.М.). 65

**27. Корбанова З.Г**. **“Галиәсгар Камалның балачагыннан кызыклы мизгелләр”** (Кама Аланы «1нче гомуми урта белем бирү мәктәбе» укучысы. Фәнни җитәкче: Габделхакова Г.И.). 67
**28. Маннапова Г.Р. Татар телендәге кабатлауларның синтаксик функцияләре (**КФУның Алабуга институты студенты. Фәнни җитәкче: Хәйруллина Ә.С.) 70
**29. Марданов Р.Р**. **“Галиәсгар Камал иҗатына ияреп”** (Мамадыш муниципаль районы Урта Кирмән урта гомуми белем мәктәбе, 8 нче класс укучысы. Фәнни җитәкче: Марданов Р.А.). 72
**30. Маткаримова А.Х. ”Габдрахим Утыз–Имәни әл болгари”** (Әлмәт шәһәре «13нче урта гомуми белем бирү мәктәбе»нең 10нчы сыйныф укучысы. Фәнни җитәкче: Гарипова А. Ш.) . 74
**31. Мордовина К.В. “Мәгърифәтче идеяләрен дәвам итүче”** (Бөгелмә шәһәренең 18нче төп мәктәп укучысы. Фәнни җитәкче: Насыбуллина А.Н.). 76
**32. Мөбәрәкшина Д.Л. “Кәшер авылында беренче мәдрәсәләр ачылу”** (Әлмәт районы, Яңа Кәшер урта мәктәбенең 10 нчы сыйныф укучысы. Фәнни җитәкче: Шайхулова А.И **).** 78
33. **Мөхәммәтшина А.Ф. “ Мәдәни код буларак милли ризыклар (татар һәм кытай ризыклары мисалында)”** (Казан федераль университетың 2 курс магистранты. Фәнни җитәкче: Нурмөхәммәтова Р.С.). 79
**34. Мукимова Г.Ф. “Галиәсгар Камалның әдәбиятта тоткан урыны һәм иҗатының идея–эстетик үзенчәлекләре”** (КФУның Алабуга институты 2 нче курс студенты. Фәнни җитәкче: Даутов Г.Ф.). 82
**35. Насыбуллина А.Р**. **“Дибәҗә Каюмова – төбәгебезнең күренекле шагыйрәсе һәм прозаигы”** (Алабуга шәһәренең “10 нчы күппрофильле лицее укучысы Фәнни җитәкче: Әшрәфуллина Р.И). 84
**36. Нәбиуллина А.Р. “Татар халык җырларын мәктәптә электрон ресурслар кулланып өйрәтү” (**КФУның Алабуга институты студенты. Фәнни җитәкче: Хәйруллина Ә.С ). 88
**37. Нәбиуллина А.Р. Мәктәптә иҗади үсеш технологиясенә нигезләнеп “исем” темасын өйрәнү (**КФУның Алабуга институты студенты. Фәнни җитәкче: Хәйруллина Ә.С ). 89
38. **Нәҗметдинова А.Г “Г. Сабитовның “Ярсулы яз” әсәрендә күчерелмә мәгънәгә бәйләнешле сурәтләү чаралары”**. (Алабуга районы, Иске Юраш мәктәбенең 7 нче сыйныф укучысы. Фәнни җитәкче: Гайнетдинова К.Ф. ). 91
39. **Нуриева Н.Д. “Г.Камал иҗатын мәктәптә өйрәнү” (**Алабуга институтының “Университет” гомум белем бирү мәктәбе укучысы. Фәнни җитәкче: Сахабиева Г.Х.). 95

**40. Сәхәбетдинова Ә.Б. Г.Камалның “Банкрот” һәм Н.В.Гогольнең “Үле җаннар” әсәрләрендә әхлыкй кыйммәтләр** (КФУның Алабуга институты студенты. Фәнни җитәкче: Габидуллина Ф.И.). 97

**41. Сәхәбетдинова Ә.Б. Мәктәптә Һади Такташның “Мәхәббәт тәүбәсе” поэмасын өйрәнү** (КФУның Алабуга институты студенты. Фәнни җитәкче: Камаева Р.Б.). 99

**42. Сундукова А.Ф**. “**Мәктәптә Ф.Яруллинның “Лаеклы кияү” әсәрен өйрәнү”** (КФУның Алабуга институты студенты. Фәнни җитәкче: Камаева Р.Б.). 102

43. **Талипова Г.Р.** “**Текст – как средсто коммуникации”** (студент Елабужского института КФУ. Научный руководитель: Камаева Р.Б.) 104

44. **Тимофеева Т.В.** “**Полилингваль белем бирү шартларында төрек телен татар теле нигезендә укыту”** (КФУның Алабуга институты магистранты. Фәнни җитәкче: Ә.С.Хәйруллина). 105

**45. Фәсхетдинов И.Р**. “**Арча ягы халкын христианлаштыру сәясәте.”** (Арча районы Г.Тукай исемендәге Яңа Кырлай урта мәктәбе укучысы. Фәнни җитәкче: Шиһапова Г.Х.). 108

**46. Феткуллова А.К. “Чуашстан татарлары тормышында яңа торын кабер ташлары”** (Чувашия Республикасы беренче номерлы Шыгырдан урта мәктәбе укучысы. Фәнни җитәкче: Айзатуллова Р.Р.**)**. 111

**47. Хабибуллин Н.И**. “**Философия смерти в рассказах А.Еники”** (Югары Ослан районы «Иннополис лицее» укучысы. Фәнни җитәкче; Евсеева Л.Р. ). 114

48. **Хабибуллина Л. Р. “Лилия Гыйбадуллина шигъриятенә хас үзенчәлекләр” (**КФУның Алабуга институты студенты. Фәнни җитәкче: Габидуллина Ф.И.) 117

**49. Хәкимова Р.А**. “**Галиәсгар Камал – татар театр сәнгатенә нигез салучы”** (Алабуга шәһәренең 10нчы күппрофильле лицей укучысы Фәнни җитәкче: Хайбрахманова А.А. ). 120

**50. Хәкимова И.И.** “**Галиәсгар Камал һәм аның иҗади мирасы”** (Казан шәһәренең “Казан нефть һәм химия көллияте” укучысы. Фәнни җитәкчеләр: Габдуллина Г.М., Ибрагимова В.Н **).** 122

**51. Храмова М.А**. “**Галиасгар Камал – основоположник татарского театрального искусства»** (ученица 9 класса «СОШ №13» г.Альметьевска. Научный руководитель: Устимова Г.Ш.). 125

**52. Хуҗина З.А.,Хисмәтова К.Р. "Татар халкының гореф–гадәтләре, йолаларының бүгенче көндә чагылышы”** (Алабуга шәһәре 8 нче урта мәктәп укучылары Фәнни җитәкчеләре: Шакирова Л.М.,Тимофиева Л.Г.). 126

53. **Хусаенова А.С. “Фразеологизмы с компонентом «зәңгәр/ blue» («синий») в татарском, английском фольклоре” (**ученица МБОУ “СОШ №7, г.Набережные Челны РТ. Научный руководитель: Миннахметова Р.Р.). 130

54. **Шәйхетдинова К.Р. “Татар теле дәресләрендә терминнарны өйрәнү алымнары һәм ысуллары”** (КФУның Алабуга институты студенты. Фәнни җитәкче: Камаева Р.Б.). 131

**55. Шәйхетдинова Э.Т. “Тукай иҗатында экология”** (Югары Ослан районы «Иннополис лицее» укучысы. Фәнни җитәкче; Евсеева Л.Р. ). 133

**56. Шәйхиева И. “Г.Камалның “Беренче театр” драмасында юморны оста куллануы” (**“Г.Тукай исемендәге Арча педагогия көллияте”. Фәнни җитәкче Шаһиева Д.Г). 136

57. **Шәкүрова К.А. “Габдулла Тукай иҗатында әхлак тәрбиясе”** (Алабуга шәһәре 10 нчы күппрофильле лицееның 10 нчы сыйныф укучысы. Фәнни җитәкче: Минһаҗева Р.М.). 138

**58. Шәрифуллина А.И.** “**Мәктәптә татар теле һәм әдәбияты дәресләрендә тәнкыйди материалларны куллану”** (КФУның Алабуга институты магистранты. Фәнни җитәкче: Хәйруллина Ә.С.). 141

**59. Шәрифуллина З.А.** “**Дөрес киенә белү – гүзәл күркәм холыкның бер бизәгедер...”** (“Адымнар – Алабуга” күптелле белем бирү комплексының 10 нчы сыйныф укучысы. Фәнни җитәкчеләр: Комиссарова Ф.Г, Данилова З.С.). 143

**60. Юнусова З.Н**. “**Галиәсгар Камал һәм татар театр сәнгате”** (Алабуга шәһәре “Университет” гомум белем бирү мәктәбенең 10А сыйныфы укучысы. Фәнни җитәкче: Сахабиева Г.Х.). 146

**61. Юнысова Э.Ф. “Галиәсгар Камалның тормыш юлы һәм иҗаты”** (КФУның Алабуга институты студенты. Фәнни җитәкче: Даутов Г.Ф.). 151

**62. Ягудина Р.Р**. “**Татар поэзиясендәге чагыштыруны белдерүче төзелмәләрне тематик яктан төркемләп анализлау”** (КФУның Алабуга институты студенты. Фәнни җитәкче: Хәйруллина Ә.С.). 153

**63. Янгирова С.Ф**. **“Беренче театр” комедиясенең сюжет–композициясе”** (Бөгелмә районы, Кодаш төп мәктәбенең 9 нчы сыйныф укучысы. Фәнни җитәкче: Янгирова Л.Ф**.).** 156

Научное издание

Сборник научных статей XV Всероссийской научно- практической конференции студентов и учащихся
«ТАТАРСКИЙ ЯЗЫК И ЛИТЕРАТУРА. ИСТОРИЯ: ПРОШЛОЕ, НАСТОЯЩЕЕ И БУДУЩЕЕ»

Редакционная коллегия:
Р.Б.Камаева, Ф.И.Габидуллина, Г.Ф.Даутов, А.С.Хайруллина

Подписано к публикации 28.03. 2024 г .
Гарнитура «Times New Roman»